ФӘЙЗЕЛХАК ИСЛАЕВ

БАТЫРША восстаниесе 1755ел



ФӘЙЗЕЛХАК ИСЛАЕВ
БАТЫРША восстаниесе 1755ел

ФӘЙЗЕЛХАК ИСЛАЕВ

БАТЫРША восстаниесе 1755 ел

Тарихи очерк

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2005

УДК 947+957
ББК 63.3(2Рос=Тат)-46
И 80

Фәнни редактор
тарих фәннәре докторы, профессор,
академик *И.Р.Таһиров*

Рецензентлар:
тарих фәннәре докторы *Р.У.Әмирханов*
тарих фәннәре докторы, профессор *И.А.Гыйләҗев*

Ислаев Фәйзелхак

И 80 Батырша восстаниесе. 1755 ел: Тарихи очерк.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.— 127 б.

Үзенчәлекле чыганакларга таянып эшләнгән бу монография 1755 елда булган халык күтәрелеше – Батырша восстаниесенә багышлана. Китапта Русия дәүләтенең дини сәясәте һәм аны тормышка ашыру, татар һәм башка халыкларны көчләп чукындыру, мөселманнарның ислам өчен рухи, икътисади, хокукый эзәрлекләүләргә каршы көрәше тасвирлана. Беренче мәртәбә восстание төрле яктан тикшерелә, актив катнашучыларының ачы язмышы ачыклана.

Китап ислам, татар тарихы белән кызыксынучыларга юллана.

ISBN 5—298—04077—2

Кереш

Татар халкының милли-азатлык көрәш тарихы бик бай һәм күпкырлы. Тик аны фәнни яктан тирәнтен эшләнгән дип әйтә алмыйбыз. Аның сәбәбен мәшһүр тарихчыбыз Ризаэтдин Фәхретдин болай дип аңлаткан: «Башкалар хакимияте астында яшәүче милләтләр өчен тарих белән шөгыльләнергә мөмкинлек юк... Тарихыбыз булмауның, ата-бабаларыбызның, кавем һәм кабиләбезнең хәлләре һәм гомер сөрүләре яхшы беленмәүнең сәбәбе үткәндәге галимнәрнең тик торулары, халкыбызның тарих гыйлеменә бәя бирмәүләре түгел, бәлки бу эшкә мөмкинлек булмау һәм заман тарафыннан ярдәм ителмәүдер»[1].

Шуңа карамастан илебездә демократик үзгәрешләр, Татарстан Республикасының суверен дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелүе бу максатны өлешчә булса да тормышка ашырырга җай тудырды. Максатыбыз — укучыны Русиядә XVIII гасыр урталарындагы ислам тарихы белән таныштыру, милләтебезнең дин өчен алып барган фидаи көрәшен тирәнтен өйрәнү, ислам тарихында эз калдырган изге шәхесләрне барлау.

Тикшерелмәгән фәнни проблемалар арасында XVIII гасыр уртасында Русия империясен тетрәндергән, дини сәясәтне нык үзгәртүгә китергән Батырша восстаниесе дә бар. Батырша мелла исеме белән бәйләнгән вакыйгалар татар тарихында гына түгел, ә бөтен ислам тарихында бик мөһим урын алып торуга карамастан, бу вакыйгалар яңадан тикшерүне, тирән гомумиләштерүне һәм йомгаклауны таләп итә.

Русиядә ислам тарихының тамырлары бик тирәнгә барып тоташа. Кайбер татар елъязмачылары әйтүенә караганда, Идел буендагы мәҗүси төрки халыклар арасында гарәпләр ислам динен Мөхәммәд пәйгамбәр заманында ук уңышлы тарата башлаганнар. Болгар дәүләте җитәкчесе Алмыш хан 922 елны ислам динен дәүләти дин дәрәҗәсенә күтәрә. Шул чордан башлап ислам дине болгар бабаларыбызда, соңыннан татарларда дин генә булып калмаган, аларның рухи терәге, тормыш рәвешенә, яңа цивилизациянең нигезенә әверелгән. Ислам диненең үз урыны Алтын Урда, Казан ханлыклары чорында да үзгәрмәгән, дәүләти дин булып калган.

---

[1] Фәхреддин Р. Болгар вә Казан төрекләре.— Казан, 1993.— 52 б.

Урта гасырларда Идел буенда булып киткән сәяхәтчеләр күзәтүенчә, бу якларда дини изү булмаган, тормышта төрле диннәргә ихтирам, дини түземлелек (толерантлык) яшәгән, мәҗүсиләрне көчләп ислам диненә кертү очраклары да тарихта сакланмаган. Шулай да ислам дине дәүләт дине дәрәҗәсендә булганлыктан, бу якларда башка диннәрне мөселманнар арасында тарату катгый тыелган. Бу хакта 1229 елда Авраамий Болгарский белән булган фаҗига сөйли. Ул, болгарлардан булуга карамастан, ни сәбәптәндер православие динен кабул иткән һәм мөселман болгарлар арасында христиан динен тарату белән шөгыльләнә башлаган. Тик аның мондый миссионерлык эше билгеле була, һәм ул заман кагыйдәләре буенча җәзалап үтерелә. Соңрак аның үле гәүдәсен Владимир шәһәрендәге монастырьда җирлиләр, православие динендәге изгеләр сафына кертәләр.

1552 елның 2 октябрь вакыйгаларыннан соң Идел-Урал якларында ислам дине дәүләти дин дәрәҗәсен югалтып кына калмый, ул эзәрлекләнүче дингә әверелә, ә мөселман татарлар исә яңа шартларга яраклашырга тиеш булалар. Русия дәүләте дә яңа яулап алган мөселман һәм мәҗүси халыкларына карата яңа дини сәясәт алып барырга тиеш була. Яулап алынган халыкларны христианлаштыру дини сәясәтнең төп максаты итеп билгеләнә.

Белгәнебезчә, Русия империясендә нәсара (христиан) дине рәсми дәүләт дине булганлыктан, ул эчке һәм тышкы сәясәттә ифрат зур, чикләнмәгән урын биләп, башка мәмләкәтләрне вә халыкларны буйсындыру өчен дә киң кулланыла. Мәдһиш Иван тарафыннан Казан ханлыгын басып алып җимерүне христиан диненең мөселманлыкны җиңү билгесе итеп карау очраклы булмый. Урыслар Казанны яулап алу өчен хәзерләнгән походны нәкъ тәре походы шикелле оештыралар. Җимерелгән Казан ханлыгы җирләрендә православие дине дәүләт диненә әверелеп, мөселман һәм мәҗүси халыкларга көчләп тагыла башлый, халык гаепсезгә җәбер-золымга дучар ителә, ә Казан шәһәре тиз арада урыс шәһәренә һәм дә нәсара динен шәрекъ халыкларына тарату үзәгенә әверелә. Моның өчен 1555 елда архиепископ Гурий җитәкчелегендә Казан епархиясе оештырыла. Православие динен уңышлы тараткан өчен архиепископ Гурий, Зөя монастыре архимандриты Герман һәм Казан Кремлендә урнашкан Спасо-Преображение монастыре архимандриты Варсонофий атакайлар Рус православие чиркәвендә изгеләр рәтенә кертеләләр. Варсонофий атакайның мөселманнар арасында урыс динен татарча беренче таратучылардан булганын да искәртеп киту мәслихәт.

Нәкъ шушы заманда татарлар арасында беренче керәшеннәр пәйда була да инде. Идел буенда Русия дәүләте тарафыннан беренче мәртәбә халык санын алу вакытында (ә ул 1564 —1568 елларда үткәрелә) татарлар арасында беренче

керәшеннәр рәсми теркәлгәннәр. Шушы еллардан башлап дәүләт православие чиркәве белән бергә биредә яшәгән халыклар арасында православие динен тарату өчен системалы рәвештә эш алып бара. Мондый сәясәт төрле елларда төрлечә тормышка ашырыла: кайвакытларда көчәя, куәтләнә, ә кайбер елларда сүлпәнләнеп, юкка чыгу дәрәҗәсенә җитә.

Русия империясендә яшәгән урыс булмаган халыкларны рухи изү, көчләп чукындыру сәясәте Бөек Петр патша заманында яңадан чәчәк ата башлый. Ул чорда татар морзалары чукындырыла һәм феодаль катлау буларак юкка чыгарыла; чукынганнар өчен төрле өстенлекләр билгеләнә: аларны 3 елга салым түләүдән, рекрутлыктан, җинаять кылганнарны җаваплылыктан, бурычлыларны әҗәттән азат итү турында махсус указлар чыгарыла.

Андый сәясәтне Петрның варислары да дәвам итә, һәм ул 1731 елда Зөя шәһәрендә урнашкан Богородицкий монастырендә чукындыру кантуры төзү белән тәмамлана. XVIII гасырның 40 — 50 нче елларын ислам динен юк итү, татарларны урыслаштыруның иң кискен еллары дип атасак, ялгышмабыз кебек. Чөнки нәкъ шушы елларда урыс булмаган халыкларны күпләп чукындыру, төрле ысуллар файдаланып православие диненә кертү башлана. Көчләп чукындыруга түзә алмаган мөселманнар восстание күтәрәләр. Ул тарихта Батырша восстаниесе исеме белән билгеле.

1755 елда барган Батырша восстаниесен фәнни яктан өйрәнү күптән алып барылса да, без әлегә аны тирәнтен һәм күпкырлы итеп өйрәнелгән дип әйтә алмыйбыз. Патшалар заманында да, совет чорында да төрле сәбәпләр аркасында, бигрәк тә сәяси һәм идеологик чикләүләр аркасында, мондый фәнни эзләнүләр хупланылмады; күрәсең, ислам белән православие диннәре, татар, башкорт, казакъ, урыс халыклары арасында булган четерекле кайбер проблемалар фәннән читтә калды. Степан Разин, Емельян Пугачев яуларына йөзләгән-меңләгән китап-статьялар багышланган вакытта да Батырша восстаниесе турында махсус эзләнүләр юк дәрәҗәсендә иде. Хәзерге вакытка кадәр А.П.Чулошниковның 1940 елда чыккан зур булмаган китабы Батыршага багышланган бердәнбер монография булып кала бирә. Батырша восстаниесенә багышланып әзерләнгән чыганаклар җыентыгы дистәләрчә еллар архив киштәсендә тузанланып ята.

Татар, башкорт, ислам тарихында дини сәясәтне үзгәртүдә алмаштыргысыз зур урын тоткан бу вакыйгалар мәңгегә игътибарсыз була алмый. Батырша восстаниесе тарихын фәнни өйрәнү хәзерге вакытта, төрле төбәкләрдә дини низаг-конфликтлар көчәйгән чорда, бигрәк тә актуальләшә. Батырша мелланың фәнни биографиясе дә юк, шуннан файдаланып, кайбер тарихчылар арасында аны башкорт халкының милли герое итеп күрсәтергә теләүчеләр дә бар.

Мөселманнарның рухи бәйсезлеге, азатлыгы өчен көрәш тарихын өйрәнүнең тагын бер мөһим ягы бар: без дини көчләүгә каршы көрәш тарихын бөтен нечкәлекләре белән белгәндә генә толерантлык проблемасын, җәмгыятьтә дини түземлелекне тәрбияләү мөһимлеген тиешлечә аңлый алачакбыз. Соңгы вакытта үткәрелгән фәнни тикшеренүләр Русиядә дини түземлелек, толерантлыкның башка илләр белән чагыштырганда түбән булуын һәм тагын да түбәнәюен күрсәтүгә карамастан, җәмәгатьчелек бу проблемаларны күрмәмешкә салыша, аңарга тиешле игътибар бирми. Мондый очракта рухи азатлык өчен көрәш тарихын өйрәнү тагын да актуальләшә.

Без мелла Батырша Галиев җитәкчелегендәге восстание тарихын төрле яктан тирәнтен өйрәнүне үзебезнең максат итеп куйдык. Бу максатны тормышка ашырыр өчен, без түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә тиешбез:

— восстаниенең дини, социаль-икътисади алшартларын тикшерү;
— христианлаштыру сәясәтенә каршы мөселманнарның көрәшен, Батырша Галиев җитәкчелегендәге восстаниенең төрле төбәкләрдә әзерләнүен, кинәт башланып китүен, барышын һәм әһәмиятен күрсәтү;
— фетнәчеләрнең җиңелү сәбәпләрен, Батыршаның һәм восстаниедә катнашучыларының ачы язмышын, восстание сабакларының дини сәясәтне үзгәртүдә урынын барлау.

Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләр тиешле дәрәҗәдә чишелгән очракта без максатыбызга ирешербез дип уйлыйм.

Восстание Башкортстанда булса да, без анда булган вакыйгаларны күрсәтү белән генә чикләнмәскә уйладык. Мөселманнар яшәгән Идел, Урал, Себер якларында, Мәскәү, Санкт-Петербург калаларында булган хәлләрне тикшермичә, татар һәм башкортларның ислам дине өчен көрәшен тулысынча күз алдына китереп һәм аңлап булмый.

Батырша восстаниесе вакыты буенча 1755 елның берничә аен гына алса да, без бу ел белән генә чикләнмәскә уйладык, Русия мәмләкәтенең дини сәясәт тарихын тулырак итеп төрле елларда күрсәтергә тырыштык.

Батырша восстаниесенең күпкырлы тарихын өйрәнү ышанычлы булган төрле чыганаклар кулланып эшләгәндә генә мөмкин. Мөселманнарның көчләп чукындыруга каршы көрәше күп чыганакларда чагылыш тапкан. Аларның күбесе Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Казан архивларында саклана, ә кайберләре китапларда да бастырылып чыгарылган инде.

Китапның төп чыганагы итеп 1755 елда булган восстание сәбәпләрен белү өчен үткәрелгән махсус тикшерү материалларын санап булыр иде. Мәскәүдә урнашкан Русия дәүләт борын-

гы актлар архивында (Российский государственный архив древних актов — РГАДА) Преображенское яисә Приказ Тайных дел дип аталган приказ фондында мулла Батырша восстаниесенең тикшерү материаллары саклана. Шушы һәм башка архив материалларын файдаланып, 1940 елда А.П.Чулошников «Восстание 1755 г. в Башкирии» дигән китап бастырган иде инде. Архивта сакланган восстание материалларын заманча тикшерү, бигрәк тә восстаниедә катнашучыларның сорау алу материаллары восстаниене хәзерләү, аның барышы, гыйсъянчы мулланың тарафдарлары турында яңа мәгълүматлар табарга мөмкинлек бирде. Без шулай ук башка архивларда табылган кайбер чыганакларны да файдаландык.

Мөселманнарның көчләп чукындыруга мөнәсәбәте Батырша мулла тарафыннан язылган «Өндәмә»дә һәм «Гарызнамә»дә иң төпле чагылыш тапкан. Шуңа күрә мөселманнарның рухи азатлык өчен көрәшен бу материаллардан башка өйрәнеп булмаганлыгын исәпкә алып, без аларны төрле яктан файдаландык.

Белгәнебезчә, Батырша «Өндәмә»сенең Ырынбур кәнсələрендә эшләнгән урысча тәрҗемәсе беренче булып урыс тарихчысы П.И.Рычков тарафыннан өлешчә бастырылган иде. Соңыннан бу уникаль документтан академик Н.Ф.Дубровин һәм Казан Дини академия профессоры Е.Малов файдалана. Әлеге документ тулысынча беренче мәртәбә В.Н.Витевскийның китабында басылып чыккан иде. Без шушы китаптагы материалларны яңадан татарчага тәрҗемә итеп файдаландык[2].

Күп еллар «Өндәмә»нең төп нөсхәсе югалган дип уйланылган иде. Батырша мирасын тирәнтен өйрәнүче Башкортстан Фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы, профессор Гайса Хөсәенов бу чыганакны беренче мәртәбә Батыршага багышланган «Батырша — выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир 1755 —1756 гг.» дип аталган юбилей җыентыгында чыгарган иде. Без бу материаллардан да файдаландык.

Батыршаның императрица Елизавета Петровнага хаты, Гайса әфәнде Хөсәенов тарафыннан әзерләнеп, 1993 елда аерым китап итеп нәшер ителгән иде[3]. Татар телендә шушы ук доку-

---

[2] Рычков П.И. Топография Оренбургская.— Оренбург, 1887; Дубровин Н.Ф. Пугачев и его сообщники. Эпизод из истории царствования императрицы Екатерины II, 1773 —1774 гг. По неизданным источникам. В 3 т.— СПб.,1884; Малов Е. О Новокрещенской конторе.— Казань, 1878; Воззвание Батырши // Витевский В.Н. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г.— Казань, 1889.— Вып 5.

[3] Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне [Текст, транскрипция, перевод на русский язык. Факсимиле] / Составитель, автор введения и глоссария акад. Г.Б.Хусаинов / УНЦ РАН.— Уфа, 1993.

ментны 2000 — 2001 елларда «Мирас» журналында Мәсгуд абый Гайнетдинов җитәкчелегендәге төркем бастырып чыгарды[4]. Кызганыч, журнал вариантында тарихчылар өчен кыйммәтле искәрмәләр төшереп калдырылган. Ике текст нигездә бер булса да, алар арасында шактый аермалар да күренә.

Капитан Леонид Иванович Люшин Военно-ученый архивта сакланган «Описание бывшего в Башкирии замещания 1755 года» дигән материалны Казан император университетында чыккан «Известия общества археологии, истории и этнографии» җыентыгында бастыра. Күләме буенча бик зур булмаган бу язмада Батырша восстаниесе башыннан алып ахырга кадәр тасвирлана[5].

Әлбәттә, без бу материаллар белән генә чикләнмәдек. «Полное собрание постановлений и распоряжений по ведомству православного исповедания Российской империи» дип аталган җыентыкта да безнең темага караган күп материаллар тупланган. Дини сәясәт, мөселманнарның көчләп чукындыруга каршы көрәше синод һәм сенат архивларында саклана. Алар патша заманында нәшер ителгән иде. Без аларны да файдаландык. Хезмәтебездә Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев истәлекләре, чукынган татар морзасы Тәфкилев материаллары да кулланылды[6].

XX гасырның 30 — 60 нчы елларында Башкортстан, Татарстан автономия республикалары тарихына караган җыентыклар нәшер ителде. Башкортстан тарихына багышланган күптомлык җыентыкта дини сәясәт, чукындыру, татарларның һәм башка халыкларның дини изүдән качып бирегә күчеп килүләре хакында гыйбрәтле материаллар бар[7].

Китапта шәҗәрәләрдә сакланып калган тарихи материаллар да файдаланылды. Күренекле тарихчы Миркасыйм абый Госманов мондый сүзләр язган иде: «Шәҗәрәләрдә ыру-гаилә тарихына караган үзенчәлекле белешмәләр саклана һәм аларда башка чыганакларда булмаган мәгълүматлар табып була. Шә-

---

[4] Батырша (Габдулла Алиев). Гарызнамә: Трактат // Мирас.— 2000.— № 11—12; 2001.— № 1.

[5] Люшин Л.И. Описание башкирского бунта 1755 года // ИОАИЭ.— Т. 19.

[6] Неплюев И.И. Записки / Новое полное издание, с примечаниями.— СПб., 1893; Разные бумаги генерал-майора Тевкелева об Оренбургском крае и киргиз-кайсацких ордах, 1762 год // Временник Имп. Моск. общества истории древностей российских.— М., 1852.

[7] История Татарии в документах и материалах.— М., 1937; Материалы по истории Башкирской АССР.— М.-Л., 1936.— Ч. 1; Материалы по истории Башкортостана: Оренбургская экспедиция и башкирские восстания 30-х годов XVIII в. / Авт.-сост. Н.Ф.Демидова.— Уфа, 2002.— Т. 6.

җәрәләрдә генә ыру, гаилә, халыкларның күчү нәтиҗәсендә авыллар нигезләү турында мәгълүмат сакланып кала». Без дә, шушы фикернең урынлы булуын искә алып, Марсель абый Әхмәтҗановның әсәрләренә мөрәҗәгать иттек[8].

Китапны хәзерләгәндә Батыршаның дини, рухи остазы Габдеррахман Тайсугани һәм Габдессәлам Ураевның шигъри әсәрләре дә файдаланылды[9].

Татарларны чукындыру төрле риваятьләрдә һәм бәетләрдә дә чагылыш тапкан. Татар риваятьләрен беренчеләрдән булып Каюм Насыйри өйрәнгән һәм шуларны төрле китап-җыентыкларда бастырып чыгарган. Алар арасында христианлаштыруны оештырып йөргән Лука Канашевич — Аксак Каратунга багышланганнары аерым игътибарга лаек[10].

Батырша восстаниесенә караган чыганакларны барлаганнан соң, мондый нәтиҗәгә киләсең: Батыршаның «Өндәмә»се, патшабикә Елизавета Петровнага язган хаты, архивларда сакланган һәм төрле китапларда басылган документлар бу вакыйганы төрле яктан тасвирларга мөмкинлек бирә. Тик бу чыганаклар арасында татарлар тарафыннан татарча язылганнары бик сирәк. Алар шәҗәрә яисә риваятьләр, бәетләр формасында гына сакланганнар.

Төрле җыентыкларда, архив киштәләрендә тузанланып яткан оригинал материалларны файдалану Батырша восстаниесе, фетнәчеләр язмышы турында яңа мавыктыргыч сюжетлар кертеп, заманча тасвирлама бирә торган китап иҗат итәргә мөмкинлек бирде дип уйлыйбыз.

Әлбәттә, Батырша восстаниесен фәнни тикшерү шактый еллар алып барылганлыктан, бу мәсьәлә буенча әдәбият бөтенләй юк дип әйтеп булмый. Бу әдәбиятны без ике төркемгә бүлеп тикшерергә булдык. Беренче төркем Батыршага һәм 1755 елгы восстаниегә багышланган махсус хезмәтләрне эченә алды.

1730 елларда ук Д.И.Языков «Энциклопедический лексикон» дигән китапта Батырша хакында махсус белешмә биргән[11]. Күләме буенча кыска, ләкин шактый тулы бу белешмә Батырша биографиясе буенча мөһим чыганак булып тора.

Хәзерге көнгә кадәр Батырша восстаниесенә багышланган монография булып А.П.Чулошников хәзерләгән китап торганын алдарак әйтеп киткән идек инде. Китап 3 бүлектән тора. Беренче бүлектә сүз 30 — 50 нче еллар — Башкортстандагы сәяси ха-

---

[8] Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре.— Казан, 1995.

[9] Татар әдәбияты тарихы.— Казан, 1984.— 1 т.

[10] Насыйри К. Аксак Каратун турында легендалар // Сайланма әсәрләр.— Казан, 1774.— 1 т.

[11] Языков Д.И. Батырша Алеев // Энциклопедический лексикон.— СПб., 1836.— Т. 5.

ләт, икенче бүлектә — 1755 елгы восстаниене хәзерләү, өченче бүлектә аның барышы һәм җиңелү сәбәпләре турында бара. Моңа кадәр файдаланылмаган архив материаллары киң кулланылып эшләнгән бу хезмәт хәзергә кадәр бу мәсьәләгә багышланган әсәрләрнең нигезе булып кала бирә. Әсәрнең төп кимчелеге — мөселманнарның восстаниесен Башкортстан территориясе белән генә чикләү.

Күп еллар дәверендә башкорт восстаниеләрен фәнни тикшерүдә нәтиҗәле эшне тарих фәннәре докторы И.Г.Акманов алып бара[12]. Ул, Батырша восстаниесен дә тирән тикшереп, шул турыда берничә тарихи очерклар һәм мәкаләләр иҗат итте. Тик бу хезмәтләрдә ислам диненә тискәре караш нык сизелә, чөнки, аның фикеренчә, исламның консерватив тәгълиматлары мөселманнарны христианнарга каршы изге сугышка китерә.

Биредә, И.Г.Акмановтан тыш, Т.Б.Бельская һәм С.М.Васильев хезмәтләрен дә күрсәтеп китәргә кирәк. Т.Б.Бельская, Батырша восстаниесенең характерын анализлаганда, социаль-икътисади сәбәпләргә игътибар итә[13].

Батырша восстаниесен С.Х.Алишев та шул ук күзлектән чыгып тикшерә. Ул архивта сакланган татар чыганакларын куллану белән башкалардан аерыла[14].

Гомумән, XX гасырның 70 — 80 нче елларында Башкортстан галимнәре Батырша восстаниесенә зур игътибар итсәләр, соңгы вакытта бу тема Татарстанда да кызыксыну уята. Бу хакта М.Гайнетдинов һәм Р.Мостафина мәкаләләрен атап булыр иде[15].

Икенче төркемгә Батырша һәм восстание турында сюжетлар кергән Русия яисә Ырынбур губернасы тарихына багышланган күләмле әсәрләрне кертеп булыр иде. Биредә, беренче чиратта, Батырша турында П.И.Рычков әсәрен әйтеп китү зарур. Ул — Батыршаның замандашы, Ырынбур губерна кәнсәләренең күренекле чиновнигы. Рычков Батырша мулланы күргән, аның тышкы кыяфәтен төсмерле алырлык итеп язып калдырган тарихчы. «Топография Оренбургской губернии» дигән китап 1762 елда ук нәшер ителә. Без соңрак басылган китаптан файдаландык.

---

[12] Акманов И.Г. Башкирские восстания в XVIII в.— Уфа, 1987.

[13] Бельская Т.Б. О характере восстания 1755 года в Башкирии // Башкирский гос. ун-т. Ученые записки. Сер. ист. наук.— Уфа, 1970.— № 12.— Вып.54; Васильев С.М. Роль Батырши в восстании 1755 года в Башкирии // Страницы истории Башкирии.— Уфа, 1974.

[14] Алишев С.Х. Каһарман бабайлар.— Казан, 1976.

[15] Гайнетдин М. Батырша // Иман нуры.— 1997.— Июль; Мостафина Р.— Батырша восстаниесе тарихы // Милли мәдәният.— Казан, 2003.— № 3.

Батырша хакында данлыклы тарихчы С.М.Соловьев та үз фикерен язып калдырган. Ул беренчеләрдән булып дини кысрыклауны восстаниенең төп сәбәбе итеп күрсәтә[16].

Патша заманында нәшер ителгән китаплар арасында тарихчы В.Н.Витевскийның фундаменталь хезмәте Батырша турында иң зур мәгълүмат бирүе белән аерылып тора. Монографиянең бишенче бүлеге тулаем Батырша восстаниесенә багышлана. Ырынбур губернасын оештырган, XVIII гасырда Русия дәүләт эшлеклеләре арасында иң талантлылардан булган Петр патшаның сәләтле шәкерте Иван Иванович Неплюевның кызык, мавыктыргыч биографиясе, Уралны колонизацияләү, Уфа провинциясендәге «инородецларның» тормышы, көнкүреше, татарларның һәм башка халыкларның бу якларга күчеп килүе турында кызык материаллар бирелә. Бу китапны патша заманында иҗат ителгән иң төп хезмәт дип атасак, ялгышмабыз кебек[17].

Әлбәттә, В.Н.Витевскийдан башка галимнәр дә Батырша восстаниесен төрле яктан күрсәтергә тырышканнар. Алар арасында Казан университеты профессоры Н.А.Фирсовны һәм академик Н.Ф.Дубровинны аерым атарга кирәк[18].

Батырша җитәкчелегендәге мөселманнарның баш күтәрүен, Русия дәүләтенең дини сәясәтен императрица Елизавета Петровна биографиясенә багышланган хезмәтләрне файдаланмыйча булмас иде. Алар арасында А.Вейдемайер, Н.Костомаров, С.Ешевский китапларын күрсәтергә кирәк. Биредә императрицаның диндарлыгына, дини кысрыклауларга, мәчетләрне җимерүгә игътибар ителә[19]. Соңгы вакытта Е.Анисимов Елизавета Петровна биографиясенә багышланган зур күләмле монография бастырды[20].

Табигый ки, мөселманнарның дини изүгә каршы көрәшен православие дине тарихына багышланган хезмәтләрдән башка язып булмас иде. Алар арасында Казан дини академия профессоры П.В.Знаменский әсәре аерым урын алып тора. Бу китап

---

[16] Соловьев С.М. История России с древнейших времен. Соч. в 18 кн.— М., 1993.

[17] Витевский В.Н. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г.— Казань, 1889 —1897.— Вып. 1—5.

[18] Фирсов Н.А. Инородческое население прежнего Казанского царства в новой России от 1762 года и колонизация закамских земель в это время.— Казань, 1869; Дубровин Н.Ф. Пугачев и его сообщники. Эпизод из истории царствования императрицы Екатерины II. 1773 —1774 гг. По неизданным источникам. В 3 т.— СПб., 1884.

[19] Вейдемайер А. Царствование Елисаветы Петровны.— СПб., 1934.— Ч. 1—2; Костомаров Н. Императрица Елисавета Петровна: Исторический очерк.— Б/м., б/г.

[20] Анисимов Е.В. Императрица Елизавета Петровна.— М., 2000.

«История русской церкви» исеме астында 2000 елда яңадан нәшер ителде. Биредә махсус бүлек «инородецлар» арасында изге православие динен тарату тарихына багышлана. Автор Идел-Урал якларындагы миссионерлык эшен яхшы белгән һәм аны төрле яктан тирәнтен тикшергән[21]. Авторның кайбер карашлары белән килешмәсәк тә, без бу китапны киң файдаландык.

Чукындыру тарихына багышланган миссионер Е.Маловның, А.Можаровскийның, Н.Чернавскийның хезмәтләре дә кулланылды[22].

Совет чорындагы иң яхшы хезмәтләрдән А.Н.Григорьевның күләмле очеркын күрсәтеп булыр иде[23].

Русиядә ислам тарихы, мөселманнарны христианлаштыру татар галимнәре тарафыннан тирәнтен өйрәнелгән дип әйтә алмыйбыз. Шулай да биредә иң беренче Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрен һәм Риза казыйның һ.б.ның хезмәтләрен күрсәтеп киту мөһим[24]. Биредә төрле вакытта яшәгән мулла-мөгаллимнәренең биографиясе, татарларны чукындыру, мәчетләрне җимерү турында кирәкле мәгълүматлар бар. Бигрәк тә Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтләре аерым урын биләп тора. Аның бай мирасында ислам-нәсара мөнәсәбәтләре турында актуальлеген югалтмаган күпкырлы, тирән һәм мөһим фикерләр тупланган. Алар Русиядә ислам тарихын өйрәнү өчен методологик әсбап булып торалар. Русия хакимнәренең чукындыру сәясәтенә күзәтү ясаганнан соң, Ризаэтдин Фәхретдин болай дип яза: «Урыс падишаһларының бу мәмләкәттә булган мөселманнарны чукындыру өчен тырышулары искитәрлек дәрәҗәдә булды. Бу маҗараны тәфсилләп язу — берничә кисәктән торган китап язу белән бер. Безнең моңа көчебез җитми. Болар шушы дәрәҗәдә тырышып та, бу илдә мөселман токымы югалмавы Аллаһы Тәгаләнең ярдәме булса кирәк»[25]. Олпат галимнең без бу сүзләрен киләсе буынга әйтеп калдырган васыять итеп кабул иттек һәм, туган мөмкинчелекләрдән файдаланып, аны тормышка ашырырга тырыштык. Риза Фәхретдин Батырша хакында кыскача биографик

---

[21] Знаменский П.В. История Русской церкви. — М., 2000.

[22] Малов Е. Курс. хезм.; Можаровский А. Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских инородцев с 1552 по 1867 годы.– М.,1880; Чернавский Н. Оренбургская епархия в прошлом ея и настоящем.— Оренбург, 1900.

[23] Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии // Материал по истории Татарии.— Казань, 1948.— Вып. 1.

[24] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.— Казан,1989; Фәхреддин Р. Болгар вә Казан төрекләре.— Казан, 1993; Газиз Г. История татар.— М., 1994; Баттал Г. Казан төрекләре: Тарихи язмалар.— Казан, 1996.

[25] Фәхреддин Р. Болгар вә Казан төрекләре.— Казан, 1993.— 53 б.

белешмә дә хәзерли, тик ул вакытында нәшер ителми. Ул Гайса Хөсәенов эшкәртүендә Батыршага багышланган юбилей-конференция материаллары арасында күптән түгел генә бастырыла. Шушы ук юнәлештә Газиз Гобәйдуллин һәм Габделбари Баттал иҗатын да күрсәтеп була.

А.З.Әсфәндияров, З.А.Ишмөхәммәтов, Н.М.Кульбахтин, Ю.Н.Сергеев, Колшәрипов хезмәтләрендә Идел-Урал якларында мөселманнарны христианлаштыру мәсьәләсе Русиянең колониаль сәясәте күзлегеннән чыгып эшләнә. Совет чорына караган тарихи хезмәтләргә бәя биреп, күренекле тарихчы Андреас Каппелер мондый фикер язды: «Русия мәмләкәтендә, күпмилләтле империя буларак, тарихның четерекле мәсьәләләрен өйрәнү официаль идеология тарафыннан басым алдында булганга күрә, самодержавие дәүләтенең яулап алуын чын мәгънәсендә аклап язарга тиеш иде. Шуңа күрә 1950 —1980 еллардагы тарихи хезмәтләр «халыклар дуслыгы», Русиянең яулап алуын прогрессив күренеш дигән гыйбарәләр белән чуарланырга тиеш иде. Урыс булмаган халыкларның азатлык өчен көрәше реакцион-феодал, ә милли хәрәкәтләр реакцион-буржуаз дип кире бәяләнә иде. Шул ук вакытта Русия дәүләтенең урыс булмаган халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне тарихи яктан өйрәнүгә табу (рөхсәт итмәү) куела иде», — дип дөрес бәяләмә бирде.

Хәзерге заман тарихи әдәбиятын күзәткәндә, без ислам тарихын өйрәнүче В.Г.Садур, Р.Г.Ланда, А.В.Малашенко, Г.Б.Фәизов, А.Б.Юнысова исемнәрен атар идек[26]. Р.Г.Ланда мөселманнарны чукындыру турында бөтенләй язмаса, А.В.Малашенко китабында Русиядәге кыскача ислам тарихы чагылдырыла; ул Русиядә ислам динен азчылык дине икәнлегенә ишарә ясый, мөселманнарны көчләп чукындыруны Явыз Иван һәм Лука атакай Канашевич белән генә бәйләп күрсәтә. А.Б.Юсупова монографиясендә Башкортстандагы ислам тарихы тасвирлана.

А.И.Ногманов, Ф.М.Солтанов, С.Ф.Фәизов, И.А.Гыйләҗев, Д.М.Исхаков китапларында да татар халкын христианлаштыру буенча кызыклы фикерләр бар[27].

---

[26] Садур В.Г. Мусульмане в СССР: История и современность // На пути к свободе совести.— М., 1989; Ланда Р.Г. Ислам в истории России.— М., 1995; Фаизов Г.Б. Государственно-исламские отношения в Поволжье и Приуралье.— Уфа, 1995.

[27] Гилязов И.А. Эволюция социальной структуры татарского общества и ислам (вторая пол. XV — XVIII в.) // Ислам в татарском мире: История и современность.— Казань, 1997; Ногманов А.И. Российское законодательство второй половины XVI — XVIII вв. как источник по истории татарского населения Среднего Поволжья и Приуралья. — Казань, 1994; Исхаков Д.М. Историческая демография татарского народа (XVIII — начало XXвв.).— Казань, 1993 и др.

Чит ил тарихчыларыннан Г.Рорлих, А.Бенигсен хезмәтләре бигрәк тә игътибарга лаек. Алар көнбатыш илләрендә, Русия тарихына объектив караш традицияләрен дәвам итеп, ислам диненең ролен дөрес итеп күрсәтәләр. Алар фикеренчә, Русиядә православие чиркәвенең һәм хакимиятенең башка халыкларны христианлаштыру һәм урыслаштыру сәясәте гасырлар буенча үзгәрмичә дәвам итәлгән[28].

Төрле чыганаклар һәм шушы темага язылган әдәбият белән танышканнан соң, бу тема фәнни яктан тиешле өйрәнелмәгән дигән нәтиҗәгә киләбез. 1755 елгы Батырша восстаниесенең объектив тарихы юк, идеологик сәбәпләр дини һәм милли сәясәтне дөрес күрсәтергә мөмкинлек бирмәде. Күрсәтелгән кимчелекләр Русиядә христианлаштыру сәясәтен, мөселманнарның көчләп чукындыруга каршы көрәшенә, фетнәчеләрнең ачы язмышына кире әйләнеп кайтырга сәбәп һәм этәргеч булды.

Хәзергә кадәр киң кулланылмаган чыганакларны һәм төрле әдәбиятны файдалану Батырша восстаниесен кыска итеп булса да заманча тасвирларга мөмкинлек бирде дигән фикердә калабыз. Бу язманың үзәгендә — татар һәм башка халыкларны көчләп чукындыру, нәсара диненә төрле ысуллар кулланып тарту, мөселман халкының рухи, икътисади, хокукый ээзәрлекләүләргә каршы көрәше, татарны — милләт, исламны дин буларак тәмам юкка чыгару өчен миссионерларның кылган эшләре.

* * *

[28] Рорлих Г. Идел татарлары һәм урыс дәүләте // Мирас.— 1996.— № 7—8.— 200—204 б; Бенигсен А. Мусульмане в СССР // Панорама-Форум.— 1995.— № 2, 3.

Идел-Урал төбәкләрендә мөселманнарны христианлаштыру сәясәте

Русия империясендә 1552 — 1740 елларда дини сәясәт

1554 елны православие диненең үзәге булган Константинополь шәһәрен (хәзер Истанбул) мөселманнар яулап ала. Византия империясе яшәүдән туктый. Шушы ук чорда Мәскәү кенәзлеге Алтын Урда дәүләтеннән бәйсезлек алу өчен көрәш башлый. Бу көрәшнең идеологик нигезе булып «Мәскәү — өченче Рим» дигән гыйбарә ята. Аның төп мәгънәсе — Алтын Урдадан бәйсезлек яулап, яңа дәүләт төзү генә түгел, ә изге православие динен динсезләр, шулай ук мөселманнар арасында киң тарату. Шушы еллардан башлап башка халыкларны христианлаштыру, христиан динен ныгыту Русия дәүләтенең дини сәясәтенең нигезе булып күп еллар үзгәрмичә саклана.

1552 елда Казан ханлыгын җимереп, Әстерхан, Себер ханлыкларын, Ногай Урдасын буйсындырганнан соң, ислам белән көрәш Русия дәүләтенең эчке проблемасына әверелә. Яңа буйсындырылган төбәкләрдә православие динен тарату өчен Казан епархиясе оештырыла. Аның беренче җитәкчеләреннән архиепископ Гурий, Зөядә Богородицкий монастыре архимандриты Герман атакай, Казанда Спас-Преображение монастыре архимандриты Варсонофий атакайга Идел буенда мөселманнар һәм мәҗүсиләр арасында христиан динен уңышлы тараткан өчен, изгеләр исеме бирелә, төбәктә беренче керәшеннәр пәйда була.

Дәүләт җитәкчеләре дә, православие дине әһелләре дә иң беренче христиан динен татар аксөякләре — кенәз-морзалар арасында таратырга тырышканнар. Һәм бу юнәлештә шактый уңышка да ирешәләр. XVII гасыр башларында татар морзаларының 40 проценты чукынган дигән мәгълүматлар бар.

XVIII гасырда Русиядә мөселманнарны һәм мәҗүсиләрне христиан диненә күчерү һәм урыслаштыру сәясәте көчәя. Ул вакытта Русиядәге элита да, урыс кешесе дә мәгърифәтле, төрле яктан яшәү өчен уңайлы, Ходай фатиха биргән илаһи дөнья итеп христиан дине бизәгән һәм православие чиркәвенә буйсынган дөньяны гына атый. Бу илаһи дөнья составына кермәгән киңлекләр, үзләштерелмәгән җирләр үзләренең уңай сыйфатларын югал-

талар, ул җирләрдә кара урман, вәхши-наданнар бушлыгы башлана. Ул кыргыйлар дөньясына цивилизацияле (мәгърифәтле) илаһи Алла дөньясына хас булган кешелеклелек кануннары таралмый. Дини яктан кешеләрне икегә — динсезләргә һәм денсезләргә бүлү тәре йөртүчеләр (крестоносец) өчен генә түгел, урыс миссионерларының православие динендә булмаган халыклар арасында үз-үзен тоту өчен әхлак нигезе булып хезмәт итә. Шулай булганда гына христианнар арасында мөмкин булмаган ысулларны мәҗүсиләр арасында иркен кулланып була. Христос барча халыклар, шулай ук динсезләр өчен дә бик күп газап чигеп үлгәнлектән, миссионерлар башка халыкларны яктылыкка, дөрес, изге дин юлына көчләп өнди алганнар, гәрчә алар үзләре моны теләмәсәләр дә. Христиан динен көчләп таратуга нигез булып түбәндәге фикер яткан: «Урыс чиркәвенә буйсынган һәм христиан дине белән бизәлгән дөнья булып мәгърифәтле, культуралы, Аллаһы Тәгалә хуплаган, ризалыгын биргән дөнья гына санала». Православие динен таратучы миссионерлар да мөселман татарлар һәм мәҗүсиләр арасында динне нәкъ шулай таратканнар.

Тарихи үзгәрүләр нигезендә бер дәүләттә яшәргә мәҗбүр булган мәҗүсиләрне һәм дә мөселманнарны христиан рухында тәрбияләүнең урыс халкына Алла тарафыннан махсус йөкләнгәнлегенә Петр патша чын күңелдән ышанган. Шуңа күрә ул эчке һәм тышкы сәяси мәсьәләләрне православие диненең өстенлеген саклау күзлегеннән чыгып чишкән. Чит дәүләтләр белән килешүләр төзегәндә әлеге мәсьәләгә аерым урын бирелә. Бу хакта мондый мисал китереп булыр иде. Польша белән тынычлык солыхына православие динен кысрыклау булмауны таләп иткән махсус пункт кертелә. Ә Госманлы Төркия белән 1700 елда төзелгән килешүгә Мәскәү дәүләте кешеләренә, дин әһелләренә Фәләстингә хаҗга баручылардан салымнар алмаска, бару өчен грамоталарны бушлай алу мөмкинлеге бирә. Бу килешү Төркиядә Мәскәүдән чыккан дин әһелләренә һәм православие диненә эшәкелек эшләмәскә өнди. Биредә шушы ук вакытта мөселманнарның Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗга бару мөмкинлеге нык чикләнүен күрсәтеп китү дә урынлы булыр.

Татарлар, 150 елдан артык дәвердә баскыннар изүе астында яшәсә дә, үзләренә генә хас дини, рухи үзенчәлекләрне саклап кала алдылар. Русия хөкемдарлары бу вакытта Төркестан, Кырым, Каф тауларында яшәгән халыкларны яулап буйсындыру, Урал-Себер табигый байлыкларын үзләштерү планнарын коралар һәм аларны тормышка да ашыра башлыйлар. Тик бу яңа җирләрне басып алу алдыннан Идел буендагы халыкларны рухи яктан колонизацияләүне тәмамлауны таләп итте. Русия күз салган төрки-мөселман халыкларын яулап алганчы, империянең нәкъ уртасында яшәгән мөселман татарлар каршылыгын юкка чыгару нисбәтеннән аларны чукындырып, урыска әйләндерүне зарур дип тапты.

XVIII гасырның беренче чирегендә Казан губернасында 13322 чукындырылган кеше саналган. Ул вакытта үз диненә тугры булып калганнар саны 285454 кеше булып, чукынганнар барлык татарлар арасында 5 процентка якын өлешне тәшкил иткәннәр. Дамир Исхаков мәгълүматларына караганда, XVIII гасыр башында бөтен Русиядә 17000 керәшен исәпләнгән, бу татар халкының 6,5 проценты; Казан губернасында татарлар арасында керәшеннәр шул ук заманда 9,4 процент тәшкил итсә, Касыйм татарлары һәм, гомумән, мишәрләр арасында чукынганнар саны 2 проценттан артмаган[29]. Башкортстанда ул вакытта керәшеннәрнең барысы 300 хуҗалыгы, ягъни 1000 якын кеше булганлыгы билгеле[30].

Православие руханилары хакимият даирәләреннән урыс булмаган халыклар арасында миссионерлык эшен җәелдерүне таләп итәләр. Аларның мондый теләкләре Петр патшаның уй-фикерләре белән тәңгәл килгән. Уя, Аурупа илләре белән танышып йөргәндә, Амстердам шәһәрендә үз фикерен рәсемгә дә ясап калдырган: христиан диненең ислам динен җиңү символы итеп ярым ай өстенә кулына хач һәм пальма ботагы тоткан фәрештәне утыртып сурәтләгән[31]. Петр патша православие диненең исламны җиңү символын шулай күз алдына китерә, бөтен гомерен, искитәрлек энергиясен Русиядә ислам диненә урын булмаган империячел дәүләт төзү өчен багышлый.

Бөтен татар халкын чукындыруга керешер алдыннан Петр патша татар аксөякләре — морзаларны урыс диненә күчереп бетерүне тели. Сәбәбе: 1704 —1711 еллардагы Идел-Кама буйларында яңа салымнарга түзә алмыйча күтәрелгән восстаниеләрдә морзалар һәм йомышлы татарлар бик актив катнашалар, татар авыллары тирәсендәге урыс авылларындагы чиркәүләрне җимерәләр. Восстаниенең төп оештыручылары морзалар затыннан булганлыгын яхшы аңлаган хакимият бу феодал катлавын бөтенләй юкка чыгару өчен бик мәкерле эш башлый. Русия илендә яшәгән мөселманнарны христианлаштыру һәм урыслаштыру юлында киртә булган авторитетлы аксөяк-морзаларны юкка чыгару кирәклеген патша яхшы аңлаган бугай. Морзаларның язмышында Петрның фәрман-указлары иң мөһим рольне уйныйлар.

1713 елның 3 ноябрендә кабул ителгән указ нигезендә, Казан һәм Азов губерналарында яшәгән мөселман морзаларның утарларында православие динендәге крәстияннәр булса, алар да ярты ел дәверендә чукынырга тиеш булалар; православие

---

[29] Исхаков Д.М. Күрс. хезм.— 56, 94 б.

[30] Социально-экономическое развитие и классовая борьба на Южном Урале и в Среднем Поволжье.— Уфа, 1988.— С. 37.

[31] Соловьев С.М. Күрс. хезм.— 554 б.

диненә күчкән очракта, алар байлыкларын да, биләмәләрен дә, крепостнойларын да саклап калалар. Морзалар ислам динендә калган очракта, аларның биләмәләре крәстияннәре белән бергә патша файдасына күчә[32].

Мөселман морзалар кулында православие динендәге крәстияннәр күп булмаганлыктан, бу фәрман нигезендә чукынырга тиешле морзалар саны әллә ни ишле булмый. Мондый чикләнгән указ хакимиятне канәгатьләндерми. Шуңа күрә өч атна үтүгә, 27 ноябрьдә, яңа фәрман кабул ителә. Указ буенча чукынмаган морзаларның авыллары тартып алынырга, чукыну өчен озак вакыт бирмәскә, дигән кисәтү ясала. Указда ул болай дип теркәлгән: «Деревни, которые за бусурманами, сказать ежели не крестятся все, отнять, и чтоб в том долгову сроку не давать».

Сенаттан алынган указ Казан губерна кәнселәре тарафыннан барча морзаларга һәм йомышлы татарларга вакытында җиткерелә. Ярты елдан Санкт-Петербургка Казан губерна кәнселәреннән җавап килә: морзалар һәм йомышлы татарлар чукынудан бердәм баш тарталар, патшага «без чукынмыйбыз!» дигән җавап юллыйлар.

Биләмәләрендә урыс крәстияннәре булган морзалар саны Казан губернасында ул вакытта күп булмый. Иң күп морзалар (46 кеше) Пенза өязендә яшәгән; аларның биләмәсе унбер авылда булып, утарларында 76 кеше православие динендә исәпләнгән. Тау ягында, ягъни Зөя өязендә, бары тик өч кенә морза исәпләнсә дә, алар карамагында 57 хуҗалык була, димәк, бер морзага унтугыз хуҗалык туры килгән.

Казан вице-губернаторы Н.А.Кудрявцевның Петр патшага юллаган хатына караганда, 1714 елда изге православие динен кабул итмәгән өчен Казан, Зөя, Сембер, Пенза өязләрендәге морзаларның һәм йомышлы татарларның утарлары үзләренең җирләре, тегерманнәре белән патша исеменә тартып алынган. Бу татарлар хәзерге көнгә кадәр үҗәтләнеп изге христиан динен кабул итмәделәр. Алардан тартып алынган крәстияннәр дә хәзерге көнгә кадәр беркемгә дә беркетелмәгән. Патшага малае белән бергәләп хезмәт иткән өчен шул җирләрне, утарларны тегерманнәре белән гомерлеккә үзенә сорый. Бөек патша моңа ризалыгын бирә[33]. Мөмкинчелектән файдаланып, Казан вице-губернаторы морзалар җирен тиз арада үзләштереп тә куя.

1715 елгы мәгълүматларга караганда, Казан губернасында барысы 94 чукынган морза яисә йомышлы татар булган. Кызганыч ки, аларның христиан диненә күчү вакыты күрсәтелмәгән. Шул ук вакытта чукынмаган мөселман морзалар саны — 500,

---

[32] Полное собрание законов Российской империи.— Т. 5.— С. 66—67.

[33] Макаров Д.М. Самодержавие и христианизация народов Среднего Поволжья (XV — XVIII вв.).— Чебоксары, 2000.— С. 143.

йомышлы татарлар саны 4911 була; моннан тыш Пенза өязеннән башка губерналарга күчеп киткән 507 мөселман морза исәпләнгән.

Указны тормышка ашырган вакытта морзаларның утарларында православие динендәге крәстияннәрне исәпкә алып тору булмаганга охшый. Мөселман морзаларның байлыкларын тартып алу башлана. Моның белән килешмәгән морзалар сенатка шәхси яисә күмәкләп шикаятьләр язалар. Беренчеләрдән булып Сембер өязеннән Ибраһим Богданов, Зөя өязеннән Ибраһим Ишеев 1715 елның 28 маенда шикаять җибәрәләр. Ислам динендә калган морзалар православный крепостнойлардан гына мәхрүм ителми, аларны өйләреннән куганнар, җир биләмәләрен, тегермәннәрен, башка байлыкларын тартып алганнар. Урыс хезмәтчеләренең морзалар утарларында юклыгы, ә хуҗалыклары, йорт-кураларының урыслардан аерым булуы да морзаларны бәладән саклап кала алмый.

1715 елның 1 июлендә Казан губернасының төрле өязләреннән морзалар һәм йомышлы татарлар янә сенатка мөрәҗәгать итәләр. Алар патшаларга тугры хезмәт иткән өчен бүләк ителгән урыс крепостнойларын кире кайтаруны үтенәләр. Морзалар мөселманлыкта калган очракта, аларның крепостнойларын тартып алудан тыш, үзләрен өйләреннән куганнар, җир биләмәләрен, тегермәннәрен һәм башка байлыкларын да тартып алганнар. Ислам динендә калган морзалар үзләренә патшага хезмәт иткән өчен бирелгән утарларын, җирләрен, каралты-кураларын, тегермәннәрен, печәнлекләрен калдыруны үтенәләр.

Морзаларны һәм йомышлы татарларны чукындыру хакында сенат 1715 елның 12 июлендә яңа фәрман кабул итә. Бу указ морзаларга чукынмаган очракта утарларын, җир, тегермәннәрен саклап калырга мөмкинлек бирә[34].

Чукынырга ашыкмаган морзаларны һәм йомышлы татарларны тулысынча буйсындыру өчен тагын бер мәкерле эш башкарыла. Аларны, аксөякләр затыннан булуларына карамастан, Санкт-Петербург шәһәрен төзү өчен озаталар. Беренче төркемдә 1255 кеше исәпләнә. Берничә елдан аларны лашманчылыкка беркетеп, чын мәгънәсендә кара халык рәтенә кертү өчен тагын бер адым ясала. Капитал җыеп, халык мәнфәгатьләрен кайгыртырга тиеш булган байлар кыш буе ифрат авыр хезмәттә — Русия хәрби флотын төзү өчен агач кисүдә эшләргә тиеш булалар. Шулай итеп, татар морзалары йә чукынырга, йә булган малыннан мәхрүм калырга тиеш була. Менә шушы еллардан соң татарлар арасында «чабаталы морзалар» төшенчәсе килеп чыга да инде. Морзаларның күбесе, «байлык — бер көнлек, дин — мәңгелек!» дигән фикердә булып, басымнарга бирешмә-

[34] Полное собрание...— Т. 5.— С. 163.

гәннәр, исламга искиткеч тугрылык күрсәткәннәр. Туган якларында яшәргә мөмкинлек калмагач, чукынырга теләмәгән морзалар Урал, Себер якларына күчеп урнашалар һәм миссионерларга каршы ислам дине өчен көрәшне оештыручы булалар. Нижгар якларыннан Башкортстанның Карыш авылына күчеп килгән Батыршаның әтисе Туктаргали абыз да шуларның берсе булганга охшый.

Сакланып калган чыганаклар татар морзалары арасында православие диненә күчүчеләр барлыгын күрсәтә. Кадом өязе Торопов авылында яшәгән Ханя (документта шулай язылган.— *Ф.И.*) Сөнчәләй улы 1720 елны чукынырга теләген белдерә. Шушы елның 3 мартында синод карары буенча аны, христиан дине нигезләре белән танышу өчен, Мәскәүдәге Дини академия каршындагы Спас монастырена озаталар һәм шунда чукындыралар.

1722 елның 7 ноябрендә Кадом шәһәрендә яшәгән морза Шаһгали Алышев Петр патша исеменә үзенең чукыну теләген белдереп хат яза. Хәбәрне алу белән, морза синодка чакырыла, анда аның христиан диненә күчү теләге ныклап тикшерелә. Морзаны православие дине нигезләре белән шул ук Спас монастырендә таныштыралар, 1723 елның февраль аенда шунда ук чукындыралар. Сенат махсус указ нигезендә морзаны өч елга барча салымнардан азат итә һәм лашманчылар белән җитәкчелек итү өчен Воронеж губернасына озата.

Габдеррахман Бәхтияров исемле морза 1729 елның 3 июлендә Мәскәүдәге шул ук Спас монастырендә чукындырыла һәм Иван Авраамов-Кутлин булып яши башлый.

Морзалар турында 1730 елның 6 мартында тагын бер фәрман кабул ителә. Христиан диненә күчерүне тизләтү җәһәтеннән, бу указ нигезендә чукынмаган морзалар авылларын керәшен морзаларга тапшырырга тиеш булалар. Морзалар үзләре яисә туганнары чукынган очракта гына үзләренең утарларын һәм авылларын саклап кала алганнар.

Шулай итеп, Русия патшалары белән православие чиркәве тырышлыгы нәтиҗәсендә татар феодаллары юкка чыгарыла, халык югары аксөяк катлавыннан мәхрүм ителә. Әлбәттә, морзалар, йомышлы татарлар бөтенләй юкка чыкмыйлар, алар, гади крәстиян дәрәҗәсенә төшерелгән очракта да, җәмгыятьтә үзләренә хас урынны саклыйлар. Шулай да татар морзаларын юкка чыгару сәясәтен халкыбызны бетерү өчен кылынган махсус эшләр рәтенә кертергә мөмкин.

Ризаэтдин Фәхретдин татар морзаларын кимсетә торган бәяләмә язып калдырган: «Русларны һәм славяннарны «Россия мәмләкәте» хәленә китерүчеләр, Екатерина иярченнәре булган немецлардан бигрәк, чукынган татар кенәзләре һәм морзалары булды. Болар үз хөкүмәтләрен тәртипле һәм мәдәниятле бер хөкүмәт ясый алмасалар да, үз өлкәләрен үз кулларында тоту

хакында чаралар табуга яраклы булмасалар да, «Олуг Россия» исемле мәмләкәтне төзү хакында руслардан артык хезмәт күрсәттеләр»[35]

Петр патша заманында Русиядәге урыс булмаган халыкларны христианлаштыру темпын үстерү нисбәтеннән төрле яңа чаралар эшләнә. Христианлаштыру процессын тизләтү юнәлешендәге материаль һәм социаль стимуллар мәмләкәттә православие динен җитәкләү өчен төзелгән оешма — синод оештырылгач тизләтелә. Шушы ук елларда православие динен кабул итүчеләр өчен төрле өстенлекләр закон буенча бирелә. Иң беренче булып яңа чукынганнарны барча салым түләүдән 3 елга азат итәләр; шул ук вакытта керәшен авылларында чиркәүләр төзү өчен елына 1 мең тәңкә акча бүлеп бирелә. Петр патшаның имзасы куелган указ нигезендә 1722 елда рекрутларны, үзе теләп чукынган очракта, хәрби хезмәттән азат итәләр. 1724 елда чукынганнарны бурыч түләүдән, ә җинаятьчеләрне төрмәдән азат итү турында указлар кабул ителә. Христиан динен кабул иткәннәр өчен бу махсус өстенлекләр зур стимул булса, үз диннәрендә тугры калучыларда ул нәфрәт уята. Керәшеннәргә мөселманнар һәм мәҗүсиләр үз диннәрен сатучылар дип кенә түгел, ә хаксыз өстенлекләр алган кабахәт дип карыйлар. Тик бу кылган эшләрнең файдасы гына чамалы була.

Казан митрополиты Сильвестр мәгълүматларына караганда, 1719 елдан 1730 елга кадәр яңадан 2160 кеше православие диненә күчә, димәк, бу ел саен 200 тирәсе кеше чукынган дигән сүз. Әлбәттә, чукындыру эше бу тизлектә барса, аның иге-чиге күренмәс иде, шуңа күрә бу вазгыять белән Русия хөкемдарлары да, миссионер руханилар да риза була алмыйлар.

Формаль яктан православие диненә күчкән булып саналган мөселманнар һәм мәҗүсиләр, чынбарлыкта нәсара дине кануннары буенча яшәмичә, үз диннәренә тугры булып калганнар. Бу хакта Казан митрополиты Тихон 1722 елның 11 гыйнварында болай дип яза: «Яңа чукынганнар чиркәүгә йөрмиләр, попларны өйләренә чакырмыйлар, тәүбә итмиләр, үлгәннәрне урыс руханиларын чакырмыйча җирлиләр»[36].

Шул ук хакта икенче Казан митрополиты Сильвестрның 1729 елда язган хәбәре дә сөйли. Ул, Казан өязе Җөри юлындагы Әбди авылында керәшеннәрне күреп киткәннән соң, синодка борчу хатын юллый (хат текстын урысча бирәбез): «Крещеные татары почти не соблюдают нормы православной веры, не умеют и молитву Иисусову творить: крестное знамение воображать и закон христианский в твердости исполнять и содержать от не-

---

[35] Фәхреддин Р. Курс. хезм.— 50 б.
[36] Описание документов...— Т. 1. — С. 364—365

научения и непризрения не умеют: в господские праздники и воскресные дни к церкви божией с женами и детьми приходить они новокрещены и сопраздновати и молитися и по христианской должности и грехов своих исповедатися и святых таин причащатися не сподобляются: а мертвые их новокрещенские тела на их старых новокрещенских кладбищах, на полях и лесах, по татарскому обычаю, сами собою, а не у церкви божией, без священника погребают, а рождающиеся их новокрещенские младенцы за дальностию приходских церквей бывают без крещения своими младенцами дают имена татарским званием»[37].

Мондый шөбһәле хәбәр алганнан соң, кирәкле чаралар эшләнелә: авылда чиркәү төзелә, Лаеш якларыннан бирегә урыслар күчерелә, чукынган татарлар өстеннән күзәтү көчәйтелә, соңыннан керәшен һәм урыс балалары өчен мәктәп тә салына. Авыл унтугызынчы гасырның икенче яртысында тулысынча диярлек урыслаша.

Әлбәттә, мондый хәбәрләрне алгач та синод керәшеннәрдә православие динендә ныгыту, башка халыкларны урыс диненә тарту турында кискен чаралар күрергә ашыга. Православие руханилары бу мәсьәләдә Русия хакимияте белән уртак тел табалар, дөресрәге, бер юнәлештә сәясәт алып баралар. Православие руханилары, күпләп чукындыру нәтиҗәсендә яңа чиркәүләр ачып, үзләренә эш табу белән беррәттән, патшага булган йогынтыны да үз файдаларына үзгәртергә тырышканнар. Руханилар һәм дә хакимият даирәләренең бергә, кулга-кул тотып эшләгәндә генә көчләп чукындыру сәясәтен тормышка ашыру мөмкин булуны алар яхшы аңлаган, күрәсең.

Керәшеннәргә өстенлекләр бирүче кануннар да, православие миссионерларының шашып мөселманнар арасында хезмәтләре дә урыс булмаган халыкларны христианлаштыру мәсьәләсен чишә алмыйлар. Чукындыру сәясәтенең яңа баскычы 1731 елның 23 августында, Казан епархиясендәге мөселманнарны һәм башка халыкларны чукындыруны тизләтү нисбәтеннән чыгарылган указдан башлана. Указ буенча махсус чукындыру кантуры төзелә һәм ул Зөя (Свияжск) шәһәрендә 1556 елда татарларны беренче чукындыручылардан булган миссионер «изге» Герман төзегән Богородицкий монастырена урнаштырыла. Казан ханлыгын җимерүне Зөя шәһәрен төзү белән бәйләгән урыс руханилары татар һәм башка халыкларны рухи яктан кол итү эшен дә шушы шәһәрдә урнаштырып, үзләрен бу сәясәтне дәвам итүче варислар итеп күрсәтергә телиләр. Явыз Иван нигез салган Зөя кальгасы Казан ханлыгын яулауда нинди урынны тотса, мөселман һәм мәҗүси халыкларын чукындыруда да бу шәһәргә

---

[37] Православный собеседник.— 1858.— Ч. 3.— С. 234—236.

шундый ук урын бирелә. Биредә тагын шуны искәртеп китәргә телибез: кайбер галимнәр чукындыру кантуры Казанда урнашкан дип ялгыш күрсәтәләр[38].

Зөядәге Богородицкий монастыре архимандриты итеп миссионерлык эшендә зур тәҗрибә туплаган иеромонах Алексий Раифский билгеләнә һәм ул урыс булмаган халыкларны чукындыру эшен оештырырга тиеш була. Бу изге эшне ул 1738 елның ахырына кадәр диярлек алып бара. Монастырь турыдан-туры изге синодка буйсындырыла, ә Казан митрополиты Сильвестр бу монастырь белән җитәкчелек итүдән мәхрүм ителә. Указ нигезендә Алексий Раифскийга ике зур вазифа йөкләнә: ул берьюлы монастырь җитәкчесе дә, махсус чукындыру кантуры җитәкчесе дә була. Бу махсус оешма тарихта «Новокрещенская контора» яисә «Контора новокрещенских дел» исеме астында билгеле.

Алексий Раифский инде ул вакытта шактый тәҗрибә туплаган күренекле рухани-миссионер була. Сакланып калган документларга караганда, ул әтисе белән XVIII гасыр башында 3683 чирмешне чукындыра, алар өчен хөкүмәт акчасына җиде чиркәү дә салдыра. Чукындыру кантуры җитәкчесе итеп билгеләгәндә, әлбәттә, Алексий Раифскийның элекке миссионерлык хезмәте дә исәпкә алынгандыр.

Алексий Раифский тырышлыгы белән Зөядәге Богородицкий монастыре чукындыру үзәгенә әверелә. Христиан диненә күчәргә «теләүчеләрне», төрле төбәкләрдән Зөягә алып килеп, Гайсә пәйгамбәр Иордан елгасына кереп чукынса, бирегә җыелган халыкны да Зөя елгасына кертеп чукындырганнар. Ул хакта махсус дәфтәрләргә дә теркәп куйганнар. Төрмәләргә ябылган мәҗүси һәм мөселманнар православие диненә күчү теләге белдерсәләр, гаскәриләр ярдәмендә шушы монастырьга китерелгәннәр һәм чукындырылганнар, шул рәвешчә, җинаятьтән азат ителгәннәр. Чукындыру өчен монастырьда махсус урын — крещальня ясала һәм ул изге пәйгамбәр Илья чиркәвенә урнаштырыла[39].

Чукындыру комиссиясенең тырышлыгы православие диненә күчүчеләр санын аз гына булса да арттыруга китерә. 1732 елда

---

[38] Казанское востоковедение: Традиции, современность, перспективы.– Казань, 1997.— С. 272; Султанов Ф.М. Ислам и татарское национальное движение в Российском и мировом мусульманском контексте: История и современность.— Казань, 1999.— С. 51; Кульбахтин Н.М., Сергеев Ю.Н. Религиозная политика царизма в Башкирии // Социально-экономическое развитие и классовая борьба на Южном Урале и в Среднем Поволжье.— Уфа, 1988.— С. 38.

[39] Яблоков А. Город Свияжск Казанской губернии и его святыни: Историко-археологический очерк.— Казань, 1907.— С. 78.

201 кеше булса, 1733 елда 290 кеше христиан диненә күчә. 1733 елда чукындыру өчен 1047 сум 37 тиен акча сарыф ителә. Димәк, һәр керәшен казнага 3 сум 61 тиенгә төшә[40].

Алексий Раифский 1738 ел тәмамланганчы чукындыру конторы җитәкчесе булып кала һәм миссионерлык эшен дәвам итә. Синод, 1738 елның 23 октябрендә указ чыгарып, Алексий Раифскийны ялга озата. Чөнки авырып, сөйләшә алмаслык хәлгә җиту сәбәпле, ул инде архимандрит булып та, чукындыру конторы җитәкчесе булып та хезмәт итә алмаган. Алексийның элеккеге хезмәтләрен искә алып, аны монастырьда калдыралар: 3 монахка тиешле аш-су бирелә, аны күзәтеп тору өчен махсус кеше дә билгеләнә, төрле төбәкләрдә миссионерлык эшен дәвам иту өчен 2 — 3 ат та калдырыла[41].

Алексий Раифскийның Идел буе халыкларын чукындыру эшләренә нинди бәя биреп булыр иде? Чукындыру конторы миссионерлары тырышлыгы белән утызынчы елларда христиан диненә күчүчеләр шактый арта. 1731 елда алар саны 108 булса, 1738 елда ул сан-318гә җитә, уртача елына 267,5 кеше чукына. Чукынганнарның иң күп саны 1734 елда була һәм ул 508 кешегә җитә. Барысы сигез елда 2140 кеше чукындырыла[42].

Чукынган кешеләрнең нинди халык вәкилләре икәнлеген күз алдына китерү өчен, без түбәндәге саннарны китерәбез: 1733 — 1734 елларда барысы 705 кеше чукынган булса, аның 24е мөселман булган[43]. Димәк, христиан диненә күчүчеләрнең 3,4 проценты элек ислам динендәге татар һәм башкортлардан булган.

Татарлар арасында христианлаштыру процессының активлашуы бу процессны Башкортстанга да җәелдерүгә китерә. Элегрәк Башкортстанда миссионерлык эше юк дәрәҗәдә булса, 1736 елдан Ык буенда Ногайбәк крепосте төзү белән бередә дә христианлаштыру актив үткәрелә башлый. 1736 елда татар абызларының, муллаларының, ахуннарының халык арасындагы йогынтысын киметү өчен махсус карар кабул ителә. Русиянең колониаль сәясәтенә каршы 1735 —1740 елларда булган восстание вакытында фетнәчеләр керәшеннәрнең 300 утарын яндыралар. Восстание оештыруда дин әһелләре дә гаепләнә. Ырынбур комиссиясе җитәкчесе И.К.Кириллов фикеренчә, башкорт илендә мөселман дин әһелләре гадәттә Казан ягыннан. Минемчә, ахуннар саны унга җитә. Аларның ни белән шөгыльләнүләре, кем тарафыннан куелулары турында Уфада билгеле түгел. Бирегә күчеп килгән ахуннарны, муллаларны, абызларны яманлыкта га-

[40] Описание документов...— С. 379.
[41] Описание документов...— Т. 19.— С. 196.
[42] Ислаев Ф.Г. Православные миссионеры в Поволжье.— Казань, 1999.— С. 15 —16.
[43] Макаров Д.М. Курс. хезм.— 219—220 б.

еплэп була; алар үз диннәрен чуаш һәм мордвалар арасында гына түгел, хәтта бирегә качып килгән урыслар арасында да тараталар, аларны сөннәткә утырталар, моңа кадәр булмаган санга мәчетләр һәм мәктәпләр санын күпкә арттыралар. Кириллов һәр юлга бер ахун, аларны хакимияткә тугрылыгы турында ант иттерү, халыкның уй-фикерен тиз арада администрациягә хәбәр итү, мари, чуаш, удмурт, мордвалар арасында ислам динен таратмау, яңа мәчетләр төзергә рөхсәт итмәү турында тәкъдим ясый. Бу тәкъдимнәрне сенат кабул итә. Шул ук вакытта Русия дәүләтенә каршы чыккан фетнәләр вакытында халык Коръән Кәримгә ант иткән Әзәй мәчете җимерелә.

Башкортларны христианлаштыру 1735—1740 еллардагы восстаниене бастырганда бик киң кулланыла. Шул елларда 11500 кеше, фетнәче дип гаепләнеп, урысларга кол итеп тапшырыла. Алар барысы да православие динен кабул итә[44]. Шул вакытларда кечкенә башкорт балаларының кол ителеп урыс алпавытларына бүләк ителүе һәм аларның чукынуы турында шактый материаллар «Материалы по истории Башкирской АССР» дигән җыентыкта бар. Шуларның кайберләрен күрсәтеп китәбез. 1737 елның җәй аенда хатын-кызлардан һәм кечкенә малайлардан 300 кеше чукындырыла. Төрле елларда әсир итеп алынган башкортлардан Федор Семенов, Курмангол Җаекбаев, Алексей Иванов; балалардан Хәнәмбикә Үтәгәнова (15 яшь), Прасковья Иванова (10 яшь), Екифор Дмитриев (4 яшь), Икбирде Акманаев (6 яшь), Әбди Нурмәтов (8 яшь), Габдел Сәитов, Ука Мултаева (13 яшь), Имәнәй Иванаев (7 яшь), чукындырылып, Русиянең үзәк районнарына күчерeләләр[45]. 1740 елда Санкт-Петербургтагы төрле чиркәүләрдә 7 яшьлек Солтанморат, 6 яшьлек Собхангол, 18 яшьлек Елгаш, 7 яшьлек Екатерина, 4 кечкенә татар һәм башкорт чукындырыла[46].

Дәүләт органнары һәм православие чиркәве христиан диненә күчкәннәрнең дин тотуларын һаман күзәтеп тора. Ул заманда 1649 елгы Уложение буенча православие динен кабул иткән кешегә кире элекке диненә кайту катгый тыела, ә бу тыюны бозган кешене исә утта тере килеш яндыру карала. 1738 елның 20 июнендә, Екатеринбург каласында мәҗүсиләрне һәм мөселманнарны, керәшеннәрне җыеп, Туйкилде Жуляков исемле баш-

---

[44] Рычков П.И. История Оренбургская.— Оренбург, 1896.— С. 56; Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание.— Уфа, 1999.— С. 19.

[45] Материалы по истории Башкортостана. Оренбургская экспедиция и башкирские восстания 30-х годов XVIII в.— Уфа, 2002.— С.424; Материалы по истории Башкирской АССР.— Т. 3.— С. 359—363, 368, 371—373, 376, 382—383; Т. 5.— С. 542—543.

[46] Описание документов...— Т. 20.— С. 137, 165, 199, 295, 305, 618.

кортны утта яндыралар. Ул, 1735 елгы фетнәдә катнашып, әсир төшә, тик чукынып җәзадан азат ителә һәм туган якларына кайтып китә. Туган ягында ул яңадан мөселманча яши башлый. Ырынбур комиссиясе җитәкчесе итеп куелган В.Н.Татищев 1738 елның 11 мартында Минзәләдән Теча бистәсенә указ юллый. Указ буенча Себер драгун полкы командиры полковник Арсеньев Туйкилде Жуляковны гаиләсе белән Екатеринбургка озатырга тиеш була. Ә Екатеринбургта майор Угримов Туйкилдене, чукынганнан соң яңадан ислам динен кабул иткәне өчен, башкаларны куркыту йөзеннән, бөтен керәшен татарларын җыеп яндырырга тиеш була. Аның хатынын, балаларын рус шәһәрләренә таратырга, ике малаен үзенә, Самарага җибәрүне таләп итә.

Туйкилде Жуляков керәшеннәр алдында утта яндырыла. Аны ут өстенә куяр алдыннан В.Н.Татищевның указы укыла. Анда мондый сүзләр дә бар: «По указу Ея императорского величества самодержицы Всероссийской и по определению его превосходительства Тайного советника Василия Никитича Татищева, велено тебя, татарина Тойгильду, за то, что ты, крестясь в веру греческого исповедания, принял паки махометанский закон, и не только что в богомерзкое преступление впал, но яко пес на свои блевотины возвратился, и клятвенное свое обещание, данное при крещении, презрел, чем Богу и закону его праведному учинил великое противление и ругательство, — на страх другим таковым, кои из махометанского приведены в христианскую веру, при собрании всех крещеных татар велено казнить смертию — сжечь»[47].

Бу чукынган керәшенне беренче генә яндыру булмый. Шушы тирәдә урыс диненнән яһүди диненә кире әйләнеп кайткан капитан-лейтенант Возницын һәм аны яһүди диненә кайтырга өндәгән Борох Лейбов утта яндырылалар. 1740 елда христиан динен кабул иткәч, Роман Исаев булып киткән татар керәшене дә утта яндырыла. Ул хатыны белән парлап православие динен кабул итә. Башта алар Казан өязе Ташкирмәндә керәшеннәр арасында яшиләр, аннары Уфа өязенә күчеп киләләр. Бирелә яшәгәндә ул ислам дине тәгълиматлары нигезендә яши башлый. Килмәк абыз фетнәсендә катнаша, сугышта әсирлеккә төшә. Фетнәчеләр арасында аның мөселманча яшәгәнлеге билгеле булгач, Санкт-Петербургка алып киләләр һәм җәзалап сорау алалар. Тикшерү тәмам булгач, мондый карар чыгарыла: Исаевны гаепле дип танырга, Минзәләгә кире кайтарып тормыйча, Санкт-Петербург шәһәрендә җәзалап үтерергә; туган ягына кай-

---

[47] Анисимов Е.В. Дыба и кнут: Политический сыск и русское общество в XVIII веке.— М., 1999.— С. 541—542.

тарган очракта, ул юлда качып китәргә һәм фетнәдә яңадан катнашырга мөмкин[48].

1738 елның ахырында чукындыру контурының яңа җитәкчесе итеп билгеләнгән архимандрит Димитрий Сеченов, миссионерлык эшен нигездән үзгәртеп корып, барча мөселман һәм мәҗүсиләрне православие диненә күчереп, урыслаштыру сәясәтен тормышка ашыра башлый. Лука Канашевичны Казан епархиясе епископы итеп билгеләү, чукындыру контуры җитәкчесен алмаштыру — болар барысы да татар халкын көчләп чукындыруны, урыслаштыруны тизләтү җәһәтеннән кылынган үзгәрешләр. Канашевич, Сеченовлар мөселман һәм мәҗүсиләрне көчләп күпләп чукындыру сәясәтенә нигез салалар һәм аны гамәлгә дә ашыралар. Бу миссионер-руханилардан чукындыруның яңа бер чоры башланып китә.

Менә шундый дини эзәрлекләүләр булуга карамастан, кайбер тарихчылар Анна Иоанновна чорында Русиядә гореф-гадәтләр йомшару, башка диннәргә карата түземлелек (толерантлык) формалашуы турында язалар. М.М.Богословский Русиядә немецлар заманында дини түземлелек турында фикер йөртсә, хәзерге заман тарихчысы Н.Н.Петрухинцев XVIII гасырның 30нчы елларында Башкортстанда көчләп христианлаштыру булмавы турында яза[49]. Югарыда күрсәтелгән мисаллар Русиядә дин мәсьәләсендә ситуация икенче төрле икәнлеге турында дәлил булып тора.

Мөселман татар халкын чукындыру сәясәтендә чын мәгънәсендә яңа чор императрица Анна Иоанновна 1740 елның 11 сентябрендә тамга салган указдан башлана. Бу указ күп еллар мөселманнарны һәм мәҗүсиләрне көчләп чукындыру буенча руханилар һәм хакимият даирәләре өчен законлы нигез булып хезмәт итә.

Кыска гына кереш сүздән соң чукындыруны камил оештыру буенча бихисап киңәшләр бирелә. Указ нигезендә архимандрит Димитрий Сеченов һәм аның ярдәмчеләре урыс булмаган халыклар арасында нәсара динен киң таратуны дәвам итәргә тиеш булалар. Бу «Аллага яраклы эшне» Казан епархия җитәкчесе күзәтүе астында, аның фатихасын алып эш итү кирәклеге күрсәтелә.

Һәр нәсара диненә күчүчене иң мөһим булган христиан кануннарын һәм риваятьләрне, догалардан «Отче наш», «Богоро-

---

[48] П о п о в Н. В.Н.Татищев и его время. Эпизод из истории государственной и частной жизни в России первой половины прошедшего столетия.— М., 1861.— С. 206.

[49] Б о г о с л о в с к и й М.М. История России XVIII в. (1725 —1796 гг.).— М., 1915.— С. 135; П е т р у х и н ц е в Н.Н. Царствование Анны Иоанновны: Проблемы формирования внутриполитического курса: Дис. ...д-ра. ист. наук.— М., 2001.— С. 443.

дице Дево», «Символ Веры» һәм башкаларны өйрәтү карала. Урыс булмаган халыклардан чукынырга теләмәүче табылса, аларны көчләп, куркытып чукындыру тыела, миссионерлар, Гайсә пәйгамбәр шәкертләре шикелле вәгазь укып, тыйнаклык, тынычлык, сабырлык күрсәтеп, масаймыйча, христианлыкка өндәргә тиеш булалар. Әлбәттә, биредә язылган сүзләр тормышка ашырылган нисбәттә, православие диненә башка халыкларны өндәү икенче юнәлештә киткән булыр иде. Тик аларның тормышка ашырылу мөмкинлегенә указны язган авторлар үзләре дә ышанмаган бугай, чөнки югарыда күрсәтелгән изге сүзләрдән соң ук миссионерларны саклау өчен гаскәри-солдатлар кирәк булуы турында искәртелә. Тик гаскәриләр сагы астында изге эшләр эшләнә микән соң дигән урынлы сорау туа.

Указ чукынган кешеләр өчен чиркәүгә йөрү тәртибен дә кертә. Алар православие дине кануннары буенча иренмичә чиркәүгә дога кылырга, Аллаһыны мактау өчен килергә тиеш булалар. Бигрәк тә күзәтү керәшеннәр — чукынган татарлар өстеннән кискенләштерелә һәм бу вазифа чукынган татарлар белән бергә яшәүче урысларга тапшырыла. Керәшеннәр чиркәүдә тәүбәистигъфар кылырга, мөмкин булганча мөселманнар белән аралашмаска тиеш булалар: алар арасында иренеп чиркәүгә йөрүчеләр булса, аларга акчалата штраф салу урынына җиңелчә чиркәү епитимиясе, ягъни чиркәүдә халык алдында, гөнаһлы булуны танып, берничә мәртәбә баш ию, бил бөгү дә аларга җитә дип карала. Православие динен һаман бозып торучыларга карата указ акчалата штраф салу мөмкинлеген дә күрсәтә. Дин бозу очраклары билгеле булса, ул тиз арада, ягъни өч көн эчендә тикшерелергә тиеш була.

Указның бер пункты урыслаштыру сәясәтен аеруча җентекләп карый. Башта керәшеннәр урыслар белән өйләнешеп, гаилә кору юлы белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру карала: керәшеннәр йортында урыслардан кияү яисә килен булган очракларда, алар христиан диненә каршы эшләр кылмас, элекке диннәрен әкренләп онытырлар, диелә. Урыслар кызларын керәшеннәргә кияүгә биргән очракта, алардан калым сорамаска тиеш булалар; ә керәшеннәргә, чын мәгънәсендә православие диненә күчкәч кенә, үзара өйләнеп, гаилә кору мөмкинлеге бирелә.

Беренче мәртәбә указда чукынган һәм христиан диненә күчмичә калган мөселман һәм мәҗүсиләрне яшәгән урыннарыннан күчереп утырту мәсьәләсе карала. Указның авторлары чукынганнар белән мөселманлыкта һәм мәҗүсилектә калган кешеләрнең бергә яши алмаганлыгын яхшы аңлаганнар булса кирәк. Әлбәттә, алар бу хакта дөрес уйлаганнар, чөнки керәшен белән мөселман бергә яши алмый. Керәшеннәрне мөселманнардан аеру өчен, указ нигезендә аларны урыслар яисә элек чу-

кынганнар (мәкруһ — старокрещеныйлар) арасына күчереп, яңа урында аларга элеккеге урындагы шикелле җир биләмәсе бирү карала. Күченүдән күп зыян чыкмасын өчен, чукынганнар һәм чукынмаганнар, бер-берсе белән килешеп, йорт-кураларын алмаштырырга тиеш булалар: йортларның бәясе төрле булганда, аерманы килешеп түләү карала. Бу ифрат четерекле эшне башкару өчен махсус кеше билгеләнә, ә аңа исә яхшы хезмәт хакы түләнә.

Керәшеннәрне күчереп утырту өчен Сарытау һәм Царицын арасында җир бүлеп бирелә. Бу махсус урында авыллар салу, ә авылда һәрбер 250 йортка бер чиркәү төзү кирәк дип табыла; һәр чиркәүдә алты рухани керәшеннәрне, көне-төне күзәтеп, нәсара диненә өйрәтеп торырга тиеш була. Керәшеннәргә бу якларга күчеп утыру өчен, рөхсәтне чукындыру кантуры үзе бирә. Яңа авылларда староста итеп керәшеннәр сайланып, алар авыл халкы арасында тәртип сакларга, керәшеннәрне кыерсыту очрагы була калса, алар воеводаларга яисә Казан губерна кәнселәренә хәбәр итеп торырга тиеш булалар; шикаятьләрне тиз арада тоткарлыксыз тикшерү карала.

Указ буенча урыс диненә күчкән керәшеннәргә шактый льготалар карала. Беренчедән, христиан диненә күчкән һәрбер кеше өч ел салым түләүдән азат ителә; керәшеннәр түләргә тиеш салым чукынмаганнар өстенә салына. Икенчедән, заводларда эшләргә тиеш керәшеннәр бу эштән шул ук вакытка азат ителә. Өченчедән, керәшеннәр өч ел рекрут озатмый һәм рекрутларны җыю өчен акча да бирми. Рекрутларны керәшеннәр өчен мөселманнар өстәмә җыярга тиеш була. Чукынган кешегә бу указга кермәгән тагын зур өстенлек бирелә: әгәр син җинаять кылып җаваплылыкка тартыласың икән, үзең теләп чукынгач ук, сине җавап бирүдән азат итәләр.

Татарларны һәм мәҗүсиләрне православие диненә күчүдә кызыксындыру өчен төрле бүләкләр дә бирелә: ярлыларга, кара халыкка — җиздән эшләнгән тәре, күлмәк, кафтан, бүрек, бияләй, аяк киеме; баеракларга — көмеш тәре, сукнодан кафтан, итек, күлмәк; болардан башка һәрбер керәшенгә илле тиеннән бер сум илле тиенгә кадәр акчалата бүләк тә билгеләнә. Гаиләләре белән чукынган очракта керәшеннәргә өй почмагына куяр өчен икона да тапшырыла.

Чукындырылган мөселманнар һәм мәҗүсиләр арасыннан миссионерлар хәзерләү нисбәтеннән указ Казандагы Федоров монастыренда, Алабугада, Цивильскида, Царево-Кокшайскида —барысы дүрт урында махсус керәшен мәктәпләрен ачуны карый. Мөселманнар һәм мәҗүсиләр яшәгән төрле төбәкләрдә урнашкан бу мәктәпләр татар, башкорт, чирмеш, чуаш, мордва, ар-удмурт халыкларыннан миссионерлык эшен алып барырлык руханиларны хәзерләүне күз алдында тота.

Чукындыру кантурын тоту һәм миссионерлык эшен мөсел-

маннар һәм мәҗүсиләр арасында алып бару өчен, хөкүмәт казнадан ел саен 10000 сум акча бүлеп бирә. Ә азык-төлекне Димитрий Сеченов мөселманнардан һәм мәҗүсиләрдән үзе теләгән урыннан җыеп ала алган. Указ нигезендә Зөя монастыре кырында чукынырга килгән кешеләр өчен фатирлар төзү дә карала. Алар бирегә чукынырга, үгет-нәсихәт, христиан диненең нигезен төшенер өчен килергә тиеш булалар[50].

Шушы 23 пункттан торган указ нигезендә Идел-Урал якларында һәм башка төбәкләрдә татарларны чукындыру сәясәте көчәйгәннән-көчәя бара. Указдагы көчләмичә, Гайсә пәйгамбәр шикелле үгетләп чукындыру таләбе тиздән онытыла, чөнки татарлар арасында үзе теләп чукынучылар бик сирәк табыла. Халыкны төрле яктан бик каты көчләү, дини һәм милли эзәрлекләү, җәберләү башлана, татарны — милләт, исламны дин буларак юкка чыгару өчен канлы көрәш кызганлыктан, татар авылларында тормыш мәхшәргә әверелә.

Афәт: мөселманнарны 1741 — 1755 елларда күпләп чукындыру

Патшабикә Анна Иоанновна 1740 елның 11 сентябрендә имза салган указ тормышка ашырылу Петр патшаның яраткан кызы Елизавета Петровнаның 20 еллык патшалык елларына туры килә, чөнки Анна, патша указ чыгарган көннән бер ай чамасы вакыт үтү белән, фани дөньядан китә. Русия империясенең төрле почмакларында барган христианлаштыру сәясәтенең нәтиҗәсе итеп Урал-Идел якларында яшәгән мәҗүси халыкларының бөтенесен диярлек, өлешчә татарларны чукындырып, бу халыклардан керәшеннәр ясауны санап булыр иде. Елизавета Петровна хакимлек иткән еллар турында язучы галимнәр, гадәттә, шушы елларда урыс булмаган халыкларны көчләп чукындыруны искә алмаска, ә патшабикәнең мәрхәмәтлелегенә, ул чорда үлем җәзасы кулланмауга игътибарны җәлеп итәргә тырышалар. Күренекле тарихчы С.В.Ешевский Елизавета Петровна турында мондый фикер яза (текстны татарча бирәбез): «Елизавета Петровна хакимлеге еллары дәүләтнең эчке төзелеше хакында озакка сузылган истәлекле еллар дип әйтеп булмый. Ул заманда илдә үзгәртеп кору кирәк булуга карамастан, 20 ел буена дәүләт учреждениеләрендә кискен үзгәрешләр сизелми. Хакимият карарларында без гомуми план, тәртипне бик тырышып эзләсәк тә таба алмабыз»[51]. Тик мондый бәяләмәне без дини сәясәткә

[50] Полное собрание...— Т. 11.— С. 248—256.

[51] Е ш е в с к и й С.В. Очерк царствования Елизаветы Петровны // Сочинения по русской истории.— М., 1990.— С. 112.

карата әйтә алмыйбыз, чөнки бу өлкәдә Русия тарихына хас булмаган эзлеклелек һәм максатка омтылышлылык күренә.

Шулай да кайбер тарихчылар Елизавета Петровнаның дини сәясәте үзенчәлекләре хакында аз булса да фикерләрен әйтергә мәҗбүр булалар. Мәсәлән, М.М.Богословский Елизавета Петровна чорында Христос исемен ишетә алмаган яһүдиләрне кысрыклауга, аларны илдән куып чыгаруга һәм аларны Русиягә кертмәүгә игътибар итә. Яһүдләрне куып чыгарганда, Русиядә сату-алуга зур зыян килергә мөмкин, дигән кисәтүгә, патшабикә: «Христосның дошманнарыннан бернинди дә керем безгә кирәкми!» — дип җавап бирә. Хәзерге заман тарихчысы Е.В.Анисимов Елизавета Петровнаның дини сәясәтен аның характеры белән бәйләп карарга тырыша. Ул болай дип аңлата: «Ул хакимлек иткән елларда православие динен элеккечә тоткан «старообрядецлар» белән көрәшү турында указлар чыгарыла. Качып урманнарда яшәгән старообрядецларның Петр патша заманында шикелле үзләрен-үзләре утта яндыруы яңадан кабатлана. Русиядә квакерларны кысрыклау, мөселманнарның мәчетләрен һәм әрмән чиркәүләрен җимерү башлана»[52].

Идел-Урал якларында урыс булмаган халыкларны христиан диненә кертү архимандрит Димитрий Сеченов җитәкчелегендәге керәшен кантурына йөкләнә. Иң башта ул яңа миссионерлар чакыра. Алар арасында Казан духовная семинариясендә укытучы булып эшләүче, Киев духовная академиясен тәмамлаган Василий Пуцек-Григорович, Сильвестр Гловацкий, Филипп Скаловский һәм Мәскәүдә поп булып хезмәт итүче грузин Георгий Давидовны күрәбез. (Грузин поплары осетиннар арасында шактый уңышлы православие динен тарату белән тарихта билгеле.) Алар барысы да Идел-Урал якларында православие динен урыс булмаган халыклар арасында шөһрәт казанган миссионерлар рәтенә керәләр.

XVIII гасырның кырыгынчы елларыннан башлап чукындыру ысулы, гомумән, көчләүгә генә кайтып кала һәм ул миссионерлар өчен мөселманлыкны һәм мәҗүсилекне юкка чыгару өчен иң нәтиҗәле ысул була. Чукынырга теләмәгәннәрне рәхимсез җәзалау, җәфалау, төрле юллар белән икътисади, сәяси, хокукый эзәрлекләү киң кулланыла башлый. Әлбәттә, Русия хакимияте һәм миссионерлары элек тә башка җиңелгән халыкларны нәсара диненә тартканда бик үгетләп тормаганнар. Бу хакта 1647 елда Романов шәһәрендә яшәүче морзаларның һәм йомышлы татарларның Алексей Михайлович патшага мөрәҗәгате яхшы мисал булып тора (текстны урысча бирәбез): «Романовский во-

---

[52] Анисимов Е.В. Императрица Елизавета Петровна.— М., 2000.— С. 112.

евода Олексий Малышкин посадил нас холопей твоих в тюрьму и мучил, сажал в чепь и в железа и нудил нас холопей твоих сильно креститься в православную христианскую веру: и не мога мы, холопи твои, перетерпеть муки от него... подали мы челобитную ...чтобы нас... крестить в православную христианскую веру; а мы, холопи твои, хочем быть в своей басурманской вере... не вели, государь, нас сильно крестить в православную христианскую веру, а вели, государь, нам быть в своей басурманской вере»[53].

Төрле яктан көчләү 1741 елда ук нәтиҗә бирә башлый. Бу елны 416 чирмешне Царево-Кокшайск (хәзерге Йошкар-Ола) өязендә Георгий Давидов чукындыра; Уржум һәм Вятка өязләрендә 475 чирмешне һәм ар-удмуртны — Вениамин Пуцек-Григорович; Алатор өязендә чукындыру кантуры җитәкчесе Димитрий Сеченов — 721 мордваны; Пенза өязендә 114 мордваны — Стефан Давидов; чуаш, мордва һәм башка халыклардан 179 кешене Казандагы Владимир соборы протопобы Иоанн Симонов чукындыралар. 1742 елда чукынучылар саны тагын да арта. Бу елны иң күп — 3342 чирмешне Георгий Давидов чукындыра; Керенск өязендә 108 мордваны — Иоанн Филиппов; Стефан Давидов — 913 татар, мордва, чирмешне, Вениамин Пуцек-Григорович 282 төрле диндә булган кешене чукындыралар[54].

Татарлар арасында христиан динен тарату Казан өязендә аеруча нәтиҗәле алып барыла. Бирелә 64 кеше чукындырыла: Курмышта — 34, Уфада — 20, Зөядә — 14, Сембердә — 5, Алаторда — 2, Саранскида 1 кеше. Вятка, Керенск, Пенза, Самара, Шацк, Уржум, Цивил өязләрендә яшәгән татарлар арасында православие диненә кучу очрагы күзәтелми.

Урыс булмаган халыкларны православие диненә күчерү өчен төрле ысуллар кулланыла. Шулар арасында җинаять кылган адәмнәрне чукынган очракта җаваплылыктан азат итү турында указ булуга карамастан, сенат 1741 елның 11 мартында шушы хакта яңа указ кабул итә. Бу указ нигезендә үзләре теләп чукынган җинаятьчеләрне җәзадан азат итү генә түгел, ә Русиянең эчке районнарына урыслар арасына күчереп утырту карала. Мондый указны православие руханилары хуплап чыгалар. Вятка епископы Вениамин атакай «үлемнән шундый мәрхәмәтле коткару очракларын күреп, мәҗүси вотяклар (удмуртлар.— *Ф.И.*) күпләп православие динен кабул итәрләр» ди. 1741 елда удмуртлардан О.Алешина үлем җәзасыннан азат ителә. Аны хатын-кызлар монастыренда ярты ел тәүбә итү белән чикләнәләр. Шушы ук елның 14 августында Чабаксар төрмәсендә утырган җирле

---

[53] ДАИ.— Т. 1.— С. 118.
[54] Описание документов...— Т. 23.— С. 365—370.

халык вәкилләрен ат урлауда һәм кеше үтерүдә гаепләнүдән азат итеп чукындыралар һәм Мәскәү тирәсендәге патша беләмәсе булган вулысларга күчерәләр[55].

Урыс миссионерлары һәм хакимият көчләп чукындыруда ир-егетләрне рекрут итеп солдатка алудан азат итү алымын бик яхшы файдаланганнар. Ул чорларда гади татар крәстияне рекрут итеп алынса, аның туган якларына кире әйләнеп кайтуы бөтенләй мөмкин булмаган, дисәк тә, дөрес булыр иде. Әтиәни, туган-тумача, рекрутны патша армиясенә озатканда, аның белән бөтенләйгә хушлашкан. Ул вакытта татарлар Балтыйк буенда хезмәт иткәннәр. Хезмәт вакыты тәмамлангач та аларны, туган якларына кайтармыйча, чик буена урнаштырганнар. Каты авырып яисә яраланып хезмәт итә алмаган солдатлар гына өйләренә кире әйләнеп кайта алганнар. Шуңа күрә солдатка алынуны әҗәл белән тиңләгән яшьләр рекрутлыктан чукыну ярдәмендә генә котыла алганнар.

Рекрутларның авыр хәле турында Шиһабетдин Мәрҗани өстәмә мәгълүматлар бирә: «Чираттагы кеше читтә булса йә качса, бөтенләй чиратта тормаган кеше алына. Шуның аркасында чираттагы кешеләрне кулга алып, качмасын дип, богаулап куеп, ун-унбишәр көн, хәтта артыграк та каравыл астында тоталар иде. Хәтта безнең заманда да мондый законсызлыклар эшләнә, чираты җиткән кешене, качмасын дип, һичнинди гаебе булмаган икенче берәүнең аягына богаулап куялар. Һәрвакыт, ни генә эшләргә туры килсә дә, хәтта йоклаганда да һәм бәдрәфкә чыкканда да, икесе бергә булалар. Бу үз күзебез белән күргән хәлләрдән»[56]. Мәрҗани хәзрәтләре заманыннан йөз еллар элек рекрутларның хәле тагын да аянычрак булган дип уйларга хакыбыз бар.

1742 елның 6 апрелендә синод хәрби хезмәттә булган калмык, татар, мордва, чуаш, чирмеш һәм башкаларны полклардагы гаскәри священниклар чукындырырга тиеш дигән указ кабул итә. Указ нигезендә армиядәге попларга урыс булмаган солдатларны православие дине нигезләренә дога кылырга өйрәтү, аларны һәрдаим күзәтеп тору йөкләтелә. Шушы указдан соң армиядә хезмәттә булган татар һәм башка халыклар арасында православие динен тарату киң тарала. Хәрбиләр арасында православие динен тарату турында җирле халык яхшы белгән, шуңа күрә урыс булмаган рекрутлар, армиягә алынганчы ук православие динен кабул итеп, армия хезмәтеннән котылалар.

XVIII гасыр урталарында ир-атларга рекрутлыктан качып котылу өчен бер генә ысул кала — чукыну. 1746 елда Казан өязе

---

[55] Сенатский архив.— Т. 4.— С. 274—275.
[56] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар...— 202 б.

Арча юлындагы 76 ар-удмурт егет рекрут итеп билгеләнә, тик алар барысы да чукына һәм хезмәттән азат ителә; алар урынына яңадан 56 кеше билгеләнә, алар да чукына; яңадан рекрут итеп сайланган 26 кеше шулай ук чукына. Бу хәлдән соң Арча ягындагы ар-удмуртлар арасында солдатка җибәрерлек яшьләр табылмый. Шуңа күрә читтән, һәрберсенә 40 — 80 тәңкә түләп, ят кешеләрне рекрут итеп озатырга мәҗбүр булалар[57].

Мондый хәл мәҗүси ар-удмуртлар белән генә булмый, әлбәттә. 1746 елда Зөя өязе Янбахты һәм Дүртөйле авылы ясаклы татарлары Андрей Ашкин һәм Үтәгән Якчурин язуына караганда, йомышлы һәм ясаклы татар, чуаш, чирмеш, мордва рекрут итеп билгеләнсә, алар барысы да акча һәм ашамлыклар алгач та чукынганнар һәм хезмәттән азат ителгәннәр. Алар урынына һәр авылдан алтышар һәм аннан да күбрәк кеше җибәргәнлектән, халык бөтенләй бөлгенлеккә төшә. Зөя өязендәге мөселманнар керәшеннәр өчен өстәп 1638 тәңкә салым түләргә тиеш булалар. Өстәмә салымны түләр өчен татарлар йортларын, мал-туарын сатсалар да, салым түләргә акчалары җитми, шуңа күрә алар төрле якларга качып китәргә мәҗбүр булалар[58].

Яшьләрнең чукынып солдаттан котылуы бик еш булган, күрәсең. Берничә елдан соң сенат «Чукынган рекрутларны хезмәттән азат итмәскә, рекрут итеп икенче кешене алмаска!» дигән фәрман кабул итәргә мәҗбүр була. Мөселманнар чукындыру кантурына килеп, православие диненә күчкән очракта да аларны яңадан хезмәткә озатырга боерыла[59].

Рекрутларның православие диненә күчү очраклары көтелмәгән яңа проблемалар тудыра. Шушы хакта гыйбрәтле бер вакыйга турында язып китәбез. 1749 елның июнь аенда татарлардан М.Исаев чукына һәм рекрутлыктан азат ителә. Бу вакытта М.Исаев өйләнгән була. Аның каенатасы Ч.Гомәров Мортаза исемле улы белән Исаевның чукыну турындагы хәбәрен ишетүгә, кызын, киявеннән аерып, өенә алып кайта. Хатынын яңадан үзенә кайтару ниятеннән керәшен М.Исаев, дус-ишләре белән Наратлы авылына килеп, хатынын алып китәргә тели. Болар арасында низаг чыга. Керәшеннәрнең шикаятенә караганда, мөселман татарлар керәшеннәрне күсәк белән шактый рәхимсез кыйнаганнар, керәшен Дмитрийның кулына сөңге белән чәнчегәннәр, тәреләрен, муеныннан өзеп алып, җиргә ыргытканнар һәм таптаганнар, әгәр чукынудан туктамасаң, уң кулыңны сындырабыз, дип янаганнар.

Ахырда өстенлек керәшеннәр ягында калган. Мөселман та-

---

[57] Л у п п о в П. Христианство у вотяков со времени первых исторических известий о них.— Вятка, 1901.— С. 158.

[58] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 3.— С. 83.

[59] Шунда ук.— 85 б.

тарларны керәшеннәр бәйләп Казанга алып килгәннәр. Тикшерү барган вакытта, 1749 елның 9 ноябрендә, Ч.Гомәров һәм Б.Исламов православие динен кабул итәләр.

Чукынучылар арасында хатын-кызлар санының ирләр саныннан аермасын да шушы мәсьәләнең бер чагылышы дип карап булыр иде. Бу күренеш татарларга гына түгел, башка мәҗүсиләргә дә хас күренеш. 1744 елда 139 чукынган татар арасында 14 кенә хатын-кыз теркәлгән; 1745 елда 159га 26, 1746 елда 184 һәм 37 булган. Алга таба чукынучы татарлар арасында ирләр күп булса да, хатын-кызлар саны әкренләп арта барган. 1748 елда 1173 татар чукынса, аның 329ы хатын-кыз; 1751 елда бу саннар 1441 һәм 673кә җиткән[60].

Әлбәттә, көч кулланмыйча гына тиз арада бу кадәр халыкны чукындыру мөмкин булмас иде. Дини эзәрлекләү иң беренче мөселман татарларга, мулла-мөдәррисләргә, мәчетләргә каршы юнәлтелә. Чөнки мәҗүси мордва, чирмеш, чуаш, удмурт халыклары чукындыруга каршы килмәсәләр, мөселман татарлар башта миссионерларга нык каршы торган, алар арасында 1741 елда чукынучылар бик аз. Ул заманда ислам дине мөселман кешесенең рухи терәге генә түгел, ә аның яшәү рәвеше дә була: татар кешесенең гадәти тормышы шәригать кануннары буенча тәртипкә салынганга күрә, муллаларның мәхәлләләрдә халык алдында абруе зур була, чөнки ул, намаз, вәгазь уку белән бергә, халык өчен кирәкле башка вазифаларны да үтәгән, казый-судья да, укытучы да, хәтта табиб та булган. Шуның өстенә урыс руханилары ислам динен үзенең табигый көндәше итеп тә карый, чөнки ул чорларда мөселманнарның мәҗүсиләргә рухи яктан тәэсире нәсара диненнән көчлерәк тә булган, дисәк тә ялгышмабыз кебек. Һәрхәлдә, урыс руханилары ислам дине Русиядә артык активлашудан бик шикләнгән һәм аны булдырмас өчен вакытында кирәкле чаралар күргән.

Мөселман муллаларында гаеп табып, аларны кызганмыйча җәзаларга, гади татарлар аларга пәйгамбәрләргә ышанган шикелле ышануны бетерү һәм мөселман санын киметү нисбәтеннән аларны Уфа һәм Казан өязләреннән сөргенгә сөрергә. Мөселман руханиларын, мәчет-мәктәпләрдән алып, гарәп-фарсы телләреннән тылмач итеп, халыктан аерсаң, тагын да яхшырак булыр, дип язган XVIII гасырның утызынчы елларында Ырынбур комиссиясенең беренче җитәкчесе И.К.Кириллов[61].

Чукындыру кантуры, нәкъ менә шушы И.К.Кириллов тәкъдимнәре буенча эш йөртеп, мөселманнарның көчләп чукындыру сәясәтенә каршылыкны юкка чыгару нияте белән, рухи һәм мәдәни үзәк булган мәчетләрне җимерүдән башлый. Миссионерлар фи-

---

[60] РГАДА.— Ф. 796, оп. 26, д. 169, л. 84—88 об., л. 148—150.
[61] Материалы по истории Башкирской АССР.— Т. 3.— С. 494.

керенчә, мәчетләрне җимерү мөселман руханиларын юкка чыгаруга тиң булачак. Ислам диненең терәге булган руханилар юкка чыккач, дин дә югала, татар халкы динсез кала, православие динен чиксез таратырга киң мөмкинлекләр ачыла. Урыс тарихчыларыннан Н.Фирсов муллаларның татар җәмгыятендә ролен болай итеп күрсәткән: «Бу мәмләкәттә ислам диненең куәте, аның халык арасында таралуы муллаларның тәэсиреннән килеп чыкканлыгы, ә алардагы тәэсир көченең, гыйбадәт урыны гына булып калмыйча, вәгазь һәм тәрбия урыны да булган мәчетләр ярдәме белән саклануы аңлашылганга, мәмләкәттә исламның бу таянычын какшату кирәк иде»[62].

Әлбәттә, миссионерларның бу кабахәт фикере юк җирдә генә тумаган. Явыз Иван, Казанны яулап алгач та, шәһәрдә булган барлык мәчетләрне җимереп, алар урынына чиркәү салырга әмер бирә. Урыс елъязмачылары бу вәхшилекне болай дип теркәп куйганнар: «Божию милостию и православного царя Ивана Васильевича великою верою по его желанию сердечному прадеде ему господь бог безбожных татар казанских и бесерменскую их веру благочестивый их государь разори, и мизгиты (т.е. мечети.— *Ф.И.*) их розсыпа и попра, и мрачныя их места своим благочестием просвети и божии церкви воздвигнув и православие устрои и архиепископию и многие священства по церкви учини»[63]. Казанның берничә урынына Мөдһиш Иван үз кулы белән тәреләр утыртып, биредә чиркәүләр төзергә боера. Башкаланың үзәге Кремльдә Русия патшасы күрсәткән урында төзелгән Благовещение соборы бүген дә эшләп тора, тирә якка христиан нурын сибә.

Классик тарихчыбыз Ризаэтдин Фәхретдин фикеренчә, «Өлкәне басып алганнан һәм тырнакларын батырганнан соң, руслар мәчетләрне, мәктәп һәм мәдрәсәләрне ваттылар, җимерделәр, изге Коръән һәм башка китапларны яндырдылар. Язулы кәгазь һәм дәфтәрләрдән берсе дә калмады»... «Казан шәһәре алынганнан соң, руслар, бөтен авылларда йөреп, байлыкны басып алдылар, мәктәп-мәчетләрне яндырдылар, бик күп мөселманнарны чукындырдылар (керәшен ногае, мәкруһ) дип йөри торган халыкларның күбесе — шул вакыттагы чукындырылган халыклар... Казан хөкүмәте бетү белән... гыйлем әһелләре Кавказга һәм Төркестанга качты. Кайбер авылларда кечкенә генә һәм күбесе яшерен рәвештә гыйбадәтханәләр ачылды, муллалар барлыкка килде. Абыз ага дип йөртелә торган бу муллалар, ир һәм кыз балаларны үз өйләренә җыеп, иман һәм намаз да өйрәтәләр иде»[64].

---

[62] Баттал Г. Күрс. хезм.— 68—69 б.
[63] Русские летописи по Никоновскому списку.— Т. 7.— С. 233—234.
[64] Фәхреддин Р. Күрс. хезм.— 52, 245 б.

Шушы ук вакыйгалар кайбер хәзерге заман дәреслекләрендә, тарихны бозып, түбәндәгечә тасвирлана: «Всем подданным бывшего Казанского ханства, даже упорно сражавшимся против русских, объявлена была милость и даны все права... Православная церковь мирно относилась к иноверцам и даже не думала, например, искоренять мечети, сохранившиеся не только вокруг Казани, но и в самом городе»[65].

Димәк, елъязмалар күрсәтүенчә, Русия патшасы «алласыз» Казан татарларының, ислам динен юк итү өчен, мәчетләрен җимерә, бу «караңгы» урыннарга диндарлы аң-белем тарата һәм, Аллаһының чиркәүләрен төзеп, ислам төбәгендә православие динен оештыра. Әйе шул, урыс патшалары борынгыдан алып башта җимергәннәр, аннары ашык-пошык төзегән булып кыланганнар. Тик ни өчен изге эшне Аллаһы йортын җимерү, юкка чыгарудан башларга кирәк икән?

XX гасыр башында яшәгән урыс тарихчысы Н.А.Спасский язуларына караганда, хан сараенда җимерелгән дүрт мәчет урынына Благовещение соборы төзелә. Явыз Иван әмере буенча җимерелгән Кремльдә изге Киприан һәм Иустин чиркәве салына. Кол Шәриф мәчете урынына Спас-Преображение монастыре төзелә башлый. Кремльдә булган биш таш мәчетләрдән берсе генә ватылмый кала. XVIII гасырда бу мәчетне чиркәүгә әйләндерәләр. Шушы мәчет тарихта Нурали мәчете исемендә билгеле[66].

Мәчетләрне җимерү турында менә шундый төрле ышанычлы чыганаклар булуга карамастан, кайбер «галимнәр», урыслар Казанны басып алгач та, Явыз Иван әмере буенча барча мәчетләрне җимермәгәннәр, мәчетләрне яңадан төзүне тыю да чынбарлыкта тиешенчә үтәлмәгән, дип язалар[67]. Алга таба без урысларның сугыш вакытында түгел, ә тыныч елларда эшләгән вәхшилекләрен, чыганакларга таянып, күпьяклап сурәтләргә тырышырбыз. Ә менә безнең халыкта, баскыннарга ярар өчен, тарихны бозып, караны ак итеп күрсәтүчеләрне һич аңлап булмый. Икенче яктан аларны аңлап та була: алар бит дөньяга ярашып яшиләр, иҗат итәләр, гыйльми дәрәҗәләр дә алалар. Маңкортлыкны күрсәткән мондый аяныч күренеш күпме дәвам итәр икән?!

Укучыны тагын бер аяныч күренеш белән таныштырасы килә. Тарихи дәреслекне бозып, Русия дәүләтен мөселманнарга карата көчләүче итеп түгел, ә киресенчә, бик миһербанлы икән-

---

[65] Богданов А.П. История России до петровских времен.— М., 1997.— С. 199—200.

[66] Спасский Н.А. Очерк по родиноведению.— Казань, 1913.— С. 240—244.

[67] Исламо-христианское пограничье...— С. 167—168.

леген исбатлау өчен кайбер галимнәр түбәндәге уйдырма фикер дә таратырга тырышалар. Имештер, Русия империясендә православие чиркәве белән хакимият союзы гына булмыйча, шактый гына мәчетләр хөкүмәт акчасына салынып, дәүләт ислам динен халыклар арасында тарату белән дә шөгыльләнгән[68]. Айһай, шулай булды микән? Әлбәттә, тырышып тирәнрәк казынсаң, бөтен Русиягә казна акчасына салынган мәчетләр турында бер-ике мисал табып булыр иде. Тик ул мәчетләрне ислам динен тарату өчен түгел, ә ислам дине аша мөселман халыкларын Русия империясенә буйсындыру өчен эшләнгән мәкерле сәясәт дип карау зарур. Бу хакта яхшы дәлил булып түбәндәге мисал тора: 1799 елда Ырынбурда мәчет төзелеп, шәһәр мулласы итеп куелган Гадеррахманга казнадан 150 тәңкә хезмәт хакы билгеләнә; 1750 елда Кече Җүз ханы Нурали Ырынбур губернаторы И.Неплюевка мәчет төзүне үтенеп хат яза. Губернатор мәчет төзүгә рөхсәт бирми, чөнки казна исәбенә Русия мәмләкәтендә мәчетләр төзү катгый тыела, бигрәк тә мәчетләрне христианнар кулы белән төзергә ярамаганлыгын азсызыклап казакъ ханына җиткерә[69].

Хәзер инде, чыганакларга таянып, татар мәчетләрен җимерү турында фактлар китерик. Күп кенә галимнәр мәчетләрне вату 1742 елның 19 ноябрендә сенат чыгарган указ буенча тормышка ашырыла дигән фикердә торалар. Указ Казан, Себер, Әстерхан, Воронеж губерналарында рөхсәтсез төзелгән мәчетләрне җимереп ташларга һәм яңаларын төземәскә боера[70]. Бу фәрман буенча мөселманнар яшәгән авылларда бер генә керәшен булса да, мәчетләр ватылырга тиеш була.

Ә чынбарлыкта татар авылларында мәчетләрне җимерү ярты ел алдан, синод тарафыннан шул ук елның 10 майда кабул ителгән указ нигезендә башлана. Мәчетләрнең язмышын Казан епископы Лука Канашевич үзе генә хәл иткәнлектән, мәчетләрне саклап калу мөмкинлеге бөтенләй диярлек югала. Бу хакта Казан епископы үзенең һәрбер приходына махсус указ юллый: «Нигде вновь мечетей не было и построенные за запретительными указами мечети, где еще не разобраны б были, а так же о возобновлении вновь мечетей с согласия от него быть уже не следует»[71]. Башка епархия җитәкчеләре дә, нәкъ Лука атакай шикелле эш итеп, мәчетләрне җимерүне оештыралар.

Шушы указларны алу белән, татар авылларында мәчетләр-

---

[68] Журавский А.В. Симфоническое единство государства и церкви: Иллюзии и реальность // Религия в современном обществе: История, проблемы, тенденции.— Казань, 1998.— С. 77.

[69] Чернавский Н. Курс. хезм.— 126 б.

[70] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 1.— С. 251.

[71] Шунда ук.— Т. 2.— 150 б.

не, мәдрәсәләрне җимерү, рәхимсез вату башлана. Татар авылларына нур биреп торган мәчетләрне, рухи вә мәгърифәт үзәкләрен җимерү шаукымы табигать афәте сыман үтә, әмма моңа табигать түгел, ә исламны күралмау сәбәп була. Бик аз вакыт — бары тик 1742 — 1743 елларда — Казанда һәм өяздә 536 мәчеттән — 418, Себер губернасындагы Тубылда, Тарада һәм башка өязләрдә 133 мәчеттән — 98, Әстерхан губернасында 40 мәчеттән 29 ватыла[72]. 550 тирәсе мәчетләрне җимерү бер ел эчендә булуы турында тагын кабатлап әйтәсебез килә, чөнки кайбер галимнәр мәчетләрне җимерү вакытын шактый озак итеп күрсәтәләр[73]. «Церковь в истории России» дигән китапта Казан губернасында мәчетләр җимерелү вакыты егерме ел — 1738 елдан 1758 елга кадәр итеп ялгыш күрсәтелә[74]. Мәчетләрне җимерү вакытын яңадан кабатлап әйтәбез — егерме ел түгел, ул мәчетләр бер ел эчендә җимерелә! Татарча язма җыентыкта бу афәт болай тасвирлана: «Мең дә ети йөз дә кырык өчтә мәсҗидләр бозылды, аз калды. Ат елы ирде, Петр кызы Елизавет шаһ ирде. Соң кири ясамага улук әмер итте. Аллаһының әмере илән»[75].

Бирелә китерелгән саннар хакында аерым аңлатма биреп китү зарур дип уйлыйбыз. Моңа кадәр басылган тарихи хезмәтләрдә 418 җимерелгән мәчетләр саны Казан губернасында җимерелгән итеп тасвирлана. Тик бу фикер дөрес түгел. Без, яңа чыганакларга таянып, мондый фикергә килдек: күрсәтелгән сан Казан Татар бистәсендә һәм Казан өязендә җимерелгән мәчетләргә генә карый, бирелә сүз бөтен губерна турында бармый. Бу хакта Казан епископы Лука Канашевичның 1743 елның 18 ноябрендә синодка юллаган белдерүе яхшы дәлил булып тора. Бу белдерүдә сүз Казан өязе һәм Казандагы Татар бистәсе турында гына бара: документта беренче мәртәбә җимерелгән мәчетләрнең саны да атала[76].

Күптән түгел без Мәскәүдәге Русиянең борынгы чыганакларны саклау үзәк архивында (РГАДА) Казан өязендә һәм Казан татар бистәсендә җимерелгән Татар мәчетләре исемлеген таптык. Бу исемлеккә сүз Казан Татар бистәсендә һәм Казан өязендә булган 536 мәчетнең 418е җимерелеп, 118 генә калуы турында бара. Казандагы Татар бистәсендә ул вакытта 342 хуҗалык булып, анда 665 ир-ат яшәгән һәм бирелә дүрт мәчет

---

[72] Шунда ук.— Т. 4.— 231 б.

[73] Религия в современном обществе: История, проблемы, тенденции.— С.177; И с х а к о в Д.М. Историческая демография татарского народа...— С. 60.

[74] Церковь в истории России...— С. 197.

[75] Б а т т а л Г. Күрс. хезм.— 69 б.

[76] Описание документов...— Т. 22.— С. 813.

булган. Дүрт мәчетнең икесе Казан ханлыгын алганчы ук төзелү турында бистә халкы әйтүгә карамастан, барлык мәчетләр дә җимерелә.

Ул заманда Казан өязенең, элекке Казан ханлыгы традициясен дәвам итеп, биш юлга бүленгән булуы тарихчыларга яхшы билгеле. Бу документта да Казан өязе шулай итеп күрсәтелгән. Казан өязе Галич юлы буенча 17, Алат юлы буенча 91 мәчетнең барысы да ватыла, Җөри юлындагы 97 мәчетнең 96сы, Ногай юлында 83 мәчет җимерелә, ә 52 калдырыла; Арча юлында 127 мәчет җимерелә, 65 сакланып кала. Ничек итеп Арча һәм Ногай юлына караган авылларда мәчетләрне саклап калырга мөмкин булуын хәзергә аңлап булмый. Мәчетләре җимерелгән кайбер авылларны атап китик: Галич юлында Котлыбулат, Кулбаш, Чуаш авыллары; Алат юлында Япанча, Олы Сәрдә, Әтнә, Ташкичү, Кенәр, Куныр авыллары; Җөри юлында Арташ, Кече Кирмән, Баландыш, Иске Җөри авыллары; Ногай юлында Әлки, Ибрай, Елховой Багрәж, Шахмай, Әлмәт авыллары; Арча юлында Түбән Симет, Сатыш, Янгул, Казиле, Югары Мәтәскә, Кырлай, Сикертән авылларында мәчетләр җимерелә, ә Югары Симет, Мәңгәр, Казанбашта (өч мәчетнең икесе), Түбән Мәтәскәдә, Урта Пошалымда, Югары Курсада мәчетләр ватылмаган. Шунысы игътибарга лаеклы: 7— 8, хәтта 4 йорты гына булган авылларда да мәчетләр эшләп килгән. Казан губерна кәнсеЛәрендә төзелгән шушы документ җимерелгән мәчетләрнең санын дөрес күрсәтә торган иң мөһим дәлил булып тора.

Кызганыч ки, соңрак бу сан ни сәбәптәндер рәсми документларда бөтен губерна саны итеп күрсәтелә башлый. Ә бит биредә татарлар күп яшәгән башка өязләр күрсәтелмәгән. Һәрхәлдә, бу сан Русиядә, Идел-Урал якларында миссионерлар тарафыннан кылынган вәхшилекнең чын масштабын күрсәтми. Оста куллы мөселман татарлар тарафыннан төзелеп, авылларда иман нуры таратып торган мәчетләр Русия империясенең барча төбәкләрендә дә күпләп җимерелә һәм аның саны, күрсәтелгән саннарга караганда, ким дигәндә, 2 — 3 мәртәбәгә артык булырга тиеш.

Тагын шуны күрсәтеп китү кирәктер дип уйлыйбыз: мәчетләрне җимерү ислам динен татар халкы арасында какшатуга китерми; киресенчә, ул православие миссионерларының кылган эшләренә нәфрәт уята; ә татарлар, үзләрен керәшеннәр белән бутамас өчен, башка халыклар белән танышканда, үзләрен мөселман дип атый башлыйлар. Алар арасында чукынучылар саны да бик артмый, елына 100 —150 тирәсе була. Татарлар арасында чукынучылар саны 1748 —1749 елларда гына бер меңнән артып китә.

Вятка епископы Варлаам атакай Слободской өязендәге Зур авыл, Ильяс, Починошной, Чепца өязендәге Кыстым авылында

булган мәчетләрне ватарга тәкъдим итә[77]. Кызганыч ки, без бу епископның теләге үтәлгәнме, әллә юкмы икәнлеген ачыклый алмадык. Шулай да бу авыллардагы Аллаһ йортлары җимерелгәндер дип уйлыйбыз, чөнки урыс руханиларының мәчетләрне юкка чыгару теләге вакытында тормышка ашырылган.

1753 елда Касыйм шәһәрендә Дмитрий Симонов исемле бер алпавыт элек татарлар биләмәсе булган урында җир сатып ала. Бу алпавыт җирендә таш мәчет сакланып калган була. Дмитрий Симонов мәчет материалларыннан чиркәү төзү өчен Рязань епископы Палладийдан рөхсәт ала һәм үзенең кешеләрен мәчетне ватарга җибәрә. (Игътибар итегез: рөхсәтне мөселман мулласы түгел, ә православие рухание бирә!) Тик алар тиз арада таш мәчетне ватып бетерергә өлгерә алмыйлар. Кылынган вәхшилек турында ишеткән Касыйм татарлары морза Абдулла Маметев җитәкчелегендә мәчет тирәсендә җыелалар һәм ачудан мәчетне ватучыларны кыйнап та ташлыйлар, ә берсенең кулын бәйләп, Касыйм кәнселәренә алып киләләр. Тик соңыннан барыбер бу мәчетне ватып, аның материалыннан урыслар чиркәү төзеп куялар[78].

1742—1743 еллардагы мәчетләрне күпләп җимерү тәмамланып, аларны яңадан торгызырга мөмкинлекләр ачылган елларда да кайбер төбәкләрдә аларны вату дәвам итә. Нижгар губернасы Курмыш өязендәге Маклаковка авылында булган мәчет 1760 елда юкка чыгарыла. Мәчетне ватканда татарлар каршылык күрсәтмәсен өчен, авылда гаскәриләр командасы «тынычлык» саклап тора[79].

Төрле төбәкләрдә мәчетләрне җимерү кызган вакытта, 1742 елның сентябрендә үк Казан Татар бистәсе мөселманнары исеменнән Сәфәр Гомәров исемле изге зат патшабикә Елизавета Петровна исеменә үтенеч юллый. Аның фикеренчә, Татар бистәсендә мәчетләрне ватарга нигез юк, чөнки бистәдәге мәчетләрне вату турында указда махсус әйтелми, керәшеннәр Татар бистәсендә яшәми, урыс чиркәүләре биредә юк, ә Татар бистәсе урыслардан аерым урнашкан. Әлбәттә, бу үтенеч мәчет төзергә рөхсәт алырга мөмкинчелек бирми. Киресенчә, 1742 елның 19 ноябрендә сенат кабул иткән указ шушы мөрәҗәгатькә җавап була да инде.

Татарлар хакимият органнарына җимерелгән мәчетләрне торгызу өчен рөхсәт сорап мөрәҗәгать итеп торалар. Беренчеләрдән булып сенатка Казан өязе Төбәк авылыннан Бакый Исмәгыйлев, Зөя өязе Олы Шырдан авылыннан Айтуган Урас-

---

[77] Описание документов.— С. 812—815.

[78] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 1.— С. 63—64.

[79] Никольский Н.В. Распространение христианства среди нижегородских чуваш до 1764 г.— Петроград, 1915.— С. 133.

киев, Сембер өязе Мочалы авылыннан Мөхәммәтали Мөхәммәтев, Пенза өязе Түбән Әләзән авылыннан Давыт Кудашев мәчетләрне яңадан торгызу мөмкинлеген үтенәләр. 1743 елда Казан, Зөя, Сембер өязләрендәге ясаклы татарлар миссионерлар җимергән мәчетләрне торгызу кирәклеге турында патшабикәгә шикаять язалар. Сенат «Хәзергә кадәр мәчетләр сакланып калган булса, аларны ватарга, яңаларын төзергә рөхсәт итмәскә, татар авылларында чукынганнар арасында чукынмаганнар булса, аларны икенче авылларга күчереп утыртырга!» дигән фәрман чыгара.

Шулай да бу указда Казандагы Татар бистәсендә, Казан һәм башка губерналарда җимерелгән мәчетләр урынына, мәхәллә 200 — 300 кешедән торса, мәчет салырга рөхсәт бирә[80]. Шул ук вакытта, яңа мәчетләр төзүне булдырмау өчен, хакимият татар абызларыннан һәм йөзбашларыннан махсус имзалар ала. Тик бу сенат фәрманының мәчетләр төзү рөхсәте ул елларда тормышка ашырыла алмый, чөнки ул вакытта татарларны дини изү шулкадәрле көчле була ки, аларның сенат яисә синодка «мәчет төзергә рөхсәт бирегез» дигән үтенечләренә һәрвакытта: «Мәчетләрне җимерергә!» — дигән карарлар чыгып кына тора. Безнеңчә, указның мәчетләрне төзергә мөмкинлек биргән өлеше татарларга бөтенләй җиткерелмәгән булырга тиеш...

Казан һәм Сембер өязләреннән йомышлы морзалар һәм татарлар исеменнән Якуб Биметев 1744 елның 13 апрелендә сенаттан мәчетләр төзергә рөхсәт сорый. Бу сорауга сенат «Сакланып калган мәчетләрне ватарга, яңаларын салмаска, ә мөселманнарны икенче авылларга күчерергә!» дигән фәрман кабул итә.

Кайбер очракларда татарлар үз мәчетләрен җимерүдән саклап кала алганнар. Бу турыда Әстерхан шәһәрендә булган хәл сөйли. Төрле елларда шәһәрнең татарлар күпләп яшәгән бистәләрдә ун мәчет төзелгән була. Сенаттан җибәрелгән указ бистә саен берәр мәчет калдырып, калган бишен җимерүне таләп итә. 1754 елның 23 августында язылган шикаятьтә Әстерхан татарлары мәчетләрне җимермәүне сорыйлар; мәчетләр җимерелгән очракта татарларның Кубань якларына күчеп китү мөмкинлеген күрсәтәләр; сенатның элеккеге указы буенча 3245 кешегә биш мәчет аз, унбер кирәк булганлыгын искәртәләр. Әстерхан татарларының бу үтенече канәгатьләндерелә[81].

Русия империясе составында булган мөселманнар арасыннан XVIII гасыр буенча туктамыйча баскыннарга каршы баш күтәреп торган башкортларга гына мәчетләр тотарга рөхсәт ителә, биредә булган мәчетләр рәсми җимерелми; шундый өстенлекләр булуга карамастан, 1744 елның 20 февралендә

---

[80] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 2.— С. 144.
[81] Описание документов...— Т. 22.— С. 815.

чыккан фәрман буенча Уфа өязендә, башкорт ягында, яңа мәчетләр төзү барыбер тыела.

Ә мөселман татар халкы, Русия хакимияте рөхсәтен көтеп тормыйча, җимерелгән мәчетләр урынына яңа мәчетләр төзи башлый. Нәкъ шушы елларда, миссионерлар күзенә чалынмасын өчен, манарасыз мәчетләр эшләнә башлый. (Урыслар аны рәсми документларда «пятивременные мечети», ягъни биш вакыт намаз укый торган мәчет дип теркәгәннәр.)

Беренчеләрдән булып Казан өязе, Ногай юлы Елтан, Агрызан, Ясаклы Киек, Зур һәм Түбән Шантала авылларында 1744 елда җимерелгән мәчетләр урынына яңалары салынган була. Казан өязе Ногай юлы Әлки авылы йомышлы татарлары исеменнән Әнишә Барисов, сайланган Мәкәй Мәмәев, староста Али Чапкынов 1744 елда авылларында ватылган мәчет урынына яңаны төзергә рөхсәт сорыйлар. Мондый хәбәрне алу белән, урыс миссионерлары бу төбәктә зур тикшерү ясыйлар. Тикшерү татарларның бернәрсәдән дә курыкмыйча еракта булган авылларда гына түгел, ә урыс авылларыннан якында да рөхсәтсез мәчет төзүләре турында күрсәтә. Бу башбаштаклыкны күргән миссионерлар тагын «Мәчетләрне кичектергесез ватарга, яңаларны салырга рөхсәт итмәскә, ә татарларны урыс һәм керәшен булмаган авылларга күчереп утыртырга!» дигән фәрман кабул итәләр[82].

Татарлар формаль-юридик яктан мәчет төзү өчен рөхсәтне 1743 елда алсалар да, бу указны тормышка ашыру өчен күп еллар хакимият белән көрәшергә туры килә. Рәсми рәвештә татар авылларында 200 хуҗалык булган очракта мәчет төзергә рөхсәтне сенат 1756 елда, Батырша восстаниесе шаукымы астында гына кабул итәргә мәҗбүр була. Казандагы Татар бистәсендә мәчет төзергә рөхсәт 1743 елда бирелсә дә, аларга Аллаһ йорты салу өчен 25 елга якын шәһәр түрәләре һәм миссионерлар белән көрәшергә туры килә.

Казанга кунакка килгән Әби патша — Екатерина-сания генә (кайбер татарлар Екатерина II не шулай дип атаганнар) 1767 елда Татар бистәләрендә таш мәчетләр салырга рөхсәт бирә. Бу хакта риваятьләрдә болай теркәлгән: «Әби патша Казанга килгәч, мөселманнарның олуг байлары, Әби патша катына кереп, гарызнамә биргәннәр, бистәгә таш мәчет салырга рөхсәт сорап. Вә һәм Әби патша, Казан байларының гарызын кабул итеп, таш мәчет салырга рөхсәт биргән, вә һәм мәчет урынын тәгаен кылган, вә һәм мөселманнарны бик яраткан; Казанда торган мөддәтендә һәмишә (һәрвакыт, өзлексез.— *Ф.И.*) мөселман арасына төшеп: «Урыстан җәфа күрмимсез?» — дип сора-

---

[82] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 3.— С. 490—491.

шып йөргән»[83]. (Бу вакытта инде татар бистәсе уртасына урыс чиркәве салып куелган, берничә керәшен гаиләсе мөселманнар арасына күчерелеп утыртылган, 200 бала укый торган керәшен мәктәбе ачылган.) Патшабикәнең карары булуга карамастан, татарлар 1773 елда яңадан төзелгән мәчетләрне урыслар җимерергә исәпли, чөнки: «Рөхсәт телдән генә әйтелгән иде»,— дип, яңадан шикаять язарга мәҗбүр булалар[84].

Чукындыру кантуры миссионерлары, мәчетләрне вату, җимерү белән беррәттән, Идел буендагы керәшен авылларында чиркәү һәм монастырьлар салу эшен киң җәелдереп җибәрәләр. Керәшен авылларында чиркәүләрне күп итеп төзүне архимандрит Димитрий Сеченов башлый. Башта ул авылларда 30 чиркәү төзүне сорый. Сенат фәрманы чиркәүләр керәшен авылларында гына түгел, ә чукынырга теләмәгән мөселман татар авылларында да төзү, төзелешкә мөселман татарларны да җәлеп итү кирәклеген күрсәтә[85].

Лука Канашевич тәкъдиме белән чиркәү, монастырьлар нигезен салганда, борынгы татар зиратларындагы кабер ташлар киң кулланыла. Шулай итеп, халкыбызның борынгы гореф-гадәте, теле һәм мәдәнияте ядкярләре вәхшиләрчә юк ителә, чиркәүләргә күп еллар буе нык нигез булып хезмәт итә[86].

Бу турыда бер гыйбрәтле мисалны Мәрҗани хәзрәтләре дә китерә: «Моннан җитмеш еллар элек Әтрәчтән биш чакрым көньяктарак урнашкан Җанбакты исемле рус авылы алпавыты шул авылга чиркәү салдырганда, нигезенә таш кирәк булгач, шундагы тигез ташларны кулай табып, мөселманнарның олылап хөрмәт иткән ташларыннан егерме-утызлабын агач чиркәүнең нигезенә куйдырган. Әтрәч авылының яше сиксәннән узып барган мөәзине түбәндәгеләрне сөйләде: «Мин, бала чагымда атам белән шул авылга йомыш белән барганда, ул ташларны төзәтеп куйганнарын карап тордым. Атам елап: «Менә, балам, безнең авылыбыздагы газизләрнең каберләре өстендәге ташларны чиркәү бусагасына куялар»,— дип әйтте»[87].

Изге Болгар җирендә 1712 елның 20 августында Успенский монастыре төзелә башлый. Борынгы палатадан чиркәү ясала, монастырь төзү өчен 200 тәңкә акча, 100 пот тимер, 200 мичкә известь, кирәгенчә эшчеләрне ашату өчен арыш һәм солы бүлеп бирелә[88]. Шулай итеп, борынгы болгар бабаларыбызның

---

[83] Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар.— Казан, 1987.— 72 б.
[84] Знаменский П.В. Руководство к русской церковной истории.— С. 372.
[85] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 1.— С. 416.
[86] Газиз Г. Күрс. хезм.— 156—157 б.
[87] Мәрҗани Ш. Күрс. хезм.— 76 б.
[88] ТР МА.— 10 ф., 5 тасв., 511 эш бер., 24 б.

изге йортында да чиркәү-монастырьлар төзелә башлый. 1732 елда монастырьда яңа таш чиркәү салына һәм аңа Успения Богоматери дигән исем куела. Бу чиркәүне салганда, зираттагы каберташлар һәм башка җимерекләрдән төзү материаллары алына; бигрәк тә нигез-фундаментка һәм идәнгә гарәпчә язылган каберташлар күп итеп салына[89]. Бу изге чиркәү Җәмигъ мәчете җимерекләре янында хәзерге көнгә кадәр сакланган. Хәтта Бөек Петр патшаның Кавказга яу белән барганда Болгар җире хәрабәләрен караганнан соң әйтеп калдырган боерыгы да үтәлми, тиз онытыла. Ул, каберташларның тәрҗемәсен Кадермөхәммәт Сүнчәләевтән тыңлаганнан соң, Казан түрәләренә бу истәлекләрне сакларга, ә язуларны күчереп алырга боера. Хәзер инде нигездәге каберташларның язуын штукатурлап ук куйганлыктан, аларны бөтенләй күреп булмый.

Казан һәм Воронеж губерналарында 1747 елда гына да 88 чиркәү төзелә, ә тагын 22не төзергә кирәк дип табыла. Күпләп көчләп чукындыру чорында керәшен авылларында барысы 241 чиркәү казна исәбенә төзелә[90]. Казан епархиясендә 1740 елда 669 чиркәү булса, 1745 елда алар саны 725кә җитә. Димәк, биш елда 56 храм төзелә. Ул чорда Казан епархиясенә Арча, Лаеш, Зөя (Свияжск), Козмодемьянск, Чабаксар, Царево-Кокшайск, Тәтеш, Сембер, Оса, Сарапул, Кукарка, Царевочансурск, Малмыж, Алабуга, Уржум, Яранск, Ветлуга, Уфа, Бөре, Самара, Ырынбур, Сергиевск, Ставрополь (хәзерге Тольятти), Җаек шәһәрләре һәм өязләре кергән була.

Мөселман татарлар, мөмкинчелектән файдаланып, җимерелгән мәчетләрне торгызу өчен зур көч һәм тырышлык куйганнар. Унсигезенче гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында ук шактый авыллар мәчетләрен төзеп, мәктәп-мәдрәсәләр эшен дә рәткә сала алганнар. Данлыклы урыс академигы И.Лепехин шул заманда Чирмешән якларындагы татар авылларын карагач та, һәр авылда мәчет һәм мулла булуын, ә авыллар зур булган очракта, аларның саны ике-өчкә җиткәнен дә күрсәтеп үтә. Шул ук хакта Петр Рычков язмалары да сөйли. Ул да һәрбер авылда диярлек мәчет, мәктәп булганлыгын, биредә малайлар гына түгел, кызларның да татар, гарәп теленә, Коръән серләренә өйрәнүе турында сокланып яза[91].

Керәшеннәр һәм мөселманнар арасында еш кына низаг, аңлашылмаучылык чыгып торган. Мөселман татарлар да, керә-

---

[89] Яблоков А. Село Болгары или Успенское Спасского уезда Казанской губернии.— Казань, 1905.— С. 39.

[90] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 3.— С. 391.

[91] Рычков П.И. Журнал или дневные записки путешествия капитана Рычкова по разным провинциям Российского государства в 1769 и 1770 годах.— СПб., 1770.— С. 5.

шеннәр дә бер-берсен күрә алмаганнар, булмаган гаепне табып, хакимият органнарына бер-берсен гаепләп шикаятьләр язганнар. Православие чиркәве тарихчысы Аполлон Можаровский язмаларына караганда, күп өязләрдә чукынмаган йөзбашлар, вулыс старосталары, сайлап куелган җитәкчеләр, керәшеннәрнең ташлама алуларына карамастан, салым һәм башка түләүләрне түләргә мәҗбүр иткәннәр, рекрутларны армиягә озату өчен алардан акча җыйганнар, керәшеннәр өстеннән судка ялган донослар язып, керәшеннәрне төрмәгә утырту очраклары булгалаган. Зөя өязе Мәлки авылында яшәгән мөселман татарлар (димәк, биредә әле керәшеннәр генә түгел) А.Иземеткин, К.Баюков, Б.Аклыев, А.Еремкин, С.Левентьев, А.Замяткин, О.Токенев керәшен татары А.Ивановны кыйнаганнар, муенындагы тәресен өзеп алып, син христиан динендә түгел, син эт динендә, дип хурлаганнар.

Христианлаштыруны арттыру максаты белән мөселманнарга һәм мәҗүсиләргә өстәмә салым салу ысулы да оста файдаланылган. Белгәнебезчә, рәсми рәвештә 1740 елның 11 сентябрь указы нигезендә чукынмаган мөселманнар һәм мәҗүсиләр керәшеннәр өчен өстәмә салымны түләргә тиеш булалар. 1743 елда сенат фәрманы нигезендә бу салымнар Казан губернасында яшәгән православие диненә күчмәгәннәргә өләшенә.

Чукынучылар саны күп булган төбәкләрдә татарларның хәле бигрәк авыр була. Мондый хәл Нижгар якларындагы морзалар һәм йомышлы татарлар арасында күзәтелә. Алатор провинциясендә яшәгән морзалар һәм йомышлы татарлар фикеренчә, Нижгар һәм Ядрин өязләрендә яшәгән мәҗүси мордвалар һәм чуашлар православие диненә күчкәч, чукынмаганнар саны бигрәк аз кала. 1746 елда Алатор провинциясендә 6510 ир-ат исәпләнгән. Алар 78917 сум салым түләргә, 217 рекрутны армиягә озатырга, 70 ат бирергә тиеш булалар. Һәр кеше 12 сум 12 тиен салым, һәр 30 кеше бер рекрут, 93 кеше ел саен 1 ат биреп торырга тиеш була. Керәшеннәр өчен һәр кешегә 15 тиен өстәмә салым салына. Морзалар һәм йомышлы татарлар өстәмә салымнан азат итүне үтенәләр. Бу очракта татарларның үтенече үтәлә, аларны бер елга салым түләүдән азат итәләр. Тик бу локаль, чикләнгән күренеш, ә 1747 елда Темников, Шацк, Тамбов, Кадом, Касыйм, Пенза өязләре татарларының мөрәҗәгате үтәлми[92].

Мөселманнарны күпләп чукындыру өчен колачлы эшләр алып барылган елларда керәшеннәргә яңа өстенлекләр бирелә. Алпавытларда кол булып хезмәт итүчеләр коллыктан 3 яисә 5 тәңкә премия бирелгәннән соң азат ителә. Бу хакта күренекле урыс тарихчысы Н.Костомаров болай дип яза: изге православие ди-

[92] РГАДА.— Ф. 248, оп. 126, д. 803, л. 378—379.

нен кабул иткән крепостной (кол) мөселман ирек ала; әгәр аның элекке хуҗасы булган морза-алпавыт та православие диненә күчсә, чукынып азатлык алган крепостной яңадан элекке хуҗасына тапшырыла. Колларга азатлык игълан итеп, яңадан аны югалтуны автор керәшеннәрне кимсетүче, куркыныч, уйлап чыгарылган канун дип атый[93].

1748 елда православие динен кабул иткән морзаларны һәм йомышлы татарларны сенат лашманчылыктан азат итә.

Урыс булмаган халыклар арасында православие динен тарату өчен чираттагы халык санын алу кампаниясен дә хакимият яхшы файдалана. 1746 елның 22 мартында кабул ителгән указ нигезендә татар, мордва, чуаш, мари, вотяк халыкларын аерып, чукынганнарын һәм чукынмаганнарын күрсәтүне таләп итә. Перепись вакытында качып, үзләрен яздырмаган кешеләр, чукынган очракта, гаепләнүдән азат ителәләр. Авыр җәзадан котылыр өчен, Казан һәм Саранск өязләрендәге кайбер авыл кешеләре, чукынырга ризалык биреп, христиан динен кабул иткәндә бирелә торган акчалата бүләктән баш тарталар. Бу административ ресурсны куллану да керәшеннәр санын шактый арттырганга охшый, чөнки халык санын алу тәмамланып килгән 1747 ел — иң күп чукынучылар санын күрсәткән ел.

Провинция һәм өяз администрация җитәкчеләре белән православие дин әһелләре христиан диненә күчкән керәшен татарларын яңадан ислам диненә әйләнеп кайту очракларын булдырмас өчен күзәтүне көчәйтә; күчү очраклары булганда, кискен чаралар күргән, закон нигезендә гаепле дип табылган кешеләрне үлемгә кадәр хөкем иткән. Бу турыда да берничә мисал китерәбез.

Әхмәт Мусманов (чукынгач — Павел Яковлев) 1741 елда «үзе теләп» урыс диненә күчә. Аны Казандагы Богородицкий соборы протопобы Иван Филиппов чукындыра. Чукынганнан соң, ул, Кирмән авылына күчеп, урыслар арасында яши, аннары Уфа өязенә күчеп китә. Анда үзен татар кешесе дип атый, татар исемен йөртә, урысларның ураза вакытында, христиан дине кануннарын бозып, ит ашый, сөт эчә. Әхмәт Мусмановның элек керәшен булганлыгы да миссионерларга билгеле була. Алар аны кулга алалар, Казан тирәсендәге Раифа монастырена ябалар. Ул биредә алты атна буена тәүбә-истигъфар кылырга тиеш була. Шулай миссионерлар чукынган татарны монастырьга ябу белән генә чикләнәләр.

Ә күп вакытта миссионерлар, ислам диненә күчкән кешеләрне куркыту өчен, кискен чаралар күрәләр. Бу турыда тагын бер мисал китерәбез. 1743 елда 33 чуаш ире һәм 26 чуаш ха-

---

[93] Костомаров Н. Императрица Елисавета Петровна: Исторический очерк.— Б/м., б/г.— С. 25.

тын-кызы ислам диненә күчә. Казан губерна канцелярияләре, бу хәл турында хәбәр алгач та, сөннәткә утырган чуашларны чукынырга өндәргә, ә чукынырга теләмәсәләр, аларны камчы белән рәхимсез ярырга боера. 16 мөселман татар чуашны исламга өндәүче дип таныла һәм мәңгелеккә Себергә сөрелә, татарлардан туган бала-чагалар, әти-әнисеннән тартып алынып, чукынган чуашларга тәрбиягә таратыла; урыс диненә күчкән чуашлар гына гаепле дип танылмый[94].

Идел-Урал киңлекләрендә урыс булмаган халыклар арасында православие динен көчләп тарату елларында керәшеннәрнең яңа динне бозмыйча тоту кагыйдәләрен православие руханилары һәрдаим тикшереп торалар. 1744 елның апрель аенда керәшеннәрнең дини йолалар тотуын тикшереп торыр өчен руханилар билгеләргә, епархия җитәкчеләре керәшеннәрне ике елга бер мәртәбә, ә керәшен кантуры җитәкчесе ел саен карап тору хакында синод указ кабул итә.

Урыс булмаган халыкларны күпләп христианлаштыру өчен кулланылган ысуллар ярдәмендә Идел-Урал якларында 1741 — 1755 елларда 335789 кеше православие динен кабул итә. Татарлар 1747 елга кадәр ислам диненә тугры калалар. Шушы елдан татарлар арасында да православие динен кабул итүчеләр арта башлый. 1749 елда 2041 татар кешесе чукына. 1748 — 1755 елларда 9648 татар кешесе православие динен кабул итә.

Христиан динен кабул итүчеләрнең санын этник яктан анализлаганда, иң күбе чуашлар — 178130 кеше, икенче урында марилар — 58729, аннары мордвалар — 40668, вотяклар — 36505, татарлар — 10732 кеше икәнлеге күренә. Чукынучы татарларның иң күбесе Казан, Зөя, Сембер өязләрендә яшәгән. Христианлаштыруның үзәге булып Зөядәге Богородицкий монастыре була. Бирегә көн саен Казан, Әстерхан, Нижгар, Воронеж губерналарыннан 20 — 30, ә кайбер көннәрдә 100 кеше килеп, бераз православие динен тоту тәртипләре белән танышканнан соң, чиркәүдә яисә Зөя суында православие динен кабул иткәннәр.

Данлыклы миссионерлар

Димитрий Сеченов

Татарларны христианлаштыру тарихын тасвирлаганда, чукындыру кантурын төрле елларда җитәкләгән урыс руханилары хезмәтеннән башка күрсәтеп тә булмый. Шуңа күрә көчләү аппараты җитәкчеләре турында кайбер мәгълүматларны махсус биреп китәргә уйладык. Укучылар арасында, бәлки, аерым рухани хезмәтләре хакында җентекләп язу кирәк түгелдер дигән сорау да туарга мөмкин. Без андый фикер белән килешә ал-

[94] Полное собрание... — Сер. II.— Т. 3.— С. 200—202.

мыйбыз. Мөселман татар халкы үз «геройларын» белергә, аларның кылган «батырлыкларына» тиешле бәя бирергә тиеш.

Керәшен кантурының беренче җитәкчесе булган архимандрит Алексий Раифский турында без шактый гына мәгълүматлар алда биргән идек инде. Ул — Идел буенда миссионерлык эшен киң җәелдерү өчен зур хезмәт куйган данлыклы рухани. Кырыгынчы елларда Алексий Раифский шикелле миссионерлар заманы тәмамлана һәм көчләп чукындыру чоры башлана.

XVIII гасырның кырыгынчы елларында көчләп чукындыру, татарларны урыслаштыру сәясәте иң беренче булып Димитрий Сеченов исеме белән бәйле. Русия чиркәү тарихында зур бәя бирелгән шушы рухани чукындыру кантурын җитәкләгәндә, Идел буе халыкларын күпләп көчләп чукындыру, дини эзәрлекләү башлана да инде.

Ул Мәскәү тирәсендә туа, Даниил дип исем кушалар. Мәскәүдәге Славян-грек-латин академиясен (Духовная академия) уңышлы тәмамлаганнан соң, шунда ук 1730 елда оста тел укытучысы (учитель красноречия) итеп билгеләнә. Ике елдан соң, 1732 елны, ул монах була һәм Димитрий исемен ала.

1738 елның ахырында Димитрий Сеченовны Зөядәге Богородицкий монастыре архимандриты һәм керәшен кантуры җитәкчесе итеп кую турында указ кабул ителә. 1740 елның 11 сентябрендә чукындыру эшен киң җәелдерү өчен махсус указга имза салына. Бу указны хәзерләүдә Димитрий Сеченов һәм Лука Канашевичларның өлеше зур булырга тиеш.

Патшабикәдән мондый зур указ алганнан соң, Димитрий Сеченов җитәкчелегендәге миссионерлар православие диненә күчүчеләр санын арттыру өчен көне-төне тырышалар. Төрле юнәлештә алып барылган миссионерлык эше нәтиҗәләре дә күренә башлый. 1741 ел көчләп чукындыру тарихында кискен борылыш елы булып исәпләнә; нәкъ менә шушы бер елда чукынучылар саны утыз мәртәбә арта һәм бу сан 9159 кешегә җитә. Алдагы елларда да чукынучылар саны шактый ишәйсә дә, елына утыз мәртәбә күбәю башка булмый.

Димитрий Сеченов беренчеләрдән булып керәшен авылларында күпләп чиркәү төзү мәсьәләсен хәл итә, аның күрсәтүе буенча агачтан утыз чиркәү керәшен авылларында гына түгел, хәтта мөселманнар гына яшәгән авылларда да төзелә башлый. Иң башта Казан епархиясендә уналты чиркәү төзелә башлый: Казан өязе Җөри юлындагы Түбән Акташ һәм Ямаш, Ногай юлындагы Кутыш, Сембер өязендәге Куроедовка, Царево-Кокшайск өязендәге Нурма авылларында.

Чукынырга теләмәгән мөселманнарны керәшеннәрдән аерып икенче урынга күчереп утырту да бу танылган миссионер исеме белән бәйле. Патшабикә фәрманы нигезендә икенче урынга күчерүне сылтау итеп, мөселманнарны борын заманнан ата-

бабалары яшәгән бай туфраклы, җайлы урыннардан кысрыклап чыгару, яхшы, уңдырышлы җирдән мәхрүм итү башлана. Татарлар арасында керәшеннәр күп булмаганлыктан, алар бигрәк аз җирле халык булып калалар һәм бу хәл Октябрь инкыйлабына кадәр дәвам итә. Халыкның иң беренче байлыгы булган җир мөселманнар кулыннан баскыннар, нәсара динен тотучылар кулына эләгә.

Русия патшабикәсе фәрманы нигезендә 1742 елның 1 сентябрендә Димитрий Сеченов Нижгар епархиясенә епископ итеп билгеләнә. Биредә дә ул, иң беренче булып, урыс булмаган халыкларны чукындыру белән шөгыльләнергә тиеш була[95]. Зөядән Нижгарга архимандрит бик канәгать булып киткәндер, мөгаен. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә Идел буендагы урыс булмаган халыкларны күпләп чукындыру һәм шуның нигезендә урыслаштыру башлана.

Дини эзәрлекләү, халыкны православие диненә тарту иң көчәйгән дәвердә, 1748 елда, Димитрий Сеченов, барча эшен калдырып, гади монах булып Казан тирәсендәге Раифа монастырена килә һәм биредә ул 1752 елга кадәр яши. Бу елны Димитрий Сеченов Русия православие чиркәвенең иң дәрәҗәле югары органы — синод әгъзасы итеп, ә 1757 елда Новгород епархиясенең җитәкчесе итеп тә билгеләнә. Әби патша заманында Димитрий Сеченов патшабикәгә иң якын торган руханиларның берсенә әверелә, Екатерина II не тәхеткә бәхилли. Патшабикә дә аның хезмәтләрен онытмый, аны митрополит дәрәҗәсенә күтәрә, бер мең крәстиянне крепостной итеп бүләк итә, француз Вольтерга язган хатларында аңа, «урыс руханилары арасыннан үрнәк рухани» дип, күркәм характеристика да бирә.

Чукындыру кантуры ябылгач та, Димитрий Сеченов миссионерлык эшен дәвам итә, аны камилләштерү өчен төзелгән махсус комиссия җитәкчесе була, Әби патша тарафыннан яңа законнар чыгару өчен чакырылган комиссия әгъзасы итеп сайлана. Тик анда озак эшли алмый, 1767 ел ахырында кинәт вафат була.

Сильвестр Гловацкий

Епископ Лука Канашевич һәм Димитрий Сеченов тәкъдимнәре буенча чукындыру кантурының җитәкчесе итеп Сильвестр Гловацкий билгеләнә. Синод 1742 елның 17 ноябрендә аңа Зөядәге Богородицкий монастыре архимандриты исемен бирә, 18 декабрьдә ул үз вазифаларын үтәргә керешә. Бу очракта кантур җитәкчесе бәхәссез генә билгеләнә, миссионерлык эше тоткарлыксыз дәвам итә. Шулай да кантур хезмәткәрләре арасында каршылыклар чыккалап торган. Димитрий Сеченов Нижгарга киткәч тә, кантур җитәкчесе булып калу өмете Вениамин Пуцек-Григоровичта да уяна, мөгаен. Бәлки, ул Димитрий Сеченовның синодка язган хат эчтәлеге белән дә таныш та булгандыр. Һәрхәлдә, кантур җитәкчесе итеп Сильвестр Гловацкий билгеләнгәч

---

[95] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 1.— С. 195.

тә, авырыйм дигән хәйлә табып, миссионерлык эшеннән баш тарта башлый. Синод аның фикере белән килешмәсә дә, ул тагын 1743 елның 17 июлендә миссионерлык эшеннән азат итүне сорый. Иеромонах Вениаминның тел төбен яхшы аңлаган синод 1743 елның 14 ноябрендә, «миссиядә һәм семинариядә тырышлыгын исәпкә алып», аны Казан Кремлендә урнашкан Спас-Преображение монастыре архимандриты — җитәкчесе итеп билгеләде. Чукындыру кантурына Вениамин урынына Цивильск шәһәрендә урнашкан Казан Илаһи Ана (Казанская Божья Матерь) рухание, чуаш телен яхшы белүче Тихон Васильев билгеләнә.

Чукындыру кантуры җитәкчесе, күп мәртәбә миссионерлар командасын җитәкләп, төрле төбәкләргә бара, шактый гына татар, ар-удмурт, чирмеш-мариларны чукындыра — 1744 елның ахыры 1745 елның башында ул Вятка провинциясендә миссионерлык эшен алып бара; кантурдан тиз арада акча җибәрүне үтенә, чөнки ул үзе белән алган 1610 тәңкә акчаны чукынганнар өчен бүләк итеп, кием-салым алуга тотып бетергән була. Бу баруында Сильвестр Гловацкий 5000 ар-удмуртны чукындыра. Тик алар арасында татарлар булмаганга охшый, чөнки П.Луппов фикеренчә, татарлар арасында чукынучылар саны елына 5 кешедән артмаган. 1782 елда Глазов өязендә 44 кенә керәшен-татар саналган, ә мөселманнар саны 338 кеше була һәм алар Ильяс, Карино, Починошная авылларында яшәгәннәр[96].

Сильвестр атакай җитәкчелегендәге миссионерлар урыс булмаган халыкларны чукындыру буенча иң зур казанышларга ирешәләр: 1743 елда 10025 кеше, 1744 елда — 4037, 1745 елда — 10986, 1746 елда — 73969, 1747 елда — 113392, 1748 елда — 28914, 1749 елда — 27003 кеше нәсара диненә күчә.

Кырыгынчы еллар ахырында Идел буендагы мәҗүси халыкларны көчләп чукындыру тәмамланып килгән, дисәк тә дөрес булыр; тик мөселман татар халкы гына, урыс миссионерларына каршылык күрсәтеп, ата-бабалар динен саклап калырга тырышалар. Шулай да алар арасында да икътисади, хокукый, сәяси һәм рухи эзәрлекләү нәтиҗәсендә яңа чукынган керәшеннәр күбәя. Архимандрит Сильвестр Гловацкийны миссионерлык эшендә зур казанышлары өчен Казан епископы Лука Канашевич махсус эшләнгән көмеш таяк белән бүләкли. Бу таякка түбәндәге сүзләр язылган була: «Сей посох сделал преосвященный Лука, епископ Казанский и благословил им Свияжского Богородицкого монастыря архимандрита Сильвестра 1749 года декабря 6 дня». Нишләптер бу кадерле таякны Сильвестр үзе белән Себергә алып китмәгән һәм ул Зөядәге монастырьда XX гасыр башында да сакланган була[97].

---

[96] Луппов П. Курс. хезм.— 482—483 б.

[97] Яблоков А. Город Свияжск Казанской губернии и его святыни.— Казань, 1907.— С. 119.

Идел буендагы татарларны һәм мәҗүсиләрне көчләп чукындыру буенча зур тәҗрибә туплаган Сильвестр Гловацкий миссионерлык эшен камилләштерү өчен Себергә озатыла.

Тубыл һәм Себер митрополиты итеп билгеләнгәч тә, Сильвестр Гловацкий Идел буендагы шикелле үк көчләп чукындыруны яңа урында да дәвам итә. Себер татарлары миссионерларның көчләве турында сенат-синодка туктаусыз шикаятьләр язып торалар. 1750 елның 13 ноябрендә, 1751 елның 6 апрелендә, 23 июнендә, 5 июлендә язган хатларында митрополит: «Себер татарларын көчләп чукындыру очраклары юк»,— дип җавап бирә[98].

Митрополит Сильвестр Гловацкий җитәкчелегендәге дини эзәрлекләү, урыслаштыру максаты белән нәсара диненә тарту Тубыл якларында да әллә ни зур нәтиҗә бирми, биредә дә мөселманнар үз диннәрендә нык торалар, тик мәҗүси халыклар гына урыс диненә күпләп күчәләр. Бу хакта берничә мисал китерәбез. Себердә отчет буенча 1750 елда 1052 кеше нәсара диненә күчкән булып исәпләнә. Алар арасында иң күбе Краснояр өязендә яшәүче телеутлардан 1000 кеше, ә Тубыл татарларыннан 20 генә; тагын Исәт провинциясеннән 10 башкорт һәм сөргенгә сөрелгән 3 татар һәм башкорт чукындырыла. 1751 елда чукынучылар саны 1658 кешегә җитсә дә, алар арасында бары тик 6 Тубыл татары, ә чукынучылар арасында башкортлар һәм сөргенгә сөрелгән мөселманнар юк. 1752 елда Исәт провинциясендә татар, башкорт, мишәрдән 6 кеше генә урыс диненә күчә; 1753 елда шул ук провинциядә 29 башкорт, мишәр һәм чирмеш чукына[99].

Себер татарларының митрополит Сильвестр үткәргән миссионерлык эшенә нәфрәте, сенат һәм синод исеменә язылган шикаятьләре, бигрәк тә халкыбызның мәшһүр улы Батырша җитәкчелегендәге восстание бу руханины мөселманнар булмаган иженче урынга күчерү өчен этәргеч була. 1755 елның көз айларында ул Тубыл епархиясеннән китәргә мәҗбүр була.

Евмений Скаловский

Евмений Скаловский Зөядәге Богородицкий монастыре архимандриты һәм чукындыру кантуры җитәкчесе итеп 1750 елның 7 февралендә билгеләнә һәм ул вазифаны ундүрт ел буенча, кантур ябылганга кадәр тырышып үти[100]. Казан епискобы Лука Канашевич 1749 елның 11 октябрендә синодка Зөядәге Богородицкий монастыре архимандриты итеп Евмений Скаловскийны тәкъдим итә һәм аңарга бик уңай характеристика бирә: «Казан семинариясендә укытучы буларак балаларны игелекле тырыш хезмәткә тәрбияли, урыс булмаган халыкларга Алла сүзен белеп тарата, чиркәүләрдә вәгазьләр укып, зур абруй казана».

---

[98] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 3.— С. 439.
[99] Описание документов...— Т. 31.— С. 474—480.
[100] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 4.— С. 33.

Лука Канашевичның синодка язган бу хаты Евмений Скаловскийның язмышын хәл иткәндә зур роль уйнагандыр, мөгаен, чөнки ул 1750 елның 25 мартыннан рәсми рәвештә монастырь архимандриты булып эшкә керешә[101].

1750 елларның урталарына кадәр дини һәм милли эзәрлекләү, татар һәм башка халыкларны көчләп чукындыру сәясәте Евмений Скаловский җитәкләгән чукындыру кантуры тарафыннан һичшиксез тормышка ашырыла. Бу вакытта инде мәҗүси халыкларның күбесе православие диненә күчә, мөселманнар миссионерларга каршылык күрсәтүне дәвам итәләр. Православие руханиларының бөтен басымы мөселманнарга юнәлтелә. Миссионерларның хезмәте дә әкренләп үзгәрә, алар, нәсара диненә күчкән халыкларны яңа дингә күнектерү җәһәтеннән, күбрәк чиркәүләр салу, керәшеннәргә христиан догмаларын өйрәтү белән шөгыльләнәләр. 1751 елның 3 июнендә сенат яңа чукынган халыклар яшәгән авылларда, 150 йорт-хуҗалыкка бер чиркәү салу ниятеннән, 33 яңа чиркәү төзү турында карар кабул итә. Бу вакытта инде хөкүмәт акчасына чукынган халыклар арасында 208 чиркәү салынган була[102]. Миссионерлык эшен ул елларда иеромонах Ианиуарий Светловский, Зөядәге Рождественский чиркәве протопобы Георгий Давидов, Казандагы Владимир чиркәве протопобы Иоанн Орловский, Цивильск шәһәре Троицкий чиркәве протопобы Тихон Васильев алып баралар. Шул ук вакытта урыс диненә өндәүче (проповедник) итеп Алексей Федоров та билгеләнә.

XVIII гасырның алтмышынчы елларында чукындыру кантуры оештырган миссионерлык эшендә йомшаклылык сизелә, мөселманнарны һәм мәҗүси халыкларын нәсара диненә тарту буенча яңа омтылышлар күренми. Бу вакытта инде мәҗүсиләр күбесе чукынган, мөселманнарны көчләү әллә ни нәтиҗә бирми. Патша тәхетенә Екатерина утыру да бу вазгыятькә тәэсир иткәндер, мөгаен. Евмений Скаловский миссионерлык эшен алып барган 1742—1764 елларда үзе генә дә йөз мең кешене урыс диненә күчерә. Ул 1767 елга кадәр Зөядә архимандрит булып хезмәт итә.

Аксак Каратун

Казан епархиясенең епискобы Лука Канашевич халкыбыз хәтерендә Аксак Каратун исеме белән сакланган. 1738 елдан 1755 елның ахырына кадәр урыс булмаган халыкларны дини һәм милли эзәрлекләү, корал һәм камчы ярдәмендә православие диненә күндерү, аларны көчләп чукындыру сәясәтен тормышка ашыруда иң мөһим, төп рольне уйнаган бу зат тарихта аерым урын алып тора.

---

[101] Описание документов...— Т. 29.— С. 567—568.
[102] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 3.— С. 310—313.

Күренекле миссионерның кылган эшләрен тәфсилләп күрсәтер алдыннан бер искәрмә биреп китү зарур дип уйлыйбыз, чөнки күп кенә язмаларда Лука Канашевич чукындыру конторы җитәкчесе итеп күрсәтелә[103]. Бу дөрес фикер түгел, күп китапларга кергән уйдырма гына. Казан епархиясенең җитәкчесе, ягъни епископы булган Лука атакай чукындыру конторы белән турыдан-туры җитәкчелек итмәгән, ул Зөядәге Богородицкий монастыреның архимандриты булмаган. Казан епархиясе җирләрендә урнашкан Зөя монастыре, чукындыру конторы миссионерлары, епископның кыйммәтле киңәшләрен тыңлап, «изге эш» алып барганнар.

Лука Канашевич Украинада туып үсә, мәшһүр Киев академиясендә белем ала. Ул заманда бу уку йорты православие руханиларын хәзерләү буенча иң мәртәбәледән исәпләнә. Соңыннан ул Киев шәһәрендә урнашкан София монастыренда монах була, аннары Мәскәү академиясендәге башлангыч классларга укытучы итеп билгеләнә. Санкт-Петербургта дворян балалары өчен махсус ачылган кадет корпусына иеромонах итеп куела. Башкалада хезмәт иткәндә үк ул миссионерлык эше белән кызыксына, мөселманнарны, мәҗүсиләрне, чит ил гражданнарын урыс диненә күчерүдә катнаша. Санкт-Петербург тирәсендә артиллериядә хезмәт иткән Енидеев фамилияле бер татар 1732 елда православие диненә күчү турында теләк белдерә. Изге синод аны православие диненең нигезләре белән таныштыру өчен Лука Канашевич янына озата. Лука татар егетенең православие дине нигезләрен яхшы үзләштерүе турында 1732 елның 14 октябрендә синодка хәбәр итә. Енидеевны Исаак соборы протопобы Иосиф Чедневский 25 октябрьдә чукындыра һәм аңарга Дмитрий дигән исем куша[104]. Аның 1734 елда француз Мелард һәм ике японны православие диненә күчерүе дә билгеле.

Берничә елдан Лука Канашевич Мәскәүдәге Симонов монастыре архимандриты итеп билгеләнә, ә 1738 елның гыйнвар аенда Устюг епархиясенә епископ итеп куела. Шул ук елның 9 мартында аны Устюгтан Казанга күчерү турында фәрман кабул ителә. Ул Казанга җәй уртасында, июль аенда килә һәм биредә унҗиде ел — 1755 елның көзенә кадәр Русиядәге иң зур епархияне җитәкли, Идел буендагы урыс булмаган халыкларны күпләп көчләп чукындыру буенча зур эш алып бара. Ул бигрәк тә Казанда православие диненең тулаем җиңүе, ә Казанны урыс шәһәренә әйләндерү өчен тырыша.

Сакланып калган риваятьләргә караганда, Аксак Каратун, Казан мөселманнарын чукындырыр өчен, төрле ысуллар фай-

---

[103] Гилязов И.А. Политика царизма... // Материалы по истории татарского народа.— Казань, 1995.— С. 251.; Церковь в истории России...— С. 197.; Садур В.Г. Күрс. хезм.— 423 б.; Фаизов Г.Б. Күрс. хезм.— 42 б. һ.б.

[104] Описание документов... — Т. 12.— С. 526.

далана. Бер сәүдәгәр Идел буе калмыкларыннан берничә яшь углан сатып алып килгән икән. Шуларны бер мөәзин иманга инандырган, ягъни ислам диненә күчергән. Янәдән Гайсә дигән бер баба ул калмыкларны сөннәткә утырткан. Ахыр бу эш урыс түрәләренә ишетелеп, бу өч калмыкны газаплап чукындырганнан соң, Гайсә бабаны чиркәү астына ябып асрыйлар, ахырда ул шунда вафат була. Ә сәүдәгәр урыс диненә ихлас булып кылана. Шул арада мөәзин белән Мәскәүгә барырга сүз куя. Мөәзин яшерен рәвештә Казаннан Мәскәүгә юл ала, ә сәүдәгәр, Аксак Каратун кушуы буенча, Ногай юлы һәм Кама арты халкын чукындырырга китә. Аңарга аракы, прәннек, билбау, берничә мичкә хач-тәре биреп чыгарып җибәрәләр. Тик ул, мөселманнарны чукындыру белән шөгыльләнмичә, архиерей биргән әйберләрен сатып, акча ясап, Мәскәүгә китә. Ука суында коенганда мөәзинне очрата. Шуннан соң, патшага Казан татарларының архиерейдан күргән җәфаларын теркәгән кәгазь биреп, үзләре Идел буендагы мөселманнарны чукындыруны төрек патшасына җиткерү өчен Истанбулга китәләр. Истанбулда хәлифәгә урысның мөселманнарны дин турында кысып газаплаганын сөйләгәч, урыска Истанбулдан илче җибәрелә[105]. Бу дипломатик адымның Русия мөселманнары өчен файдасы булмый.

Лука атакай миссионерлык эшенә барлык көчен биреп, ихлас күңелдән бөтен мөселман һәм мәҗүсиләрне, урыс диненә күчереп, чын урыска әйләндерер өчен тырыша. Тик ул кулланган ысуллар рухани-түрәләр тарафыннан да хупланмаган бугай, чөнки ул Казанга епископ булып килә, епископ булып китә. Ә бит Казан руханилары 1749 елның 22 июлендә синодка Лука Канашевичның миссионерлык эшендәге уңышларын, керәшен мәктәпләре, чиркәүләр төзүдә тырышлыгын исәпкә алып, аңарга митрополит исемен биреп булмаса, архиепископ исемен бирүне сорыйлар. Тик бу хат эзсез югала, данлыклы миссионер дәрәҗәле исем ала алмый.

Татар халкы хәтерендә Лука Канашевич турында риваятьләр дә сакланган. Аларның берсендә мондый кызык юллар бар: «Күп еллар элек, Казанда мәчетләр булмаганда, урыс патшасы мәчет төзергә рөхсәт бирмәгән чорда, мөселманнар өйләрендә генә дога кылырга мәҗбүр булалар. Шул чорда Казанда бер архиерей яши. Ул бөтен татарны урыслаштырмакчы була. Ул күп кенә татарга урысларның кара чапанын һәм ыштанын кидертә, күп кенә мөселманны чукындыра. Татарларның теләген исәпкә алмыйча, архиерей аларны урыс итмәкче була, дип, татарлар министрга хәбәр итәләр. Министрлар архиерейны ачуланалар һәм Себергә сөргенгә сөрәләр». Риваятьнең икенче варианты буенча Лука Канашевичны Казаннан Зөядәге монастырьга сөргенгә озаталар.

---

[105] Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар.— Казан, 1987.— 70—71 б.

Күп кенә мөселманнар аны коточкыч хәлдә күрәләр. Монастырь ишегалдында ул тузып, ертылып беткән киемдә, муены борылып артка карап йөри икән[106]. Бу риваятьнең өченче варианты да бар, анда Аксак Каратун болай сурәтләнә: «Аксак Каратун, Зөя монастыренда күп гомер сөреп, ахырында йөзе тискәре әйләнеп вафат булмышдыр. Безнең бистә халкы, Мәкәрҗәгә барганда, монастырь ишегалдында койма ярыгыннан карарлар икән. Аксак Каратун һаман арлы-бирле шунда йөрер икән; йөзе тискәре килгән икән. Патшаның әмере белән Аксак Каратунны төшереп монастырьга куйганнан соң, мөселманнар бераз иркенләп йортлар һәм мәчетләр сала башлаганнар»[107].

Әлбәттә, Лука Канашевич мөселманнарны рухи эзәрлекләү, көчләп чукындыру өчен җавапка тартылмый. Шулай да ул 1755 елның 9 октябрендә Казаннан Белгород епархиясенә күчерелә һәм биредә 1758 елның 1 гыйнварында вафат була.

1741 —1755 еллардагы дини сәясәткә йомгак ясаганда, мондый нәтиҗәгә килеп булыр иде. Хакимият белән бергә эш алып барган миссионерлар нәкъ менә шушы елларда урыс булмаган халыкларны христианлаштыруда моңарчы булмаган нәтиҗәгә ирешәләр. Православие дине позицияләрен ныгыту, Русия составына кергән халыкларның дини үзбилгеләмәсен үзгәртү өчен алып барылган миссионерлык эшенең нәтиҗәләрен элек үткәрелгән дини сәясәтнең җимеше дип тә, икенче яктан дәүләтнең һәм руханиларның комплекслы, эзлекле, катгый тырышлык нәтиҗәсе итеп санарга да мөмкин. Күптән куелган максатка ирешү юнәлешендәге бу нәтиҗәне моңа кадәр мондый уңышларга ирешә алмаган православие миссионерларының триумфы һәм иң югары ноктасы дип карау дөрес булыр.

Белгәнебезчә, миссионерлар православие динен кабул итү өчен өндәү, мәҗбүри чаралар, көчләү кулланалар. Шушы төрле ысуллар арасында иң эффектив экономик (салымнардан азат итү), социаль (рекрутлыктан, коллыктан, суд җаваплылыгыннан азат итү), административ (мәчетләрне җимерү, 200 — 300 йорт булганда гына мәчетләр төзергә рөхсәт), оештыру (керәшеннәр өчен махсус приходлар оештыру, керәшеннәрнең дин тотуын катгый күзәтү), финанс (христиан динен кабул иткән өчен премия, аларга муенга асу өчен тәре, почмакка куярга икона һ.б. бушлай бирү) ресурсларны атап булыр иде. Алар очраклы, даими булмаган чаралар түгел, ә системалы, бер-берсе белән нык бәйләнгән һәм үзгәреп торган алымнар. Указ-законнар нигезендә алып барылган христианлаштыру кампаниясен дәүләт тарафыннан оештырылган эш икәнлегенә дәлил булып тора. Христианлаштыру кампаниясендә руханилар тарафыннан правос-

---

[106] Малов Е. Курс. хезм.— 219 б.
[107] Татар халык иҗаты...— 72 б.

лавие динен тарату өчен күрелгән чаралар эффектив һәм зур урын алган дип әйтә алмыйбыз. Киресенчә, башка ысуллар белән чагыштырганда, аларның роле минималь. Керәшеннәрне православие дин кануннары таләпләре буенча яшәүче итеп тәрбияләү юнәлешендәге эш тә чиркәүләр салу, керәшен авылларында приходлар оештыру һәм керәшен мәктәпләрендә поплар хәзерләү белән чикләнә.

Башка диннәрне бетереп, Русияне православие дәүләтенә әверелдерүне максат итеп куйган күпләп христианлаштыру сәясәтен тормышка ашыру мөселманнарда табигый ризасызлык тудыра, күпләрдә нәфрәт уята. Халыкның мондый сәясәткә каршы көрәше Башкортстандагы 1755 ел восстаниесе белән тәмамлана.

Башкортстанда дини һәм социаль-икътисади изүнең көчәюе

Башкортстан күп еллар Русия составында булуга карамастан, XVIII гасырның 30 нчы елларына кадәр автономия саклангһанлыктан, биредә ислам диненә каршы катгый эшләр алып барылмый торган территория булып, дини кысрыклау Идел буендагы шикелле бик көчле булмый. Шуңа күрә дини көчләүдән татарлар, башкортлар ягына күчеп килеп, ислам динен саклап калдылар. Бу Русия җитәкчеләрендә зур ризасызлык тудырса да, вакытлыча моңа каршы махсус чаралар кулланылмады. Башкортстанда крепость-кальгалар, заводлар төзү, аларга урысларны күчереп утырту, бу төбәкне Русия составына интеграцияләү өчен кулланылган махсус чаралар биредә яшәгән халыкның тормышында зур үзгәрешләр тудыра, биредәге мөселманнарга караш та үзгәрә.

XVIII гасырның 50 нче еллары башында Тубыл митрополиты итеп билгеләнгән атаклы миссионер Сильвестр Гловацкий Башкортстанның көнчыгыш төбәкләрендә, Исәт провинциясендәге башкортлар һәм татарлар арасында миссионерлык эшен активлаштырып җибәрә. Бу хакта Мөслим старшина болай дип сөйли: «Әй вәли нигъмәт, ни өчен сорыйсың, хәзрәтеңезгә мәгълүмдер, кяфернең җәфасы сәбәбеннән җилкәмез сынгандыр, Хак Тәгалә аларның җилкәләрен сындырган, өметләрен өзгән. Бәнем калганнан байтак кешене хәйләләр, куркытулар берлә диндән чыкардылар, вә һәм Салҗугут иләүендән күп җәмәгатьне әһел вә әүлады илә диндән харап иттеләр. Мишәр халкы вә вернай башкорт халкы ярлыкауны барчалары торсыннар, йортларында кадими кагыйдәләренчә, дию. Имдегәгә безнең диндәшләремез инсафә килүб, йорт яман булган ирде. Ахыр вадна-сыз кяфернең җанибендә фетнә кимемәйдур, көндән-көн фетнәләр артадур. Бу хәлдә һәм фетнә пәйда булып торадур. Указ

укылган: «Илтабан ыстаршина командасы берлә ислам динен ташлаб рус диненә керсеннәр. Йәки үзләренең борынгы бабаларының диненә, чуаш диненә кайтсыннар, дип, Хак Тәгалә хәзрәте белгүчедер. Бу кяфернең җәфасы сәбәбендән ни хәлләр пәйда булыр»,— диде[108]. Шундый ук хәл Әй елгасы үзәнлегендә күзәтелә Уфа өязенең Ногай юлы халыклары да көрәшкә чыгарга хәзер булалар.

Бирегә башкортлар белән килешеп яшәгән йомышлы татарларга хөкүмәт тарафыннан өстәмә 25 тиен, ясаклыларга 80 тиен салым салу аларга икътисади авырлык китерә, ризасызлыкны арттыра.

Башкортстанның көнбатышында, бигрәк тә Ногайбәк крепосте тирәсендә, Казан епискобы Лука Канашевич миссионерларының активлыгы, бу якларга татарлардан һәм башка халыклардан керәшеннәрне күчереп утырту, аларны казак сословиесенә теркәп, башка мөселман халыкларына караганда өстенлекләр бирү христианлаштыру процессының бу төбәктә активлашуын күрсәтә. Уфа өязенең Уса һәм Казан юлларында яшәгән халыклар, диндә һәм җәмгыяви эшләрдә чамасыз изү кичергәнлектән, бөтенләй хәлсез дәрәҗәсенә җиткерелә.

Башкортстандагы халыклар арасындагы ризасызлыкны бирегә күпләп күчеп килүчеләр катлауландыра. Урыс миссионерларының төрле төбәкләрдә көчләп чукындыру юнәлешендәге эшләре бирегә дә билгеле булып тора, халык арасында шомлы хәбәрләр тиз таралып, ризасызлыкны арттыра.

Белгәнебезчә, христианлаштыру процессын тизләтү өчен, урыс миссионерлары халыкны икенче урынга күчереп утырту ысулын бик оста кулланганнар. Бу гамәлне яхшы аңлаган архимандрит Димитрий Сеченов мөселманнар һәм мәҗүсиләр, йортларын һәм җирләрен югалтудан куркып, барысы да «үзләре теләп» чукыныр дип исәпләгән. Мөселманнарны керәшеннәрдән аерып яшәтү, авылдан авылга күчерү иң башта татарларга каршы кулланыла. Синод кабул иткән бер документта мондый юллар бар: «Татарлар арасында гына чукынганнарны күчереп утыртырга кирәк, ә башка халыклардан булган чукынганнарны тимәскә, аларны күчереп кимсетү бу гади халыкны чукындыруга киртә булырга мөмкин. Динсез, гади һәм әшәке мәҗүсиләрдә тирән дин тоту юк, ә ислам диненнән, дини өндәүгә, үгет-нәсихәткә карап, үзләре теләп изге православие динен кабул итүчеләр юк»[109].

Игътибар итегез, бу документ православие миссионерлары мәҗүсиләрне динсезләр рәтенә кертсә, ә мөселманнарның үзләре теләп христиан диненә күчүләрен инкяр итә торган өстәмә

---

[108] Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне.— Уфа, 1993.— С. 35.

[109] Описание документов...— Т. 50. — С. 723.

мөһим чыганак булып тора. Тормышта очраган мохтаҗлык кына татарларны православие динен кабул итәргә мәҗбүр итә. Шуңа күрә хакимият тә, урыс чиркәве дә христианлаштыру өчен мәҗбүри чаралар системасы булдыру кирәклеген яхшы аңлаганнар. Биредә күчереп утырту мөһим урын тоткан.

Үзләре теләп элек яшәгән урыннардан китүчеләр булмаслыгын яхшы аңлаган хакимият, керәшен кантуры белән беррәттән, күчү-күченү белән махсус шөгыльләнү өчен дворяннардан җитәкче билгели. Бу эш белән төрле елларда төрле кешеләр шөгыльләнә. Алар арасында иң нәтиҗәле эшләгәне Борис Ярцев була. Идел-Урал якларында яшәгән халыкларны күпләп христианлаштыруда уңышларны Лука Канашевич, Димитрий Сеченов, Сильвестр Гловацкий һәм Евмений Скаловский белән Борис Ярцев та уртаклаша.

Патшабикә указы нигезендә башта керәшеннәрне элегрәк чукынганнар яисә урыслар арасына күчереп утырту карала. Православие диненә күчүчеләр өчен алпавытларның иң уңдырышлы, яхшы җирләрен бүлеп бирергә, ә чукынырга теләмәгән мөселманнарны керәшеннәр күчеп киткән авылларга урнаштырырга тиеш булалар[110]. Тик чукынган керәшеннәр үз авылларыннан китәргә теләмиләр, ә аларны күчереп утыртуны нәсара диненә күчкән өчен Алланың җәзасы дип тә карый башлыйлар. Шуңа күрә Сарытау һәм Царицын арасына керәшеннәрне күчереп утырту нияте дә тулысынча тормышка ашырылмый.

Күчереп утыртуда килеп чыккан каршылыкларны хакимият көч куллану белән чишү өчен, 1744 елның 1 мартында чыккан указ нигезендә керәшеннәрне саклау, чукынырга теләмәгәннәрне авылдан авылга күчерү өчен, Казан һәм Нижгар губерналарына хәрбиләрдән майор яисә обер-офицер, 1 капрал һәм 12 солдат билгеләнә. Керәшеннәрне саклаган хәрбиләрне монастырьларга урнаштыралар. Зөядәге Богородицкий монастыренда 1 майор, 1 капитан, 4 поручик, 1 сержант һәм 6 солдат урнаштырыла; Казан Кремлендә урнашкан Спас-Преображение монастыренда 1 майор, 1 капитан, каптенармус, капрал һәм 4 солдат була[111].

Чукынырга теләмәгән һәрбер мөселман кешесе икенче авылга күчерелергә тиеш була һәм бу шулай эшләнә дә. Чукынырга теләмәгәннәрне күчереп утырту Идел буенда гына түгел, башка төбәкләрдә дә киң кулланылган. 1745 елны Тубыл митрополиты Антоний Тубыл шәһәреннән 62 йортта торучы татарларны шәһәрдән читкә күчерергә тели. Ул вакытта себер татарлары шәһәр уртасында яшәгән була. Митрополит татарлар яшәгән урында кунакханә төзүне кулайрак күрә. Аның фикеренчә, Тубыл

---

[110] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 1.— С. 417.
[111] ТР МА.— 3 ф. 5 тасв., 511 эш. бер., 25, 42 б.

шәһәрендә татарларның урыслар белән бергә яшәве христиан диненә ифрат зур зыян китерә; кайбер урыслар татар хатыннары белән бергә яшәгәнлектән, урыслар белән әшәке татарлар арасында кушылып, кан бозылу очраклары булгалый; шәһәрдә мәчет булу керәшеннәргә яңадан мөселманлыкка кайту мөмкинлеге тудыра. Шуңа күрә татарларны Тубыл шәһәреннән икенче урынга күчереп утырту турында карар кабул ителә[112].

Казан өязендә чукындырылган яңа керәшеннәрне элекке керәшен авылларына күчерәләр. Бу күренеш ул чорда үткәрелгән халык санын исәпләү материалларында чагылыш тапкан. Сасна авылында чукындырылган Мирон Осипов 1755 елда керәшен кантуры карары нигезендә Көшкәт авылына күчерелә һәм Марина Семеновнага өйләндерелә. Сәет Сәетов чукындырыла һәм, Савелий Дмитриев исеме алып, Оры авылыннан Чепьягә күчерелә дә шунда керәшен кызына өйләндерелә. Муртыш Тамак авылыннан керәшен Алексей Иванов Шәле авылына күчерелә һәм шунда керәшен кызы Окулина Моисеевнага өйләнә. Ташкирмән авылына Әтрәчтән 6 керәшенне күчерәләр[113].

Биредә китерелгән чыганак турында өстәп тагын шуны әйтергә мөмкин: сүз рекрутлыктан котылу өчен чукынган татар егетләре турында бара; аларны, керәшен авылына күчерү белән, керәшен кызларына өйләндергәннәр. Шуңа күрәдер, халык санын алу материалларына караганда, ирләр хатыннарыннан ким дигәндә 4 — 5 яшь кечерәк.

Чукынырга теләмәгән татар һәм башка халыкларны күчереп утырту бик зур каршылыкларга очрый. Кем генә, үз теләге белән туган авылын ташлап, икенче урынга күчеп китсен соң? Ә үз авылларын ташлап китәргә мәҗбүр булган татарлар, хакимият күрсәткән урынга урнашмыйча, үзләре сайлаган җиргә төпләнәләр. Борис Ярцев мәгълүматларына караганда, чукынмаганнарны тыңлатып булмый, хакимият күрсәткән урынга күчмиләр, алар урынына күчеп килгән керәшеннәрне кертмиләр, шуңа күрә күчерүдә зур кыенлыклар туа.

Шушы хакта бер мисал да китереп үтик. Кама аръягындагы Кутема авылына күчеп килгән мордвалар Ширбән авылы татарларына шикаять язалар: имештер, алар, сөрү һәм печән чапкан җирләрне тартып алып, кырда җиткән уңышны урак белән урып, өйләренә алып кайтып рәнҗетәләр, бөлгенлеккә төшерәләр. Татарлар аларны изге урыс диненә күчкән өчен кимсетәләр. Казан өязе Ширбән авылына бу хәлне тикшерергә килгән солдатларга алар үзләренең кайдан күчеп килүләрен әйтмиләр. «Бирегә 100 солдат килсә дә, аларны тыңламыйбыз, кусагыз да, икенче урынга китмибез, биредә үләбез, әгәр дә советник үзе

---

112 Полное собрание...— Сер. II.— Т. 2.— С. 432—434.

113 ТР МА.— 3 ф., 2 тасв., 426 эш. бер., 468, 505 б.; Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII в.— Казань, 1908.— С. 178.

килеп чыкса, ул биредә үзенең сөякләрен дә эзләп тапмас!» — дип куркыталар[114].

Шундый ук хәлләр Иске һәм Яңа Ибрай, Каменка авылларында да күзәтелә. Биредә яшәгән татарларны чукынган очракта гына авылларында калдыру турында керәшен кантуры карар кабул итә.

1743 елның 26 июлендә керәшеннәрне Уфа губернасына, Ырынбурдан Казанга бара торган яңа юл буена күчереп урнаштыру турында сенат карар кабул итә. Бирегә күчерелгәннәргә салымнардан ташлама бирелә, алар казна файдасына үтәлгән эшләрдән азат ителә. Бирегә күчерелгән керәшеннәрне аерып, иң яхшы урыннарда төзелгән махсус бистәләрдә яшәргә, авылларда чиркәүләр төзү боерыла. Шушы указны тормышка ашыру нәтиҗәсендә хәзерге Татарстан Республикасына кергән Абрамовка, Кәләй, Илтән-Бота, Түбән Абдул авыллары барлыкка килә[115].

Ык буенда урнашкан Ногайбәк крепостена һәм ул тирәдәге авылларга керәшеннәрне күчереп утыртуны да уңышлы дип исәпләргә мөмкин. Алардан 1736 елда салым алынуы, биредәге җирләрне милек итеп тапшыру, казак булып хәрби хезмәт итүгә алыну турында без элегрәк язган идек инде. Крепостьта керәшеннәрне христиан диненә өйрәтү өчен священник-поп була. 1746 елда биредә чиркәү төзелә. Шул ук вакытта Бакалыда да чиркәү төзелә. Миссионерларның даими тырышлыгына карамастан, керәшеннәрнең дини яктан зәгыйфьлеген күрсәтә торган чыганаклар саклана. Ногайбәк-казаклар православие динендә исәпләнсәләр дә, тирә-якта яшәгән мөселман татарлардан аерымлыклары сизелми. Алар яңадан ислам диненә кайтырга мөмкин дигән фикер урыс руханилары арасында борчу тудыра. Христианлаштыру эшен тикшерергә килгән миссионер Евмений Скаловский боларны күреп бик борчыла һәм биредәге кайбер татарларны көчләп чукындырып та китә.

Ногайбәк крепосте һәм ул тирәдәге авылларга төрле төбәкләрдә чукындырылган мөселманнарны китереп утырталар. 1752 елда бирегә христиан динен кабул иткән 45 иранлыны, 12 гарәпне, 3 бохаралыны, 2 каракалпакны күчерәләр. Төрле сәбәп аркасында чукынган татарларны бирегә күчереп казак сословиесенә язганнар. Бер мисал китерәбез. Уфа өязе Казан юлындагы Зичибаш авылында яшәгән Рамазан Аптиков, 23 тәңкә бурычын Яңабирде исемле кешегә кайтару вакыты җиткәч, аның атын урлап, Ногайбәк крепостена килә һәм христиан динен кабул итү теләген белдерә. Ул шунда ук чукындырыла һәм Бисипов дигән керәшен авылына җибәрелә[116].

---

[114] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 2.— С. 86—87.

[115] Габдуллин И. Движение крещеных татар по возвращению в мусульманство // Әлмәт—Альметьевск.— Казань, 2003.— С. 139.

[116] Витевский В.Н. Курс. хезм.— 441 б.

П.Рычков мәгълүматларына караганда, Ногайбәк крепосте тирәсендә 10 керәшен һәм чиркәүле Бакалы авыллары булып, биредә 1359 казак исәпләнгән. 1768 елда Ногайбәк крепостенда 450 урыс, 685 мөселманнардан христиан дине кабул иткән казак яшәгән. Казаклар арасында төрле кавем, тел кешеләре күзәтелсә дә, күбесе Казан артыннан килгән татарлардан булуы турында аларның гореф-гадәтләре, телләре яхшы күрсәтә.

Бирегә күчерелгәннәргә казак хәрби хезмәтен тиешлечә үтәү дә җиңел булмаган. Христиан динен кабул иткәннән соң бирегә күчерелгән башкортлар, татарлар һәм башка халыклар казак булып хезмәт итәргә теләмиләр, элекке тормышларын үзгәртмичә дәвам итәселәре килә. Һәрдаим хакимият күзәтүе астында булган, төрле өстенлекләр биреп күчерелгән керәшеннәр, биредә яшәгән җирле халык белән хисаплашмыйча, җирләрне, башкортлар белән килешмичә, акча түләмичә тартып алганнар. Башкорт старшинасы Тимер Мютин язуына караганда, Ырынбур губернасына күчеп килеп урнашкан керәшеннәрдән казаклар башкортларны рәнҗетәләр, аларны талыйлар. Алар башкорт җирләренә рөхсәтсез, сатып алмыйча утыралар, оброк түләмиләр. Җир сатып алганда бөтен вулысның рөхсәте урынына аерым башкортлар белән килешеп эш итәләр. Сенат «башкортларны кимсетмәскә» дигән карар чыгарса да, чынбарлыкта ул башкортларны сакларга ярдәм итми.

Көчләп чукындыру чоры белән нык бәйләнгән татарларны Сәгыйть бистәсенә күчерүне уңышлы дип исәпләргә мөмкин. 1744 елның яз айларында губернатор И.И.Неплюев хәбәр итүенә караганда, Ырынбур шәһәренә күчеп килүчеләргә зур өстенлекләр бирелүгә карамастан, бик әкрен бара; бирегә күчеп килергә бик аз кеше теләк белдерә, килгәннәре дә бик фәкыйрьләр, сәүдә белән шөгыльләнергә хәлләреннән килми. Кыргыз-кайсак халкы, Урта Азия халыклары белән уңышлы сәүдә алып барган татарлар, христианлаштыру чорында һәрдаим дини кысрыклау астында булуга карамастан, мөмкинлектән файдаланып, патшабикәдән Ырынбурга күчеп утырырга, сәүдә итәргә, ислам динен иректе тотарга, мәчетләр салырга рөхсәт сорыйлар. Сенат бай, таза тормыш алып барган Казан, Себер, Вятка провинцияләрендә яшәгән 200 татар гаиләсенә Ырынбурга күчеп килергә, шәһәрнең үзендә түгел, ә читтәрәк мәчет төзергә рөхсәт бирә. Шушы указ нигезендә Ырынбурдан ерак булмаган Сәгыйть (Каргалы) бистәсе төзелә. Казан өязе Саба авылыннан чыккан Сәгыйть Хәялин 1745 елның 8 августында бирегә килеп урнаша. Башка җирләрдә мәчетләрне ваткан чорда биредә 4 мәчет төзергә, балалар өчен мәктәп-мәдрәсәләр ачарга рөхсәт бирелә. Тарихчы Айдар Хәбетдинов фикеренчә, Каргалыда тарихта беренче мәртәбә Русия хөкүмәте һәм татарлар арасында хезмәттәшлек моделе барлыкка килә. Татарлар Русия хөкүмәтенең икътисади һәм сәяси интересын казакъ далаларыннан, Урта Азиядән Һинд-

станга кадәр тәэмин итсә, дәүләт татарларга ислам динен иреклә тотарга, сәүдә алып барырга рөхсәт бирә[117].

Сенат карары буенча 1744 елда Казан губернасына 1119 Әстерхан татары күчерелә башлый. Аларның балалары, солдат итеп хәзерләү өчен, Архангельск һәм Рига гарнизоннарына озатыла. Бу татарлар Казан губернасына күчеп килгәч тә чукынырга мәҗбүр булалар. Казан өязе Алат юлындагы Арбор (хәзерге Балтач районы) авылында яшәүче Әстерхан татары Кудай Алеев чукынгач Степан Афанасьев исемен ала һәм бередә мәңгегә калдыруны үтенә[118]. Әстерхан татарларының Казан якларына күчеп килүләре турында кайбер мәгълүматларны 1762 елда үткәрелгән перепись материаллары да саклый. Казан өязе Арча юлындагы Сәфәр йөзбашның Борнай авылында туксан яшьлек Бабик Байкаров хатыны Фатыйма Батыршина, балалары Тонали, Ялкай, Тоналиның балалары Котлыбаш һәм Җамал белән яшәгән. Шунысы кызык, ирләр «солтанаул татарлары» дип язылсалар, хатын-кызлар «ногай» дип теркәлгән[119].

Дини эзәрлекләү, корал һәм камчы ярдәмендә алып барылган миссионерлык эшенә түзә алмаган татарлар Идел буеннан Урал, Себер якларына күпләп күчеп утыра башлыйлар. Дамир Исхаков мәгълүматларына караганда, 1719 —1744 елларда Урал якларына 50000 татар күчеп китә, аларның 30000е Казан өязеннән була. 1744 —1762 елларда Уфа өязенә тагын 18000 татар күчеп килә[120].

1747 елдан 1765 елга кадәр Ырынбур губернасына 34890 кеше яңадан килеп урнаша: алар арасында 18000нән артыгы — татар, 10000е — чуаш, 4000е — мордва, 1000нән артыгы — мари, 240ы удмурт була. Күчеп килүче татарларның күбесе Казан һәм Зөя өязләреннән. 1747 елда губернада 28750 типтәр булса, XVIII гасыр ахырында алар саны 99292 кешегә җитә; ә типтәрләрнең яртысы татарлар була. Типтәр-татарлар күпләп Бәләбәй, Бөре, Бөгелмә, Минзәлә өязләренә урнашалар[121]. Христианлаштыру елларында татарлар «типтәр» сүзен «тип тәре» төшенчәсе белән бәйли башлый.

Христиан динен кабул итмәгәннәрнең күчеп китүе нәтиҗәсендә Идел буенда, бигрәк тә Казан губернасында, демографик ситуация кискен үзгәрә. Алтмышынчы елларда үткәрелгән

---

[117] Хабутдинов А.Ю. Татарское общественное движение в российском сообществе (конец XVIII — начало XX века): Дис. ...д-ра ист. наук.— Казань, 2002.— С. 36.

[118] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 3.— С. 92—93.

[119] ТР МА.— 3 ф., 2 тасв., 425 эш. бер., 431 б.

[120] Исхаков Д.М. Введение в историческую демографию волго-уральских татар.— Казань, 1993.— С. 29—30.

[121] Зобов Ю.С. Участие крестьян Среднего Поволжья в заселении Оренбургского края в XVIII веке // Сельское хозяйство и крестьянство Среднего Поволжья в период феодализма и капитализма.— Чебоксары, 1982.— С. 50.

халык санын алганда, 42185 кешенең кайда икәнлеген ачыклый алмыйлар; алар арасында иң күбе татарлар, чуашлар һәм чирмешләр була. Бушап калган урыннарга урыслар күчеп утырганлыктан, алар саны бу елларда күпкә арта[122].

Тарихчы С.Х.Алишев мәгълүматларына караганда, XVIII гасыр урталарында җитмеш Казан кешесе, көчләп чукындырудан котылу өчен, Төркиягә кадәр күчеп китәләр[123].

Күп еллар дәвамында керәшеннәрне күчереп утырту уңай нәтиҗәләр бирә дип әйтеп булыр иде. Православие дин әһелләре өчен иң кирәкле нәтиҗә — керәшеннәрнең бер өлеше христиан динендә ныгый, инана. Икенче яктан, бу кулланылган ысул керәшеннәрнең икенче бер өлеше өчен яңадан ислам диненә кире кайту мөмкинлеген ача.

1743 — 1754 елларда христианлаштыруга каршы көрәш

15 ел буе Идел-Урал якларында урыс булмаган халыкларны христианлаштыру шактый уңай нәтиҗә бирә. 1754 елда Казан губернасында чукынганнар саны 213756 булса, чукынмаганнар 117595 саналган; Нижгар губернасында аларның саны 37000 һәм 7600; Пенза провинциясендә — 18659 һәм 5095[124]. Христиан динен кабул итмәүчеләр арасында иң күбе татарлар. Мөселманнар өчен дә, мәҗүсиләр өчен дә православие динен кабул итү бик авыр була. Керәшеннәргә льготалар, христиан динен төрле халыклар арасында көч кулланып тарату үз диннәрен саклаучыларда зур ризасызлык тудыра. Тарихчы П.В.Знаменский фикеренчә, миссионерларның чукындырганда кискен чаралар куллануы татарлар һәм мордвалар арасында чуалыш уятты[125].

Беренчеләрдән булып көчләп чукындыруга каршы Нижгар губернасында яшәгән мордвалар каршы чыгалар. Нижгар өязендә Түреш вулысында яшәгән мордвалар: «Без христиан динен кабул итә алмыйбыз, үзебезнең элекке мордва динендә булырга телибез, безнең авылларда татар мәчетләре юк, без кырларда, урманнарда дога кылабыз. Әгәр дә безне, сезнең ятимнәрегезне, көчли башласалар, без, православие динен кабул итәргә теләмәгәннәр, качып урманнарда һәм башка урыннарга китәрбез»,— дип, өяз, провинция администрациясенә мөрәҗәгать итәләр. Тик мондый кисәтү булуга карамастан, мордваларны куркытып, көчләп христианлаштыру дәвам итә. 1743 елның 8 сентябрендә Пожарок авылы священнигы Клементьев тегермәндә

---

[122] Кабузан В.М. Народы России.— М., 1990.— С. 119—120, 242.
[123] Материалы по истории татарского народа.— Казань, 1995.— С. 218.
[124] Сенатский архив.— Т. 12.— С. 278.
[125] Знаменский П.В. История Русской церкви.— М., 2000.— С. 345.

он тарттырган татар һәм мордвалардан булган 8 кешенең кайберләрен көчләп чукындырган, калганнары, ашлыкларын ташлап, куркудан төрле якка качып киткәннәр.

Көчләп чукындыруга каршы Нижгар өязе Түреш вулысы мордвалары 1743 —1745 елларда Несмеянко Васильев-Кривой җитәкчелегендә фетнә күтәрәләр. Сәбәбе — Нижегород епархиясе җитәкчесе итеп билгеләнгән, Казан тирәсендә күпләп чукындыруны оештырган Димитрий Сеченовның һәм керәшен кантуры җитәкчесе Сильвестр Гловацкийның Сарлы авылында мәҗүси мордваларның изге каберлеген туздырулары һәм яндырулары. Епископ Димитрий Сеченов мордваларны көчләп чукындыра, күпләрне, агач яки тимер богау кидертеп, сакчылар астында зинданда тота, үтергәнче газаплап кыйный, кул-аякларын бәйләп су коендыра, тәре тага.

Епископ җитәкләгән миссионерлар командасы 1743 елда Нижгар губернасында мордвалар яшәгән Сарлы авылына килә. Иң башта алар мәҗүси мордваларның изге урыны булган зиратын туздырып ташлыйлар һәм яндыралар. Сәбәбе — зират урыс чиркәвенә артык якын урнашкан. Изге урыннарын тузгытуга һәм яндыруга ачуы чыккан мордвалар миссионерларны кыйный башлыйлар. Урыс миссионерлары башта чиркәүгә кереп качарга мәҗбүр булалар, ә Димитрий Сеченов куркудан бу авыл побының бәрәңге базына төшеп яшеренергә мәҗбүр була.

Бу бәла-казадан котылу белән әлеге авылга, Димитрий атакай үтенече буенча, премьер-майор Юнгер җитәкчелегендә гаскәриләр җибәрелә. Солдатлар командасын халык мылтык, уксөңге белән каршылый. Солдатлар җыелган халыкка мылтыктан ут ачалар: 35 кеше үтерелә, 31 яралана, 136 кеше кулга алына. Соңрак 130 кешене тикшерү өчен Нижгарга озаталар. Несмеянко Васильев-Кривой исемле мордва урысларга каршы христиан диненнән мәҗүсилеккә кире кайтканга, хачны муеныннан алганга, иконаны ваткан өчен котыртучы итеп танылa; һәм ул тере килеш утта яндырыла.

Түреш вулысында булган вакыйгалар 1744 елның 22 июнендә синод һәм сенатның берләштерелгән утырышында тикшерелә. Мордваларны алга таба христианлаштыруга каршылык күрсәтмәскә, мондый хәлләр яңадан булган очракларда бирегә гаскәриләр командасын җибәрү, җинаять кылучыларга каршы нинди эшләр кылынса, алар да шуның белән куркытыла. Шул ук вакытта Димитрий атакайга христианлаштырган вакытта көчләмәскә, изге атакайлар һәм указларда әйтелгән йомшак ысуллар кулланып чукындырырга диелә.

Шушы ук вакытларда, 1744 елда, Пенза өязе Вершеут авылында татарлар, ризасызлык белдереп, безне көчләп чукындырмакчы булсагыз, мондый хәлләр туктатылмаса, без каракалпаклар белән бергә Мәскәүгә кадәр барып җитәрбез, диган сүзләр әйтәләр. Аюк Хәсәнов Иделнең аръягындагы татарларга, кара-

калпакларга Мәскәүгә сугыш белән барырга чакырып хат язган дигән хәбәр тарала. Бу шомлы хәбәрне тикшерү уңай нәтиҗә бирмәсә дә, ул татарларның христианлаштыруга каршылыкларын тасвирлаган бер вакыйга булып тарихка кереп калган.

1748 елда Казан тирәсендәге мөселманнарның фетнәгә әзерләнүе турында яшерен рәвештә хатлар таратыла. Февраль башында Казан халкын пошаман калдырган хат шәһәр үзәгендә табыла. «Татарлар восстание күтәрергә хәзерләнәләр» диелгән була анда. Хатларда урысларның масленница бәйрәмендә, ягъни март башларында, Кама аръягында һәм Татар бистәсендә яшәгән мөселманнарның чукындыруга һәм түли алмаслык салымнарга каршы фетнәгә хәзерләнүе турында кисәтү язылган була.

Тиз арада Казанга һәм татар авылларына урнаштыру өчен Ырынбур губернасыннан Троицк һәм Ревель драгун полклары, Саранскидан өч драгун ротасы китерелә. Фетнә бастыруны оештыру өчен Казанга Греков яңа губернатор итеп билгеләнә. Саранскидан килгән 300 драгун Татар бистәсенә, Ревель полкы драгуннары, Казанны фетнәчеләрдән саклау өчен, Kаманың уң ягында, шәһәрдән алтмыш чакрым ераклыкта урнаштырыла. Хат язучыны табу максатыннан, шәһәрнең үзәк мәйданындагы фонарьга 500 тәңкә акча салып куялар.

Татар авылларындагы хәлләрне белү өчен тиз арада тикшерү оештырыла, яшерен рәвештә кешеләр авылларга җибәрелә. Тикшерү вакытында Кама аръягындагы Җөри һәм Ногай юлларында урнашкан 18 татар авылының фетнәгә хәзерләнүе ачыклана. Фетнә хәзерләүне әйдәп йөрүчеләр Актау авылыннан Рахманкул Арсланов, Зирекле авылыннан Исмәгыйль Любаев, Ибрай авылыннан Якуп Мостаев була. Фетнәчеләр түбәндәге таләпләрне куялар:

— чукынганнар өчен өстәмә салым түләмәскә;
— чукынганнар өчен өстәмә рекрутлар бирмәскә;
— чукынганнар өчен өстәмә атлар бирмәскә;
— лашманчылар хезмәтеннән азат итәргә.

Фетнәдә катнашырга хәзерләнгән 18 авыл арасында Актау, Зирекле, Ибрай, Юныс, Дабрамыш авыллары күрсәтелә. Губернага тиз арада гаскәриләр кертелгәнгә күрә, фетнә башланып китми кала. Авылларда тынычлык саклана. Шуңа күрә апрель башында кайбер полкларны элекке урыннарына күчерү турында карар кабул ителә. Тик бу карар алданрак кабул ителгән булып чыга, чөнки 8 апрельдә Көнгер татарлары һәм Агыйдел буендагы чуашларның да фетнә хәзерләве турында хәбәр алына.

Җентекләп тикшергәннән соң, тагын яңа фактлар ачыклана: Санкт-Петербургка шикаять белән барган Күлмән Иштеряков (Көнгер өязе Ирәнбаш вулысы Кече Тәләс авылыннан), шул якта-

гы Яңабирде авылы кешесе Камыз Ангилдин белән сөйләшкәндә, фетнәгә хәзерләнү турында сүзләр әйтә. Йанапай авылында үткәрелгән җыенда мылтыклар хәзерләп Көңгер крәстияннарын таларга барырга кирәк, дигән фикерләр әйтелә. Күлмән Иштиряков Санкт-Петербургта Ибрай авылы кешесе Якуп Мостаев белән фетнә күтәрү турында килешеп кайткан булалар.

1748 елның 26 июлендә Казан үзәгенә яңадан хат ташлап китәләр. Хат полицмейстер Маматов һәм бригадир Бардукевичка адресланган була. Хатта, татарлар Казанда янгын хәзерлиләр, элек ташлап кителгән хатны язучы керәшен татарының башын татарлар кистеләр инде, диелә. Бу хат буенча да тикшерүләр үткәрелә, тик алар кисәтүләрнең ялганлыгын гына ачыкларга мөмкинлек бирәләр. Шулай да татар авылларын яшертен күзәтү кискенләшә[126].

Казан һәм Көңгер татарлары тарафыннан хәзерләнгән фетнә тиз арада каралган чаралар аркасында башланмыйча кала. Бу хәл мөселман татарларның чукындыру сәясәтенә каршы чыгарга хәзерлеген күрсәтә торган мисал булып тора. Чынлап та, 1750 елда Саранск өязе Щербаково авылында яшәгән татарлар керәшеннәр өчен түләгән салымнарның чамадан тыш артык булуына зарланалар. Алар, әгәр дә Саранскидан салым җыярга килсәләр, татарлар Саранскига җыелып фетнә күтәрәчәкләр, без — урысларны яисә алар безне чапкалап бетерәчәкләр, дип кисәтәләр. Бу факт буенча тикшерү үткәргәндә, татарлардан Ахтирәк Алешкин, Инекәй Тахтаров, Килмәмәт Янгаев фетнә хәзерләүне ялган дип атыйлар[127].

Шулай итеп, Русиянең татарлар яшәгән төрле өязләрендә халык күпләп христианлаштыру сәясәтенә каршы күп мәртәбә үз ризасызлыгын белдерә. Алар арасында иң активлардан мордваларны һәм Казан татарларын күрсәтеп булыр иде. Тик христианлаштыруга каршы алып барылган бу ризасызлык дәүләтнең дини сәясәтен үзгәртми, миссионерларның мөселманнар һәм мәҗүсиләр арасында православие динен тарату өчен алып барылган эшен дә туктатмый.

[126] Сенатский архив.— Т. 7.— С. 257—258, 297—299, 316—317 и др.
[127] Шунда ук. 24—25 б.

Мулла Батырша восстаниесе: максатлары һәм нәтиҗәләре

Батыршаның тәрҗемәи хәле

Динне, халкыбызны саклап калу өчен барган фидаи көрәштә иң мөһим рольне Батырша восстаниесе алып тора. Халык ихтирам иткән мулланың патша властена, миссионерларга каршы көрәшкә өндәүче булып чыгуы һич кенә дә очраклы хәл була алмый. Күренекле дин әһеле һәм акыл иясе, татар халкының милли-азатлык хәрәкәтенең бөек шәхесе Батырша мулла җитәкчелегендә татар һәм башкорт халыклары күтәргән восстание, анда катнашучыларның үзләрен аямыйча көрәше генә көчләп чукындыру сәясәтен үзгәртергә мәҗбүр итә һәм ислам динен чикләнмәгән Русия империясе җирләрендә саклап калырга мөмкинлек бирә. Бу восстаниенең дини икәнлеге хакында урыс тарихчысы С.М.Соловьев XIX гасыр уртасында ук «мөселманнар православие динендә булган правительствога буйсынырга теләмиләр. Восстаниене мөселман руханиларыннан Батырша хәзерли» дип әйтсә дә, бу хакта бәхәсләр дәвам иткәнен язган идек инде.

Батыршаның исемен төрле галимнәр төрлечә атыйлар: Габдулла Алиев, Батырша Алиев, Батыршаһ, Абдулла Мязгалдин, Габидулла[128]. Танылган галим Гайса Хөсәенов фикеренчә, Батыршаның чын исеме Баһадиршаһ Миңлегали улы (Галиев), ә халык арасында аның исемен кыскартып Батырша дип атаганнар; Гобәйдулла Мәзгытдин — аның ләкабе. Мондый фикер белән тулысынча килешеп булмый. Безгә Ризаэтдин Фәхретдин фикере якынрак. Безнеңчә, Батыршаның чын исеме Габидулла Туктаргали улы (Галиев)[129]. Батыршаның чын исеме Габидулла булуга карамастан, халык арасында Батырша дип аталуы махсус

[128] Батырша— выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир 1755 —1756 гг.— Уфа, 2000.— С. 132 —133; Баттал Г. Курс. хезм.— 73 б.; Вәлиди Ә. Башкорттарның тарихы // Агыйдел.— 1993.— № 7.— 164 б. һ.б.

[129] Письмо Батырши...— 118 б.; Хосейенов Г. Батыршаның патшага язган хаты // Батырша — выдающийся идеолог и вдохновитель восстания башкир 1755 —1756 гг.— Уфа, 2000.— С. 28; Фәхретдин Р. Мулла Габидулла Батырша // Шунда ук.— 132 —134 б.

тикшерүне таләп итә. Иншалла, андый галим табылыр, исемнәр алмашу могҗизасын аңлатыр.

Хәзерге көнгә кадәр Батыршаның туган елы һәм туган урыны да билгесез. Кайбер галимнәрнең фикеренчә, Батырша 1715 елда 35 йортлы Карыш авылында йомышлы татар (мишәр) Туктаргали Дусалиев гаиләсендә туа[130]. Карыш авылына 1693 елда йомышлы татарлар нигез сала. Бирегә күчеп килүчеләр арасында Сөләйман Дусалиев та була. 1702 елда бирегә 23 гаиләдән торган бер төркем күчеп килә, алар арасында абыз (мулла) Туктаргали Дусалиевны — Батыршаның әтисен дә очратабыз. Кызганыч, хәзергә кадәр Туктаргали абызның кайсы авылдан килүе ачыкланмаган, гәрчә бирегә килүчеләрнең Нижгар якларыннан, Алатор, Курмыш, Арзамас өязләреннән икәнлеге билгеле булса да[131].

П.И.Рычков китабында китерелгән мәгълүматларга таянып, А.П.Чулошников, С.М.Васильевлар Батыршаның туган елын 1710—1715 еллар дип күрсәтәләр. Күренекле мулланың туган елы итеп М.И.Әхмәтҗанов 1711 елны атый[132]. Батыршаның туган елы итеп «Татар энциклопедиясе»ндә 1710—1715 еллар күрсәтелсә, «Башкорт энциклопедиясе»ндә 1709 яисә 1717 еллар атала[133]. Батыршаның туган елын төгәл билгели алмауның сәбәбе шунда. Архивта сакланган материалларда Батыршаның төгәл туган елы турында мәгълүмат хәзергә табылмады. Батырша сорау алганда үзенең яшен ни сәбәптәндер күрсәтми. 1756 елның октябрендә, Мәскәүдә сорау алу вакытында: «Тумышымнан утыз яшьтән күбрәк, төгәле күпме икәнен әйтә алмыйм»,— дигән. Безнеңчә, Батыршаның туган елы 1710 ел, дип әйтсәк, дөрес сыман, чөнки Батыршаны күргән, сорау алганда катнашкан П.Рычков аны кулга алган вакытта 46 яшь иде, дип теркәгән (1756 — 46 = 1710). Карыш авылы ул вакытта Уфа өязе Себер юлында исәпләнгән; хәзер Югары Карыш авылы Башкортстан Республикасының Балтач районына керә.

Батырша заманасы өчен дини яктан төпле белем ала: баш-

---

130 Алишев С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу.— Казань, 1999.— С. 42; Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана / Справочник.— Уфа, 1993.— Кн. 3.— С. 208.

131 Батырша — выдающийся идеолог и вдохновитель...— С. 21.

132 Рычков П.И. Топография Оренбургской губернии.— Оренбург, 1887.— С. 259; Чулошников А.П. Восстание 1755 г. в Башкирии.— М.; Л., 1940.— С. 64; Васильев С.М. Роль Батырши в восстании 1755 г. в Башкирии // Страницы истории Башкирии.— Уфа, 1974.— С. 26; Ахметзянов М.И. Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы: Автореф. дис. ... д-ра филол. наук.— Казань, 1998.— С. 53.

133 Татарская энциклопедия: В 5 т.— Казань, 2002.— Т. 1: А—В.— С. 315; Башкортостан: Краткая энциклопедия.— Уфа, 1996.— С. 147.

та ул үз этисе абыз Туктаргали сабакларын алса, аннары Тайсуган авылында Габдеррахман мулла мәдрәсәсендә (хәзерге Әлмәт районы) укый, тәрбия ала. Габдеррахман тәкъдиме буенча ул Казан өязе Алат юлы Ташкичү авылы (хәзерге Арча районы) мәшһүр мулласы, булачак Ырынбур ахуны Габдессәлам Уразмөхәммәд (кайбер язмаларда Урай дип кенә бирелә) җитәкчелегендә дини һәм дөньяви белемен камилләштерә. Ул Казан якларында шәкерт булып ун ел чамасы дәрес ала (1734 — 1744).

А.П.Чулошников фикеренчә, Габдеррахман мулла киң гыйльми белеме, заманасы өчен мөселманча дини белем бирүчеләрдән үзенең өстенлеге белән аерылып торган. Тайсуган авылы мәдрәсәсендә ул күп еллар гарәп әдәбияты, ислам тәгълиматлары буенча дәресләр алып бара. Мәдрәсәдә аннан башка сәләтле укучыларыннан хәлфәләр, мөдәррисләр дәрес биргәннәр. Балаларына калдырган васыяте һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә багышлаган мактау шигыре үгет-нәсихәтендә Габдеррахман мулла кулланган борынгы татар теленең байлыгын һәм матурлыгын күрсәтә. Ул тормышта белемгә зур урын бирә, балаларын, туганнарын һәм үзенә якын дусларын фән белән шөгыльләнергә чакыра, наданнар, белемсезләр белән якынаймаска өйрәтә. Ислам тәгълиматын өйрәнүдә зур уңышларга ирешкән Габдеррахман үз ягында гына түгел, Ырынбур, Казан якларында бик популяр шәхес була[134].

Киләчәктә гыйсъянчы мулланың азатлыкка омтылышы формалашуда бигрәк тә Габдессәлам мулланың тәэсире зур була. Ул Ташкичүгә күрше Мәңгәр авылында 1700 елда туа, дини белемен Төркестанда ала. 1746 елга кадәр Ташкичү авылында имам һәм мөдәррис булып шәкертләр тәрбияли. Шул елны Ырынбур янындагы Каргалы (Сәгыйть) бистәсенә ахун итеп билгеләнә, анда да мәдрәсә оештыра, төрле төбәкләрдән килгән шәкертләрне укыта һәм тәрбияли.

Казан артында яшәгәндә үк Габдессәлам имам, каләм тибрәтеп, төрле эчтәлектәге шигырьләр иҗат итә. Аның иҗатында төп урынны мәхәббәт, иҗтимагый һәм дини мәсьәләләр алып тора. Көчләп чукындыруга түзә алмаган мөселманнарның башка якларга күчеп китүе Габдессәлам иҗатында түбәндәге юлларда чагылыш тапкан:

Без икәүмез ушбу йирдә тормайалыйк,
Дуст-дошман арасында булмайалыйк...
Кадыйр Алла, безгә юл бир, китәлүм,—

ди ул.

Габдессәлам иҗатында хөррият, милли азатлыкка чакыру мотивлары да турыдан-туры күрсәтелгән:

---

[134] Чулошников А.П. Курс. хезм.— 64 б.

Карчыга карап очар — тауны күрсә,
Ир-егет кылыч алыр — яуны күрсә![135]

Шунысы игътибарга лаеклы: Батыршаның күркәм укытучылары — Тайсугандагы Габдеррахман мулла да, Ташкичүдәге Габдессәлам имам да — сүз осталары булганнар, фикерләрен шигъри юлларга салып, шәкертләрендә, ислам дине нечкәлекләре белән беррәттән, Русия патшаларының мөселман һәм башка халыкларга каршы алып барган вазгыятен дөрес аңлатып, хөррият, азатлык хисләрен дә тәрбияләгәннәр.

А.П.Чулошников белән килешеп, без дә Батырша ике мәдрәсәдә 10 ел (1734 —1744) тирәсе укыган дигән фикердә калабыз. Кайсы мәдрәсәдә кайсы еллар укыганлыгын хәзергә билгеләп булмады. Бу хакта старшина Яныш Абдуллин да Батыршаның чит якларда 10 ел укыганлыгын искәртеп кенә китә.

Батыршаның мәдрәсәләрдә белем алган еллары мөселманнарны көчләп чукындыру тәмам азган чорга туры килә. Ул, миссионерларның эшен үз күзе белән күреп, халыкның моңзарын ишетеп бергә кичерә. Бәлки, Батыршаның укуын туктатуының сәбәбе —1742 —1743 еллардагы мәчетләр җимерелү, мәдрәсәләр ябылу булгандыр. Ташкичү авылындагы мәчет тә шул вакытта җимерелә. Ул вакытта Ташкичү 40 йорттан торган, авылда керәшеннәр булмаган. Авыл халкы мәчетнең төзелү вакытын атый алмаганнар. Христиан дине, хакимият даирәләренә таянып, ислам диненә каршы төрле яктан һөҗүм алып барган чакта, Батыршаның дини һәм фәлсәфи карашлары, гыйсъянчы рухы формалаша.

Ташкичү мәдрәсәсендә дини белемнәрен камилләштергәннән соң, Батырша Уфа өязе Уса юлындагы Гәйнә вулысы Күземъяр-Байавыл авылында (хәзерге Пермь өлкәсе Барда районы) һәм Исәт провинциясендә Мөслим Аширов старшинаның йомышлы татарлар авылында (хәзерге Чиләбе өлкәсе Мөслим авылы) балаларга сабак укыта, мулла хезмәтләрен башкара.

Уфа өязе, Себер юлында, соңыннанрак Исәт провинциясенә кергән Олыкош авылында яшәүче (урысча Улукуш) старшина Мөслим Аширов, үзе абыз булуга карамастан, Батыршаны үз авылына муллалыкка чакыра. Күрәсең, имам, старшина вазифаларын бергә үтәп булмаган. Ул 1735 —1740 елларда, Башкортстанда азатлык өчен кискен көрәш елларында билгеле була. Урыс телен яхшы белгән старшина фетнә күтәргән башкортлар һәм урыслар белән арадашчы ролен үти. 1736 елның июль аенда фетнәчеләр җитәкчеләре Йосыф Арыков, Җиам бай һәм

---

[135] Татар әдәбияты тарихы.— Казан, 1984.— 1 т.— 404—411 б.; Әхмәтҗанов М. Габдессәлам // Казан утлары.— 1995.— № 6.— 157—169 б.

Төлкечура Алдагуловның В.Н.Татищевка хатларын урысчага тәрҗемә итә. 1736 —1738 елларда В.Н.Татищев исеменнән фетнәчеләр белән очраша, аларны фетнәне туктатып, баш иярга күндерә. Старшинаның урыс администрациясе кушуы буенча эшләгән эшләре барлык фетнәчеләргә дә ошамаган шикелле. 1737 елның 21 июнендә башкортлар Олыкош авылына һөҗүм оештыралар, авыл халкын талыйлар. Барча мал-туар, йорт кирәк-ярагы талана. Кызганыч, чыганакта күпме кеше үтерелгән, күпмесе әсир итеп алынган икәнлеге турында мәгълүмат бирелмәгән. Бу хәлләрдән соң авылны фетнәчеләрдән саклау өчен, Мөслим Аширов дары һәм кургаш сорый. Йомышлы татарларны фетнәчеләрдән саклау өчен, аларга төзелә торган крепостьлар тирәсенә күчеп авыллар төзү турында карар кабул ителә[136].

Биш ел чит җирләрдә йөргәннән соң, Батырша туган авылы Карышка кайта һәм ул анда мулла итеп сайлана, мәдрәсә ачып, шәкертләр укыта. Биредә ул восстание башланганчы 6 ел яши. Тиздән 15 шәкерт белем алган Батырша мулла мәдрәсәсе тирә-якта шактый абруй казана, һәм бирегә дини белем алу өчен якын авыллардан гына түгел, ерак Казан, Көңгер өязләреннән, Исәт провинциясеннән татарлар һәм башкортлар килә башлый.

Аның абруе артканнан-арта бара һәм ул 1754 елда Уфа өязе Себер юлының ахуны итеп тәкъдим ителә, тик Яныш старшина каршы килгәнлектән, ахун итеп билгеләнми кала. Тагын шуны күрсәтеп китү зарур дип уйлыйбыз: Батырша турында язылган әдәбиятта Батырша ахун итеп сайлана яисә ахунлыктан үзе баш тарта дигән фикер йөри, ләкин ул дөрес түгел, архив материаллары Яныш старшинаның, Батыршага каршы чыгып, икенче кешене тәкъдим итүен исбатлыйлар[137]. Дөресен әйтергә кирәк, 1974 елда ук тарихчы С.М.Васильев Батыршаның ахун булып сайланмауда Яныш Абдуллин старшинаның каршы килү нәтиҗәсе икәнлеге турында язса да, бу фикергә башкалар игътибар итмәде, әллә хупламадылар һәм ялгыштылар. Батырша бу сюжетны хатында түбәндәге сүзләр белән биргән: «...галимнәр вә гәуамлар, барча халайыклар Себер юлы халкы өстенә Ибраһим ахунд урнына ахундлыкка куймакга теләделәр. Вәләкин ыстаршина Яныш үзенең әмеренчә булмамакым өчен бәнетилә-

---

[136] Материалы по истории Башкортостана. Оренбургская экспедиция и башкирские восстания 30-х годов XVIII в.— Уфа, 2002.— Т. 4.— С. 384—385, 442—443.

[137] Вәлиди Ә. Күрс. хезм.— 165 б.; Фатыйхов Ә. Гәйнә тарихыннан.— Барда, 1995.— 68 б.; Акманов И.Г. Батырша // Башкортостан: Краткая энциклопедия.— Уфа, 1991.— С. 147; Асфандияров А.З. Күрс. хезм.— 145 б.; Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 68 б.; Мостафина Р. Күрс. хезм.— 75 б.; РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 2, л. 144.

мәйүб, аның үзенең әмеренчә булгудай бер мелланы ихтияр идүб язуы язды. Гәлимләрдән вә гәйреләрдән кулларуны куйдурыб, тамгаларны салдыруб, ул мелланы Оренбурдакы ике ахундлар хозурына ебәрде, динемездә ахундлык ни кагидәчә бирүлә торгандур, шул кагидәчә ахундлык мәртәбәсе бирелер өчүн. Вәләкин ахундлар ул мелланың гилемлек хәлен тәфтишләб, аны ахундлык мәртәбәсенә ләякатсыз күреб, буш кайтарганлар»[138].

Габделбари Баттал Батырша муллага мондый характеристика бирә: «Акыллы бер кеше буларак, яхшы белем һәм тәрбия алган мулла һәм русларның сыеша алмаслык дошманы була. Фетнә башлаудан күп элек ул башкорт өлкәсен аркылыга-буйга йөреп чыга, яшьләрне укыта-өйрәтә, үгет-нәсихәт бирә, халык арасындагы сүзләргә, зарларга колак сала, үзе сөйләүдән бигрәк башкаларны тыңлый. Ул матур һәм тәэсирле итеп сөйләргә дә оста була. Батырша Казан төркиләре (татарлары) белән дә, казакъ-кыргызлар белән дә бәйләнешкә керә. Аның вәкилләре Казан өлкәсендәге мөселман авылларында да, казакъ-кыргыз далаларында да йөриләр»[139].

Мөселман татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә тормышны күргән Батырша һәр җирдә дә миссионерларның христиан динен урыс булмаган халыкларга көчләп тагу сәясәтен күрә һәм ул сәясәтне туктату турында нык уйлана. Русия хөкүмәте һәм миссионерлары үз максатларына ирешер өчен һәрбер мөселман кешесен урыс диненә көчләп күчерәчәге аңар көн кебек ачык була. Татар халкы дөньяви карашының, халәтенең нигезе булган ислам диненнән читкә тайпылу урыслаштыру процессларын тизләтүдә, милләтнең милли йөзен югалтуда иң мөһим этәргеч булганын Батырша яхшы аңлый.

Батырша — восстаниенең идеологы һәм оештыручысы

Мөселманнарны икътисади бөлгенлектән, рухи, дини изүдән бердәнбер коткару юлы — баскыннарга каршы азатлык өчен корал тотып көрәшү. XVIII гасыр уртасында халыкның дини, рухи изүгә каршы ачуы иң югары ноктасына җитә. Татар, башкорт арасындагы ризасызлыкны 1754 елны хакимият тарафыннан тозны сатып алу турындагы фәрман да куерта. Тозны сатып алуны кертү белән бергә хөкүмәт татарларны һәм башкортларны ясак түләүдән дә азат итә. Шунысы игътибарга лаек: җирле халык ясактан азат ителүне сөенеп каршы алмый, киресенчә, халык арасында тиздән җирне дә тартып алалар икән дигән хәбәрләр тарала.

---

[138] Письмо Батырши...— С. 45.
[139] Баттал Г. Күрс. хезм.— 73 б.

1755 елның март айларында Ногай юлы Кәлчир-Табын вулысыннан Исмәгыйль исемле башкорт Батыршага хат тапшыра. Бу хат башкортларның май аеның ахырында восстание күтәрергә әзерлеге турында хәбәр итә. (Башкорт халкының бу мөрәҗәгате Батыршаның восстание хәзерләгәндә җитәкчелек ролен күрсәтүче бер дәлил булып тора.) Әлеге хәбәрнең Батыршага «Тәхризнамә» — «Өндәмә» язарга этәргеч булуына бездә шик юк. Халыкның оешмаган, стихияле хәрәкәтенә оешканлык бирү өчен Батырша 9 биттән торган «Өндәмә» яза. Бу «Өндәмә»не И.Г.Акманов фәнни хезмәткә тиңли, анда Русиядә яшәүче башкортларның һәм башка мөселман халыкларының хәлэтен тирән анализлауга, восстание ярдәмендә генә патша Русиясенең хакимлеген бәреп төшерү һәм бәйсез дәүләт төзү турында нигезләмә булганлыгына игътибар итә[140].

Батырша мулла 1755 елның март-май айларында шушы «Өндәмә» өстендә эшли, иҗат итә, мөселманнарны көрәшкә чакыра. Колониаль изүгә, миссионерларга каршы юнәлтелгән восстание 1755 елның 3 июленә билгеләнә. Бу «Өндәмә»не шәкертләр һәм аның тарафдарлары мөселманнар яшәгән авылларда тараталар. «Өндәмә»нең фетнә хәзерләүдә роле бик зурлыгын тагын искәртәбез.

Колониаль һәм дини изүгә каршы көрәшнең программасын тәшкил иткән «Өндәмә» мөселманнарның изге китабы Коръән Кәрим аятьләрен һәм хәдисләрен тәфсир итү рәвешендә Габидулла Мәзгытдин исеменнән татар телендә урыс илендә яшәгән мөселманнарга мөрәҗәгать итә. XVIII гасыр уртасындагы мөселман халыкларының хәләтен күрсәтүче бу мөһим документның төп фикерен, фетнәчеләрнең кайбер таләпләрен күрсәтеп китик.

Олы ислам дине белгеченә, кешеләрне ислам тәгълиматы нигезендә яшәргә өйрәтүче Батыршага баскыннарга каршы көрәшне ислам байрагы астында бөтен мөселманнарны туплый алганда гына уңышлы булачагы ачык күренә. Ул иң беренче мөселманнарга авыр социаль-икътисади һәм дини изүнең сәбәбен аңлата. Төп сәбәп — «кяфер һәм залим урыслар»га буйсынып, мөселманнарның ата-бабаларыбыз һәм туган диндәшләребез борынгыдан кабул иткән ислам кагыйдәләреннән һәм Нәби Рәсүл әйткәннәреннән читкә китеп, бозык, ялган, яман хәлләргә төшү. Батырша, ул замандагы традиция буенча, халыкларны икегә бүлеп күрсәтә: уңай, алдынгылар — «пакь динле ислами халайыклары» һәм яман, дошман халыклары — «кяфер һәм залим урыс». Икегә бүлүнең нигезендә дин ятканы яхшы күренә.

---

[140] Батырша— выдающийся идеолог и вдохновитель...— С. 16.

Мөселман халыкларының алга киткән заманасы итеп Батырша Болгар дәүләте чәчәк аткан чорны күрсәтә. Болгарда, аның фикеренчә, «мөселманнар бер күңелдә», «киңәш һәм бергә булганнар». Урыс мөселманнар белән килешенгән антларын бозган чакта, мөселманнарга төрле фетнә һәм җәфа кылган вакытта, мөселманнар яу кораллары белән коралланып, җиңелмәс газилек атларына атланып, ул кабахәт кяферләр өстенә ташланалар, күп кяферләрне кылыч һәм сөңгеләрдән үткәреп, җаннарын җәһәннәмгә җибәрәләр иде. Бердәмлек булмаган кавемдә «хәерлек һәм бәрәкәт, тынычлык һәм иркенлек» булмый.

Батырша болгарларның икенче өстенлеге итеп ислам динен урыс, чирмеш, таулы (чуаш) халыклары арасында ирекле таратуны күрсәтә. Исламны халыклар арасында тарату ысулын ул тагын да урыс миссионерлары ысулына капма-каршы куя. Мөселманнар диннәрен башкалар арасында ирекле рәвештә таратсалар, урыслар үз диннәрен көчләп тагалар. Ислам дине ул халыклар арасында хәзергә кадәр саклануы сер түгел. Кяферләргә каршы мөселманнарның керәшен, динсезләр арасында ислам динен таратуны Батырша «Алланың рәхмәте, хәер-дога, изге хатирә» дип атый.

Мөселманнарның хәләте Ырынбур кальгасы төзелгәч тагын да авырая, алар арасында «фетнәләр вә каседләр пәйда булды». Сәбәбе — мөселманнарның бер өлеше икенче өлешен «чапкылап үтереп, малларын алып, угыл-кызларны кол һәм әсир кылып, кяфер сатдылар вә һәм бәхшиш кылдылар». Мөселманнар, урыс белән килешеп, кяфер гаскәрләренә ярдәм итештеләр, мөселманнарны хурлыкка төшерделәр, һәлакәткә илттеләр, башкортларның ул-кызларын колыбыз һәм җарияләребез дип эшләтеп, кызларны, никяхсыз-нисез көчләп, түшәкләргә яткырдылар. Үзләрен мөселман санаган кяферләр һәм мөртәтләр, чөнки алар «хәрәмдә хәлял санадылар».

Икейөзле старшиналар кяферләрнең салымнарын һәм җәфаларын кабул итеп, мөселманнар өстенә йөкләделәр. Батырша старшиналарның бигрәк тә мөселманнарга 80ешәр, 25әр тиен салым салган вакытын атый. Ул чакта старшиналар кяферләрнең яңа салым салганнарына каршы чыкканнарны «урыска тотып биреп, уларны хур иттеләр һәм һәлак кылдылар».

Кыскача әйткәндә, «Өндәмә»нең максаты шул: «Әй мөселманнар! Гөнаһлылар өчен тәүбә кылыгыз һәм Алладан ярлыкау сорагыз, яман эшләрдән ваз кичегез: кяфер урыс белән бер күңелдән булып, мөселманнарның каннарын түгүдән, малларын тартып алып, үзләрен фәкыйрь һәм әсир итүдән, урыс хезмәтеннән баш тартырга, урысның кальгаларын ныгытмаска, олаулар кумаска, ясак һәм фураж салымнарын түләмәскә, кальга һәм крепостьлар, заводлар төзүгә ирек бирмәскә, ислам җәмәгатьләренә чиксез һәм хисапсыз җәфалар ирештермәскә, ислам ди-

ненә зарар һәм зәгыйфьлек китермәскә. Тәүбә вә истигъфар итеңезләр!

Пакь динле мөселманнар, берләшегез, берләшегез, берләшегез!

Батыр газилек атларыгызны һәм коралларыгызны хәзерләгез! Ук, кылыч, сөңге һәм ни кирәклеләр хәлегез кадәренчә әзерләнегез!»

Ахырда Батырша мулла, пәйгамбәребез Мөхәммәд саллалаһу галәйһиссәламне яклаучы итеп, кяфер урысны чабарга чакыра. «Аларны җиребездән куып чыгарыйк! Ил-йортыбызда мәчетләр һәм мәдрәсәләр бина кылыйк! Һәм динебезне, ислам динен куәтләндермәккә һиммәт итик!»

Батыршаның азатлык яулау идеясе исламны куәтләндерү, ислам динен көчләүдән, чикләүдән арындыру. Бу рухи иреклеккә омтылуның француз мәгърифәтчеләренең идеяләре белән аваздаш булуы бик кызык. «Казан, Сембер, Зөя өязендәге биш мең кеше яки артыграгы, кяфер урысның җәбер кысуыннан такатьсез булып, ул кяфер урыс динен кабул иттеләр. Ә уларның бәгъзеләре, йөрәкләрендә иман һәм тынычлык тотканнары, мөселманнар кайчан күтәрелерләр икән дип зарыгып көтеп торалар. Ислам хакында башны һәм җанны фида кылырга идек, дип зар булып торучы мескеннәрнең иреге өчен дә тырышыйк!»

Ислам динен саклап калу өчен башлаган изге көрәшне Батырша халыкның милли-мәдәни үзенчәлеген саклау өчен көрәш белән тиңли. Ул хөкүмәтнең дини кысрыклавына каршы гына баш күтәрми. Көчләп чукындыру урыс булмаганнарның тормыш шартлары начарлатуын, аларның бөлгенлеккә төшүен дә яхшы аңлый ул. Чукынганнар өчен чукынырга теләмәгәннәргә өстәмә салым түләү, хакимият билгеләгән мәҗбүри төрле эшләрдә катнашу мөселманнарның икътисади хәләтен бик нык начарлата. Мондый сәясәт хәлле, бай татарларның да эшләрен мөшкелли: бурычларын үтәү хисабына эшләгән хезмәтчеләр чукынган очракта бурычларыннан азат ителә. Чукынмаганнар чукынганнардан аерым яшәргә тиеш булганлыктан, яңа җирләргә күчереп утырту да бөлгенлеккә алып барган. Көчләп чукындыру турында сөйләгәндә, Батырша мулла: «Ул кяфер урысның максаты шул: әгәр үз хәле җитәр булса, бераз гына заман эчендә үк урыс илендә торучы мөселманнарның өстенә такать тотмастай авыр салымнар салып, аларны бөлдереп, үзенең бозык диненә көчләп кертер иде. Бәлки, бер көн эчендә үк. Ләкин ул кяфернең хәле җитмидер берьюлы тиз арада алай кылырга»,— дип азсызыклый.

Батыршаның программасы буенча бөтен мөселман халкы чамадан тыш салымнардан, мәҗбүри итеп тагылган хөкүмәт эшләреннән, Ырынбур шәһәрен һәм ныгытмасын, чик буендагы кальгалар төзүдән, шулай ук башка казна корылмалары салудан

азат ителергә, чиктәге хәрби хезмәт бетерелергә, төбәктә заводлар һәм кальгалар төзелү тыелырга, җирне тартып алу рөхсәт ителмәскә, җирле чыганаклардан тозны башкортларның бушка алу хокукы кире кайтарылырга, керәшеннәргә ислам диненә кире күчәргә рөхсәт бирелергә, чукынмаганнарга салынган өстәмә салымнар һәм өстәмә эшләр бетерелергә, шәригать эшләре, старшиналардан алынып, руханилар кулына тапшырылырга тиеш була. Билгеле, урысларның колониаль хакимияте саклангандa, бу таләпләрне тормышка ашыру мөмкин булмый һәм, уйлабрак караганда, алар мөселманнарның Русия империясеннән бәйсез яшәүләре кирәклеген аңлата иделәр.

Батырша мулла, ислам берлегеннән тыш, төрек бердәмлеге әсасларын, соңрак «пантюркизм» дип аталган, урысларны куркуга төшергән төшенчәгә дә нигез сала. Ихтимал, ул мөселманнарның теләктәшлеген төрек бердәмлегеннән башка күз алдына да китермәгәндер. Башкорт җирләрен колония хәленә төшергәннән соң, чиратта кыргыз-казакълар, ә аннан соң «ислами калалардан Ташкент белән Бохара», андагы мөселманнарны «мәзлум итеп баш идермәгә һәм таркатырга», «үзләренең бозык диненә иңдермәк телиләр». Урыслар Казанны буйсындырганда ни рәвештә эш кылсалар, һаман кылалар. Урыс сәясәтенә каршы Батырша мөселманнарга Уфа өязенең дүрт юл халкы, кыргыз-казакъ, башка ислам тарафындагы калалар белән берләшеп, ислам кылычын күтәрергә, урыс йорт-илен көч белән туктата алмагач, «хәйлә һәм алдау» белән җиңәргә өнди[141].

Батырша «кяфер урысның» алдавына, ә «зирәк һәм үткер акыллы кешеләр»нең алданмавына игътибар итә. Ул бигрәк тә «кыргыз-казакъ белән мөселманнарны арабызга фетнә һәм җәфа таратмага» каршы торырга чакыра. Күрәзәче шикелле, алга таба урыслар башкортларны, татарларны казакъ ыруы белән сугыштырып, халыклар арасында низаг чыгару мөмкинлеген кисәтә. Каннарыбызны түгештереп, киләчәктә ул ырулар белән безнең арабыздагы тынычлыкны һәм татулыкны бетерә, ди.

Гыйсъянчы мулла халыкның хакимияткә каршы көрәшү хокукларын да хаклы нигезли: «Әгәр дә бер падишаһка ант иткәнбез икән,— дип яза ул,— һәм дә без падишаһ сүзенә нык торып, аны бозмаска, без, шәригать кануннарыбызга һәм изге китабыбызга күрә, гомеребезне фида итәргә, башыбызны салырга тиешбез. Әгәр дә падишаһ халкын җәбердән саклау вазифаларын үтәми, салымнар даими үзгәреп, яңалары өстәлеп тора икән, мөселманнар, хәлгә кереп, диндәшләренә ярдәм итәргә һәм динебезне шәригать кушканча бөекләтергә тиешләр. Һәм бу Коръән Кәрим белән шәригать нигезендә изге санала».

«Җитәр, әй мөселманнар, егетләр һәм олылар, атлылар һәм

[141] Батырша— выдающийся идеолог и вдохновитель...— С. 128.

җәяүлеләр, коралланыгыз! Күтәрелеп чыгыгыз! Изге сугыш башлагыз! Җан-тәнегез белән Аллаһ боерганын эшләгез!»

Батырша мулла гайрәтләнеп: «Сәлам сезгә, ислам әһелләре! Белегез һәм аң торыгыз: без, Габидулла Мәзгытдин, дүрт юл халкы мөселманнарының хәлләрен һәм серләрен, югарыда әйтелгәнчә, тикшереп һәм аңлап, шул мөселманнардан беркадәр кыйммәт иясе галимнәре һәм тигез халыклары белән киңәшеп, берләшеп, вәгъдә куештык: шушы елда, 1755 тә, гает-фитырдан соң шәүвәл айның дүртенче көнендә[142], Аллаһы әмеренең Аллаһы юлында җиһад алып барыгыз, җан-тәнегез илә нигезләнеп, яу коралларын белән коралланып, кяфер урысны чабырга яу чыгарга төрле тарафларга язулар һәм хәбәрләр җибәрдек.

Бу әйтелгән вәгъдәле көндә әзерләнеп атларга атланырга!

Вәгъдәгә хилаф итмәскә, бер көн һәм бер сәгать тә ул вәгъдәдән кичекмәскә!

Әй мөселманнар, изге яуга чыгыгыз! Җиһад итегез!..

Атларга атланыйк, Аллаһның кодрәтенә таянып, изге яуны башлыйк! Аллаһы Тәгалә боерса, җиңеп чыгарбыз!» — дип, чакыру ташлый[143].

Батырша мулла тарафыннан язылып, көрәштәшләре тарафыннан мөселманнар арасында киң таратылган «Өндәмә» коралы восстание әзерләүдә, көчләрне туплауда хәлиткеч рольне уйный.

Тарихчылар «Өндәмә»гә бик югары бәя бирделәр. Н.Фирсов «Өндәмә»не фетнәчеләр манифесты дип атаса, С.М.Васильев, «Өндәмә» 1755 елгы восстаниенең программасы, анда мөселманнарның ихтыяҗы күрсәтелә, биредә шулай ук көчләп чукындыруны бетерү, Русиянең Казакъстанны яулап алуын булдырмау турында таләбе дә бар[144], дип яза.

И.Г.Акманов Батыршаны восстание җитәкчесе итеп күрсәтү дөреслеккә туры килми, революциягә кадәрге тарихчылар шикелле аның исеме белән хәрәкәтне дә атап булмый, дип язды[145]. Дөреслеккә туры килмәгән бу фикер белән килешеп булмый. Ул заманда хакимият тарафыннан язылган документларда ук Батырша фетнә оештыручы итеп, «яла ягучы һәм котыртучы хат» авторы итеп шикләнмичә күрсәтелә. Тарихи әдәбиятта хәрәкәтләрне, фетнәләрне, восстаниеләрне җитәкчеләре исеме белән атау традициягә кергән. Шуңа күрә Батырша исеменең 1755 елгы вос-

---

[142] 1755 елның 3 июленә туры килә; «Өндәмә»нең урысча текстында восстание башлану вакыты итеп 1755 елның 1 июле күрсәтелә. Кара: Витевский И.И. Неплюев и Оренбургский край.— Казань, 1889.— С. 100.

[143] Батырша— выдающийся идеолог и вдохновитель...— С. 132.

[144] Фирсов Н. Күрс. хезм.— 431 б.; Васильев С.М. Күрс. хезм.— 29—30 б.

[145] Акманов И.Г. За правдивое освещение истории народов.— Уфа, 1995.— С. 57.

стание исеме булып тарихи әдәбиятка керүе табигый. Бу хакта А.П.Чулошников Батырша хакында, восстаниене рухландыручы һәм армый-талмый оештыручы, дип язган иде инде. Без Батыршаның биографиясеннән һәм моңа кадәр сакланып килгән документлардан аның ислам әдәбиятын бик яхшы белгәнлеген, башкалардан аерылып торган акылын һәм сәләтен, тирә-яктагы хәлләргә, бигрәк тә Башкортстанга һәм Казакъстанга карата патша колониаль сәясәтенә биргән зирәк бәяләмәсен күрәбез[146].

Дөрестән дә, сакланып калган документлар, бигрәк тә Батырша үзе язган «Өндәмә» һәм «Патшабикә Елизавета Петровнага хаты», архивта сакланган тикшерү эше Батыршаның восстаниене армый-талмый хәзерләве, һөҗүм оештыруы турында сөйлиләр. Гыйсъянчы имамны восстаниене оештыручы итеп күрсәткән кайбер эпизодларга тукталып китик.

Беренчедән, Батырша Башкортстанның төрле төбәкләрен йөреп чыга, анда кирәкле көрәштәшләр туплый. Күренекле тарихчы Әхмәтзәки Вәлиди фикеренчә, Батырша, Казан, казакъ төрекләренә вәкилләр җибәреп, иттифак тәкъдим итә. Батыршаның төп көчләрен Тангаур, Үсергән, Тамьян, Сувар, Кыпчак, Сәңкем-Кыпчак кабиләләре тәшкил итә[147].

Батырша кулы белән язылган һәм аның ике шәкерте (Исмәгыйль һәм Моталлип) тарафыннан яңадан 6 экземпляр күчерелгән бу «Өндәмә» восстаниене хәзерләгәндә иң төп рольне уйный. Соңыннан тикшерү үткәргәндә, «Өндәмә»нең мөселманнар яшәгән күп төбәкләргә, бигрәк тә Уфа өязенең дүрт юлына, казакъларга һәм Казан өязенә җибәрелүе билгеле була[148]. «Өндәмә»нең мөселманнар арасында киң таралуына «Бу язу кемнең кулына төшсә, илдән илгә һич йобанмайынча йөретегез» дип язылган кисәтүнең дә файдасы булган, ахры[149].

Батырша 1755 елның май ахырында «Өндәмә»не үзенең шәкерте Исмәгыйль Апкин аша Уфа өязе Уса юлы Гәйнә вулысына җибәрә. Аны юлга озатканда: «Мелла Исмәгыйль! Бу хатны Гәйнә иләүенә илтүб,хәлүәт ердә бер кешегә тапшыргыл вә ул кешегә әйткел: Ялан халыклары хатта язылган юнәлештә тырышлык күрсәтәләр; сезгә дә тырышлык күрсәтергә һәм хаттагы тәкъдимнәрне тормышка ашыру өчен тырышлык күрсәтергә кирәк», — дип кисәтә Батырша мулла. Батыршаның шәкерте, «Өндәмә»не кирәк кешегә тапшырып, кире Карышка әйләнеп кайта. Гәйнә вулысында ул Башап авылыннан Акчура Ягутеев, Төңгәк авылыннан Чурагол Миңлебаев белән очраша. Тикшерү вакытында «Өндәмә» Чурагол Миңлебаев өендә табыла.

---

[146] Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 63 б.
[147] Вәлиди Ә. Күрс. хезм.— 164 б.
[148] Васильев С.М. Күрс. хезм.— 27 б.
[149] Батырша— выдающийся идеолог и вдохновитель...— С. 132.

Шул ук вакытта Сәфәр Ягъфәров «Өндәмә»не Исәт провинциясе Әй вулысы Исмәгыйль авылына тапшырып кайта. «Өндәмә»нең төрле төбәкләрдә таралуы хакында Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев та хәбәр итә. Аның фикеренчә, хатлар Казан губернасы татарларына, Җаек елгасы тирәсендә күчеп йөрүче кыргыз-казакъларга җибәрелгән; ул хатта фетнәнең башлану көне һәм сәгате дә күрсәтелгән иде[150]. Шул мәгълүматларны П.И.Рычков та китерә.

Мулла Батырша фикере буенча, беренче булып Уфа өязе Ногай юлындагы башкортлар баш күтәрәләр. Аларга Башкортстанның төрле төбәкләрендәге мөселманнар кушылырга тиеш була. Уңышсызлыкка очраган вакытта фетнәчеләр, Җаек елгасын кичеп, казакълар җиренә вакытлыча китеп, казакълар белән бергә Башкортстанга килеп, көрәш оештырырга тиеш булалар. Башкортстанның төньягында урнашкан Гәйнә вулысы мөселманнары Көнгер һәм Уса шәһәрләренә һөҗүм оештырырга тиеш булалар. Андагы восстание Чулман буйлап Казан губернасы татарлары тирәсендә тарала. Карышбашта җыелган фетнәчеләр Батырша мулла җитәкчелегендә старшина Яныш Абдуллинны җәзага тартканнан соң, Ельдяк крепосте, Калинники авылы аша, каршылык күрсәткән авылларны талап, Уфа шәһәренә юнәлергә тиеш була[151]. Шушы планнарны тормышка ашыру өчен Батырша һәм аның тарафдарлары көне-төне хәзерлек алып баралар.

Бөрҗән вулысындагы восстание (май ае)

Вакыйгалар шундый тиз үсеш алалар ки, урыс баскыннарына, милли һәм дини изүгә каршы халыкның ачуы шулкадәр көчле була — Бөрҗән вулысы башкортлары билгеләнгән көннән күпкә элек, 1755 елның май аенда ук фетнә башлыйлар. Елан Иткол һәм Ходайбирде җитәкчелегендәге башкортлар тарафыннан 15 майда Урал тауларында алтын-көмеш, тимер-бакыр, кыйммәтле ташлар эзләр өчен җибәрелгән экспедиция начальнигы Брагин һәм аның командасындагы 6 кеше үтерелә. Брагин Ногай юлының көньяк вулысларына төсле ташлар эзләү өчен җибәрелгән була. Тик ул биредә кыйммәтле ташлар гына эзләми, ә җирле халыкны көчләү һәм талау белән дә шөгыльләнә. Фетнәчеләр моны болай аңлаталар: «Бер завод начальнигы вур һәм явыз иптәшләре белән безнең мал-мөлкәтне талады, үзебезнең биләмәләребездәге җирдән һәм судан мәхрүм итте, күз алды-

---

[150] Неплюев И.И. Записки.— С. 144—145.

[151] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. II, л. 258 об.; Чулошников А.П. Курс. хезм.— 70 б.; Васильев С.М. Курс. хезм.— 30 б.

быздa кызларыбызны һәм хатыннарыбызны көчләде, зина кылды».

18 майда Исәт юлындагы Сапсал ям станын һәм Брагинның яшәгән йортын туздыралар, юлда йөрүче түрәләргә, почта станнарын каравыллаган драгуннарга һөҗүм оештыралар. Сапсал станын туздыру бөтен Исәт трактын эштән чыгара, чөнки биредә хезмәт иткән башкортлар эшләрен туктатып таралалар. Фетнәчеләрнең җитәкчеләре Елан Иткол һәм Ходайбирде мулла Брагин партиясендә эшләгән булалар.

Киләчәк планнарын тикшерү һәм билгеләү өчен, Сапсал ямын туздырганнан соң, Елан Иткол, Ходайбирде мулла Талкас күлендә баш күтәрүчеләр җыенын үткәрәләр. Старшина Бикбулат Аркаев һәм Алкаш Сөендеков җитәкчелегендә шул ук вакытта икенче төркем Исмәгыйль йөзбаш биләмәләре булган Сакмар суы тирәсендә 2 старшина, 6 йөзбаш, 80 кеше катнашында җыен үткәрелә. Биредә восстаниене туктатырга, башка урыннарда һөҗүм оештырмаска, оборона белән чикләнү турында карар кабул ителә. Сапсал ямын туздыруда катнашканнарны Башкортстаннан казакъ ягына качып китәргә өндиләр. Күп гаскәриләр килеп каршы тору мөмкинлеге булмаган очракта башка фетнәчеләр дә казакълар ягына күчеп китәргә тиеш була. Мондый карар кабул ителү восстаниене бөтенләй туктата. Шушы карар нигезендә восстаниедә катнашучылар Башкортстаннан казакъ далаларына күчәргә мәҗбүр булалар[152].

Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев тиз арада Бөрҗән вулысындагы чуалышларны тар-мар итү өчен мөһим чаралар күрә. 15 майда чуалышлар башланган булса, 18 майда бирегә подполковник Исаков җитәкчелегендә гаскәриләр командасын озата. Бу гаскәри команда 22 майда восстаниедә катнашучыларны җәзалауны башлый. Губернатор И.И.Неплюев подполковник Исаковны «явыз фетнәчеләргә, башка иноверецларны куркыту өчен, аларның тормыш иткән урыннарында сәбәп табып, чуалышларда катнашуда шик тудыручыларны кулга алырга, богаулап ныклы каравыл астында Ырынбурга җибәрергә» дигән күрсәтмә биреп озата. Боларга өстәп тагын 1000нән артык солдат һәм казаклар бирегә җибәрелә. Фетнә бастыруда хакимият органнарына тугры калган башкорт һәм мишәр старшиналары да катнашалар. Бөрҗән вулысындагы чуалышларны бастыруда катнашкан төрле гаскәри командаларны җитәкләүче итеп Ырынбур коменданты бригадир Бахметев билгеләнә. Фетнәдә катнашуда гаепләнгән башкортлар, аларның гаиләләре һәм туган-тумачалары кулга алына, мөлкәтләре хөкүмәт файдасына тартып алына. Исән калган башкортлар, карат командалардан качып, казакъ далаларына юнәләләр[153].

---

[152] Чулошников А.П. Курс. хезм.— 71 б.

[153] Акманов И.Г. Башкирские восстания в первой трети XVIII в.— Уфа, 1987.— С. 55.

21 майда капитан Лядомский командалыгы астында 45 кешедән торган драгуннар отряды Җаек елгасын кичәргә килгән 124 ир-аттан, 26 малайдан һәм 140 хатын-кыздан торган качакларны туктатырга тырышып карый. Драгуннар һәм качаклар арасында булган бәрелештә капитан, 2 капрал, 7 рядовой драгун үтерелә, 1 прапорщик һәм 29 драгун яралана. Башкортлар 4 кешене югалталар. Качаклар, драгуннарның барлык атларын алып, тик сыер көтүен калдырып, Җаек аша казакълар ягына китәләр[154].

Подполковник Исаков казакълар ягына качып китүчеләр арасыннан 2 кешене тотып ала; алар арасында Казан өязеннән бер абыз да була (башкортлар арасында имам, мулла вазифасын, гадәттә, Казан татарлары үтәвен дә күрсәтергә кирәк). Тоткыннардан сорау алу вакытында Бөрҗән вулысы старшиналары, йөзбашларының инде кыш көннәрендә үк яз айларында фетнә күтәрү турында сөйләшүләр алып барганлыклары, фетнәгә башка вулыслар да кушылыр дигән өметләре булганлыгы беленә. Фетнә башлаган башкортларның таләпләре — почта станнарын, Җаек елгасындагы крепостьларны юкка чыгару була[155].

Сенат губернатор И.И.Неплюевка фетнәне тар-мар иткәндә көч күп кулланмау турында махсус күрсәтмә бирә: «В том деле все силы употребили к умеренности, а не к жестокости, дабы так, как и прежде, от строгого поступка было, дальнего затруднения не произошло, и для этого велеть прилежно наблюдать, чтобы неповинные ни малого озлобления не понесли»[156]. Тик сенатның бу күрсәтмәсе чынбарлыкта үтәлми.

Башкорт старшиналары Бикбулат Аркаев, Алкаш Сөендеков һәм 6 йөзбаш, ирекле рәвештә бирелсәләр дә, рәхимсез рәвештә җәберләүне беренчеләрдән кичерәләр. Бөрҗән вулысында гына түгел, якын-тирәдә фетнәдә катнашуда гаепләнгән һәрбер шик тудырган башкортны, аның туган-тумачасын кулга алу, мал-мөлкәтен конфискацияләү, мал-туарын гаскәриләргә ашату өчен талау башлана. Мондый рәхимсез көчләүдән курыккан башкортлар урман-тауларга, күрше вулысларга качып китәләр. Кулга алынган старшиналар һәм йөзбашлар урынына бригадир Бахметев урыс хакимиятенә тугры булган, тик бу яктан түгел, ә читтән китерелгән кешеләрне билгели. Гадәттә алар йомышлы татар-мишәрләрдән булган. Башкортларны казакъ далаларына күчеп китүгә чик кую өчен, Югары Җаек һәм Орск крепостьлары арасында Казан драгун полкыннан 6 рота драгуннар урнаштырыла[157].

---

[154] Сенатский архив.— Т. 10.— С. 397; Фирсов Н. Күрс. хезм.— 433 б.; Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 72 б.

[155] Сенатский архив.— Т. 10.— С. 380—381, 397.

[156] Витевский В.Н. Күрс. хезм.— 861 б.

[157] Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 73 б.

И.И.Неплюев Кече кыргыз-кайсак урдасы ханы Нуралигә һәм Урта урда солтаны Аблайга хат җибәрә. Бу хатта бирегә качкын башкортлар килеп чыккан очракта, аларны казакъларга бирәмләп кол итеп таратырга куша. Сенат И.И.Неплюевның бу тәкъдиме белән килешми, качып киткән башкортларны кире Русиягә кайтаруны таләп итә[158].

Башкортларга алга таба фетнә күтәрү мөмкинлеген юкка чыгару ниятеннән Бөрҗән вулысы үзәгендә баскынчылар Зилаир кальгасы төзи башлыйлар; әлбәттә, бу крепость-кальганы шул ук башкортлар төзергә тиеш була; шул арада җирле халыкны көчләү, мөлкәтләрен конфискацияләү, мал-туарларын суеп, гаскәриләрне ашату дәвам итә. Зилаир крепосте яңа дистрикт үзәге итеп игълан ителә. Бу дистриктка Бөрҗән, Тамьян, Усергән, Тангаур, Сугун-Кыпчак, Бушман-Кыпчак, Чалкын-Кыпчак вулыслары кертелә[159].

Шулай итеп, Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев тарафыннан Бөрҗән вулысында май аенда булган чуалышларны тармар итү өчен кулланылган ысуллар яхшы нәтиҗә бирә, фетнәчеләр тар-мар ителә, халкы тынычландырыла. Тик шул ук чамасыз көч кулланып чуалышларны бастыру яңа, тагын да көчлерәк чуалышларга мөһим этәргеч булып тора.

Ногай юлындагы восстание (август — октябрь айлары)

Бөрҗән вулысында булган вакыйгалар турында хәбәрләр алгач та, Батырша төрле төбәкләрдәге мөселманнарның бердәм баш күтәрү юнәлешендәге эшне туктатмый, киресенчә, тагын да активлаштыра. А.П.Чулошников фикеренчә, төрле төбәкләрдәге мөселманнар белән яңа чыгыш ясауның вакытын билгеләргә кирәк иде. Бу эшне үз өстенә Батырша ала. Ул, июль урталарында Ырынбурга баруны сылтау итеп, Ногай юлы башкортлары белән очраша[160].

Аңлашыла ки, Батыршаның Бөрҗән вулысында булган вакыйгалар белән танышасы, тикшерәсе, тиз җиңелүнең сәбәпләрен ачасы килә. Ырынбурга сәяхәткә ул шәкерте Габделмоталлип Юнысовны ала. Юлда Батырша Бөрҗән халкы тора торган ямда башкортлар белән очраша, аларның күрсәтелгән көннән алда чыгыш ясауларының, тиз җиңелүләренең сәбәпләре турында, шулай ук киләчәккә планнары хакында сөйләшүләр алып бара. Күпләренең казакълар ягына качып китүгә карамастан, май аендагы уңышсызлыкларга бөрҗәнлеләр мораль яктан җи-

---

[158] Фирсов Н. Курс. хезм.— 434 б.
[159] Сенатский архив.— Т. 9.— С. 40.
[160] Чулошников А.П. Курс. хезм.— 77 б.

һелмиләр, алар яңа көрәшкә әзерлек, изге көрәштә җиңүгә ышаныч белдерәләр. Төп сәбәпне Батырша патшабикәгә язган хатында түбәндәге сүзләр белән тасвирлый: «Безләр һәм дүрт юл халкы барчаларымыз берлә хәрәкәтләнербез дип торабыз иде. Вәләкин чыдамак булмады. Бәлкем, ярым көн кадәре дә сабыр итмәк такатемез калмады. Бу рәвешле халкымызның вә босмакы, вә ата, вә бабаларымыз биләй торган оҗмах тик хуш җирләремез вә суларымызны ташлаб китмәке падишамызның хәләгәтләрен вә мәрхәмәтләрен йөкли алмаганлык өчен түгел, бәлкем залимнарның җәфасы сәбәбендә тикрә януымызны ут алып, бер сәгать тә торырга такать тота алмаганлыгыбыз өчендер». Батырша өчен иң кирәкле сүзләр түбәндәге: «Аллаһ белгүчерәктер, әгәр халайык хәрәкәтләнсәләр, хушдур, бергә булырбыз, вә әгәр хәрәкәтләнмәсәләр, ахыр безнең хәрәкәтләнмәй чарамыз булмас. Аның өчен бер-беребезнең өстенә тел булып тотылып, котылып бетәрмез. Безнең падишаһка һич тә вурлыкымыз булмаса да, залим урысларның золымлыгына чыдый алмаганлыгыбызны вурлык итәләр. Урыслар никадәр күп золымлык вә вурлык итсәләр дә, аларны вур итмиләр күрәсез кем. Кулга төшкән кешеләремезнең һичберсе сүзе тыңланып, һичберсе кайтканы юк. Бәлкем һәрберсе вурлык аты берлә һәлак булалар. Бәс, ни җирдән өмет тотып басмый торайук, һәрни булса, Ходайга тәвәккәл кылып хәрәкәтләнмәк бер хәерле фәһем кылынадыр»[161]. Патшабикәгә язган хатында Батырша тагын башкалар белән очрашуы турында хәбәр итми. Шулай да Батырша Ырынбурга җиткәнче Ногай юлында яшәгән башкортлар, вулыс җитәкчеләре, дин әһелләре белән һәрдаим сөйләшүләр алып баруына безнең шигебез юк. Шулай эшләнмәсә, август аенда бөтен Ногай юлы халкы берьюлы дәррәү күтәрелә алмаган булыр иде.

Батырша Ырынбурда Ибраһим ахун белән күрешеп, берике көн сөйләшүләр алып бара, аның хөрмәтенә оештырылган мәҗлесләрдә катнаша. Батыршага Ырынбур ахуны «ахунлык рисаләсен төзеп, мөһеремезне салуб, ул рисаләне Габдессәлам ахунга бирдем кул куеп, сезгә тәслим кылыр өчен. Ул рисаләне кабул итеп алгайсыз, егетлек һәйәтеңезне терәк итеп мәшаих һәйәте илә һәйәтләнгәйсез», — дип, нәсыйхәтләр бирә. Тик Батырша бу хөрмәтле, мактаулы исемнән баш тарта[162].

Мәҗлесләрдә аралашу вакытында хакимиятнең урыс булмаган халыкларга карата алып барылган сәясәтенә ризасызлык сүзләре әйтелә: «Бу фәһемсез янаралның төне, көне фикере вә хыялы, халайыкларга бәлаләр вә авырлыклар җитештереп, йортны вәйран итмәктәдер. Бу фәһемсезнең вакытында ничәмә фетнәләр йөкләнде халайык өстенә. Ахыр такатьсез булып, баш качырырга катлана башладылар, диде».

---

[161] Письмо Батырши...— С. 51—52.
[162] Шунда ук.— 52 б.

Ырынбурда эшен бетергәч, Батырша Каргалыга килә, анда Габдессәлам ахунның өендә берничә көн кунак була, аның хөрмәтенә җыелган мәҗлесләрдә катнаша. Биредә ул Сөләйман старшина командасыннан яхшы танышы, бәлки, тарафдары Габдессәлам мәдрәсәсендә белем алган Габдессаттар белән очрашып, серләрен уртаклаша. Аның аша Каргалы татарларын май аендагы чуалышларны бастыру өчен походка җибәрүне белә, «кяферләр үзләре хәтсез золымлыклар итәләр дә, безнең мөселманнарымызның канларын нахак түгәргә катланалар» дигән сүзләр ишетелә[163].

Батырша биредән Казан өязе Алат юлы йөзбашы Ярмәкәй Мамашевка хат язып җибәрә. Хатта ул Уфа өязе барлык дүрт юл халыклары әзер, Казан татарлары да әзер булып торсыннар, дигән хәбәр сала. Тикшерү вакытында Казан татарларыннан шәкерт булган Исмәгыйль Апкин да Казан татарларының башкортлар белән бергә хәрәкәт итәргә әзерлеге турында хәбәр итә[164].

Әлбәттә, Батырша Ырынбурда да, Каргалыда да кунак булып кына йөрмәгән. Киресенчә, мәҗлесләр восстаниене оештыруда, бергәләп чыгыш ясау вакытын билгеләүдә мөһим рольне уйнаганнар. Тикшерү вакытында Көчекбай Иманголов тикмәгә генә, Ырынбур татарлары фетнәдә катнашырга риза иделәр, дип әйтми. Ә Чурагол Миңлебаев Батырша Ырынбурда Ибраһим ахун, Сәгыйть бистәсендә (Каргалы) Габдессәлам ахун белән сөйләшеп, аларны фетнәдә катнашырга чакыра, ә алар, ризалык биреп, башкалар фетнә күтәрсә, катнашачакларын белдерәләр, дигән сүзләр әйтә[165].

Восстание башлауның яңа вакыты турында килешеп, планнарны тикшереп һәм уртак фикергә килгәннән соң, Батырша шәкерте белән әйләнеп Карышка кайта һәм восстаниене әзерләүне дәвам итә.

Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев 27 июльдә губернада тынычлык урнашу турында сенатка сөенечле хәбәр юллый. Бу доношениедә бригадир Бахметев Зилаир елгасында крепость төзү, печән хәзерләү, яңадан куелган старшиналарның үз вазифаларын үтәргә керешүе, башкортларны армия хезмәте урынына крепость төзү өчен урманнан агач ташу һәм печән хәзерләү эшенә алынуы, аларның бу эшкә керешүе турында хәбәр итә[166].

Яңа килешенгән көнне, 9 августта, җирле администрация өчен көтелмәгән яңа чуалышлар башланып китә. Иң беренче булып Урал тауларының көнчыгыш битендә урнашкан Бөрҗән

---

163 Шунда ук.— 52—53 б.

164 РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 1, л. 122; Сенатский архив.— Т. 10.— С. 4.

165 Сенатский архив.— Т. 9.— С. 473.

166 Чулошников А.П. Курс. хезм.— 79 б.

вулысы башкортлары тагын баш күтәрәләр. Яубасар Аздуров җитәкчелегендәге 50 — 60 яугирдән торган отряд Запян (урысча шулай.— *Ф.И.*) авылында мишәрләрдән старшина итеп куелган Габдулла Вәһаповны, аның писарен, 2 йомышлы татарны үтерәләр. Старшина Шәрип Мряков, шундый ук хәл булудан куркып, Мосоловның Караниколь заводына кереп качып котыла.

Фетнәчеләр 9 августта Ык буенда төзелеп килүче барон Сиверсның Вознесенский бакыр заводына һөҗүм оештыралар, заводка беркетелгән 134 атны урлап китәләр, завод өчен әзерләнгән каен тузын яндыралар, кайбер урыннарда завод урманнарына ут төртәләр. Тиз арада фетнә тирә-яктагы вулысларга тарала. Югары Җаек крепостеннан Бөрҗән вулысына бригадир Бахметев янына килүче прапорщик Страдьин юлда урнашкан ям станцияләрендә ямщикларны да, драгуннарны да очратмый; бер урында үтерелгән драгунны гына күрә.

Барнаул елгасы буенда драгуннар өчен печән чабучылар янына урманнан башкортлар йөгереп чыгып: «Сез нишләп биредә торасыз? Бөтен Башкортстанда фетнә кайный, өйләрегезгә таралыгыз!» — дип кычкыралар. Печән чабучыларны күзәтеп, тикшереп торган драгунны атып яралаганнан соң, башкортлар урманга кереп качалар. Алар артыннан печәнчеләр дә өйләренә таралалар.

9 августта фетнәчеләр, Твердышев заводы тирәсенә килеп, заводны яндыру белән яныйлар. 11 августта фетнәчеләр Воздвиженский крепосте тирәсендә печәндә эшләгән 50 кешене үтереп китәләр[167]. 15 августта Покровский заводы яндырыла. Заводларга агач ташырга алынган Тангаур вулысы башкортлары эшләрен ташлап китәләр, Зилаир крепосте солдатларын кыйныйлар, урманны яндыралар, заводка алынган атларны урлыйлар. Коралланган фетнәчеләр отряды Зилаир крепостен, Преображенский һәм Вознесенский заводларын камап алалар, Баракал, Урал, Сапсал почта ямнарын талыйлар һәм яндыралар.

18 августта Зилаир крепостеннан утыз чакрым ераклыкта Көчекбай җитәкчелегендәге гыйсъянчылар бригадир Бахметев тарафыннан Әүзән-Петров заводына җибәрелгән 30 Ырынбур казагыннан һәм бер рота драгуннардан торган капитан Шкапский командасын юкка чыгара. Казаклардан һәм драгуннардан торган бу отряд фетнәчеләр булмаган юлдан озатылса да, фетнәчеләр команданың юлында засада оештыралар; урмандагы сукмакның ике ягыннан да сазлыклы урында фетнәчеләр казакларны һәм драгуннарны бөтен яктан да камап алалар һәм һөҗүмгә күчәләр. Юкка чыгарылган гаскәри командадан 2 калмык һәм 3 башкорт кына исән кала. Бу бәрелештә фетнәчеләрнең җитәкчесе Көчекбай да вафат була[168].

Фетнәчеләрнең зур хәрби команданы юкка чыгаруы гаскә-

---

[167] Фирсов Н. Күрс. хезм.— 435 б.
[168] Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 83 б.

риләр, хакимият чиновниклары арасында каушау, аптыраш уята. Моннан файдаланып төрле вулыс башкортлары, Җаекны кичеп, казакълар ягына качып котылалар. Усергән вулысы старшинасы Куәт Инзягулов җитәкчелегендәге 600 башкорт, балаларын, хатыннарын, мал-туарын алып, казакълар ягына качалар.

20 августка фетнәгә Усергән, Бөрҗән, Тамьян, Тангаур, Бушман-Кыпчак, Сувун-Кыпчак вулыслары кушыла. Казакълар ягына күчеп китүчеләр белән җәзалау отрядлары арасында бәрелешләр булып тора. Кулга төшерелгән башкортлар кыргыз-кайсаклар белән бергә крепостьларга һөҗүмнәр, урысларны үтерү, ат көтүен куу хакында хәбәр итәләр. Чыннан да, фетнәчеләр заводларга, крепостьларга, почта ямнарына һөҗүм оештыргач та, балаларын һәм хатыннарын алып, Җаекны кичәргә, анда казакъларга кушылып, яңадан Башкортстанга әйләнеп кайтырга һәм, урысларны бөтенләй куып чыгарырга яисә юкка чыгарырга исәпләп, казакълар ягына күчеп китәләр.

Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев, фетнәне тиз арада бастыру өчен, урыс гаскәриләрен, аларга ярдәмгә баскыннарга тугры калган башкорт, мишәр командаларын фетнә кайнаган төбәкләргә озата. Мәскәү, Ревель, Троицк полклары, «котлары очсын өчен беркемне дә, хәтта аларның хатыннарын һәм балаларын кызганмаска» дигән боерык алып, фетнәне бастырырга юнәлә. Восстаниене бастыру өчен 1000 калмык, 1000 дон казагы, 1000 Ырынбур казагы һәм 500 чукынган калмыкларны казакълар белән чикне ныгыту өчен озаталар.

Башланган восстаниене бастыру өчен И.И.Неплюев төрле чараларны: гаскәр көче, хәйлә, ялган, сатып алу, рәхимсезлек — барысын да куллана, фетнә күтәргән башкортлар белән казакъларны бик оста бер-берсенә каршы куя. Ырынбур ахуны исеменнән башкортларга һәм казакъ далаларына уйдырма мөрәҗәгатьләр тарата, болардан Ырынбур ахуны бөтенләй хәбәрдар булмый. Нурали ханга башкортларга ярдәм итмәүне таләп итеп хат яза. И.И.Неплюев үзенең улы исеменнән казакъ старшиналарына башкорт фетнәсен бастыруда катнашкан өчен бүләкләр җибәрә, патша хәзрәтләренең шәфкатен тантаналы рәвештә вәгъдә итә[169]. Патшабикә Елизавета Петровна исеменнән 1 сентябрьдә үзләре теләп бирелгәннәргә гафу итү, казакъларга качып китүчеләрне 6 айда туган якларына әйләнеп кайту турында манифест кабул ителә. Манифест урыс телендә — 580, татарча 200 экземпляр халык арасында таратыла.

И.И.Неплюев соравы буенча Ырынбур губернасына булган гаскәргә өстәп 8 полк һәм 2 мең дон казагы озатыла.

Восстаниене бастыруда Кызыл крепость командиры подполковник кенәз Назаров актив катнаша. Ул фетнәчеләрне чама-

---

[169] Баттал Г. Курс. хезм.— 74 б.; Витевский В.Н. Курс. хезм.— 864 б.

дан тыш җәзалау белән билгеле була: кулга төшкән атаклы старшина Баим-тархан җәзалап үтерелә, Тамьян вулысында кулга алынган атаклы башкорт Махнут җәзалана һәм Кызыл крепостенда вафат була; Назаров боерыгы белән төрле вулыслардан хәрби хезмәткә дип алынган 40 башкорт штык белән чәнчелә; крепостька хәрби хезмәт үтәргә дип килгән 93 башкорт арасында 66 сы төрмәгә утыртыла, калганнары үтерелә[170]. Подполковник Назаровның вәхшилеген белгән А.И.Тәфкилев Назаровның рәхимсезлеге булмаса, 6 вулыстан башкортлар казакълар ягына качып китмәсләр иде, ди. Назаров кылган рәхимсезлегеннән баш тартмый, тик аларны явыз фетнәчеләргә каршы куллану өчен мөһим чара дип аңлата.

Ногай юлында фетнәчеләргә каршы көрәш 9 августтан алып октябрь уртасына кадәр дәвам итә. Сентябрь, октябрь айларында да фетнәчеләрнең төркемнәре, Преображенский, Вознесенский, Югары Әүзән-Петров, Караниколь заводлары тирәсендә һөҗүм оештырып, завод атларын куып китәләр.

Шушы ук вакытта башкорт-казакълардан торган кечкенә отрядлар Югары Җаек һәм Уй крепостьлары арасындагы ныгытмаларга һөҗүм итәләр, кешеләрне кулга төшереп, мал-туарны куып алып китәләр. Казакъларның башкортларга ярдәме озак бармый, әкренләп сүнә.

Фетнәчеләргә каршы төрле ысуллар кулланып, И.И.Неплюев уңышка ирешә: вулысларда башланган фетнәне башкаларына таралуга чик куя, фетнәчеләрнең отрядларын тар-мар итә, фетнәне Казан губернасына таралудан коткара, казакъларны фетнәчеләрдән уңышлы аера. Ырынбур губернаторының бу хезмәтләрен тарихчы В.Н.Витевский, моңарчы күрелмәгән гайрәт, зирәк дипломатик акыл белән, үзенә каршы көрәшүче кешеләрне тирәнтен аңлаучы дип бәяли.

Гәйнә вулысындагы чуалышлар

Уфа өязенең Уса юлы буенча төньякта урнашкан Гәйнә вулысы фетнәнең икенче үзәгенә әверелә. Күрәсең, Батыршаның Байавылда балаларга сабак биргән чордан ук мулла-мөдәррисләр, гомумән, халык арасында шактый таныш-белешләре сакланган булгандыр. Аның мәдрәсәсендә дә Гәйнә ягыннан шәкертләр булган. Ул Төңгәк авылыннан Исхак мулла Морзалиев һәм башкалар белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыра, биредә Исмәгыйль Апкин алып килгән «Өндәмә» дә киң таратыла.

Восстаниене әзерләүдә муллалардан Чурагол Миңлебаев, Исхак Морзалиев, Кәчекбай Имангулов, Акчура Ягутеев иң актив рольне уйныйлар. Юкка гына Чурагол Миңлебаев Уса төрмә-

[170] Сенатский архив.— Т. 10.— С. 395—396.

сендә сорау алу чорында беренчеләрдән булып җәзалап үтерелми. Төңгәк авылыннан Исхак мулла Морзалиев 1755 елның яз айларында Карыш авылында Батырша янында бер ай бергә була. Тикшерү вакытында ул Карышта булуны дини белемен камилләштерү белән аңлатса да, аның бирегә икенче максат белән килгәнлеге ачык сизелә. Алдарак, яз айларында, «Өндәмә» язылуы турында без әйтеп киткән идек инде. Язгы эшләр башланыр алдыннан ул Төңгәккә әйләнеп кайта. Исхак мулла Морзалиев — Төңгәк белән Карыш арасында арадашчы ролен генә түгел, Гәйнә вулысында һәм Уса юлына кергән Уран, Ирәкте, башка вулысларда фетнәчеләр рәтенә кертер өчен күп көч куйган шәхес. Әкренләп фетнә әзерләүчеләр рәте арта. Бу хакта тикшерү материаллары яхшы дәлил булып торалар, чөнки анда төрле авыл кешеләре хакында мәгълүматлар сакланган.

Бераздан Батырша янына Төңгәк авылы мулласы Исхак Морзалиев Көчекбай Имангулов белән килеп киңәшеп китә. Күрәсең, Исмәгыйль Исхак мулланы Карышка чакырган булган. Гәйнәлеләр белән әңгәмәдә Карыш авылыннан Борһан Мостафа улы да катнаша. Биредә Гәйнә иленең баш күтәрергә әзер булганлыгы ачыклана. Батыршага алар Чурагол мулланың бу хактагы фикерен җиткерәләр. «Безнең урман тарафлылар Гәйнәгә табиг халайыклар, барчамыз әзермез. Җибәрделәр безне сезнең хәзрәтеңезгә хәбәр белер өчен». Батырша фетнәне башларга ашыкмаска куша, үзенең Ырынбурга барып кайтачагын, аннан соң гына баскыннарга каршы көрәш башларга кирәклеген күрсәтә[171].

Батырша биредә фетнәнең максатын да әйтә: безгә тозны бушлай алырга рөхсәт итмиләр, ясак түләүне бетерсәләр дә, халык санын алганнан соң элек бөтенләй бездә булмаган рекрут алуны кертәчәкләр, без бик аяныч хәлдә калабыз, ә бу хакта патшабикә галиҗәнаплары белми, без язган шикаятьләрне аңа тапшырмыйлар, патшабикәгә шикаять тапшыру өчен безне тоткарлыйлар, паспорт бирмиләр. Шуңа күрә Батырша Русиягә каршы фетнә күтәрергә хәзерли, аның белән шактый кешеләр килешә, фетнә күтәргәч кенә патшабикә фетнәнең сәбәбен белер һәм безгә мәрхәмәтлек эшләр[172]. Мөселманнарның хәлен патшабикәгә фетнә күтәреп кенә җиткерү идеясен башкалар да уртаклашканга охшый. Чөнки Чурагол Миңлебаев сорау алган вакытта нәкъ шушы сүзләрне кабатлый. Шушы фикер нигезендә гыйсъянчы мулла, восстание күтәреп, нинди максатка ирешү мөмкинлеген реаль аңлаган дип әйтергә мөмкин. Чыннан да, «Өндәмә»дә киләчәк җиңү шиксез билгеләнсә дә, сорау алу вакытында ул фикерләр икенчегә әйләнә. Дәүләт машинасын фетнә күтәреп кенә җиңеп булмаслыгын ул яхшы аңлаган дип уйларга

---

[171] Письмо Батырши...— С. 50.
[172] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 2, л.195 об.; л.196.

урын кала. Шуңа күрә фетнәне патшабикә галиҗәнапларына халык бөлгенлеге турында җиткерү ысулы дип карау табигый.

Гәйнәлеләрнең дини һәм икътисади изүгә каршы көрәшкә җитди әзерлек алып баруы хакимият тарафыннан сизелми калмаган, билгеле. Гәйнә вулысы старшинасы Әбдүк Хуҗагулов 1755 елның 16 июлендә Уса воевода кәнселәренә аның вулысындагы дүрт авылның егерме башкорты фетнә башларга җыена, дип хәбәр сала. Вулыска килгән солдатлар старшина күрсәткән кешеләрне тотып алып китә алмыйлар, алар качып котыла[173]. Тик бу сигнал буенча җирле администрация фетнәгә хәзерлекне белү өчен мөһим тикшерүне үткәрми, чаралар күрми.

1755 елның август урталарында Нури Баскунов, Акчура Ягутеев, Гәйнә вулысындагы башкалар белән бергә, Кызыл крепостена хәрби хезмәткә алыналар. Гәйнә илендә фетнә хәзерләүчеләр, моннан файдаланып, баш күтәрүне оештырыр өчен, көрәштәшләрен Карыштан барып аннан Гәйнәгә алып килү өчен китәләр.

Исхак Морзалиев башта, хәрби хезмәткә алынып өчен, Чокыр авылына, Ирәкте вулысы старшинасы Шәрип Кииков янына килә. Тик старшина командасы белән хәрби хезмәткә китеп өлгергән була; бәлки, Исхак мулла бу авылга махсус соңга калып килгәндер. Һәрхәлдә, юлда аны Нури Баскунов һәм Акчура Ягутеев куып җитәләр һәм бергәләп Карыш авылына китәләр. Батырша янына баруның сәбәбен «Русиягә каршы фетнә башлау хакында белү өчен»[174] дип аңлаталар.

Исхак Морзалиев, Нури Баскунов, Акчура Ягутеев Батырша белән Карыш авылыннан ерак булмаган кырда очрашалар. Бу вакытка йомышлы татарлардан 500, типтәр-бубыллардан 1000 кеше фетнәгә теләктәшлек белдерә. Гәйнәлеләр соравы буенча Батырша мулла Өреш авылыннан Галикәйне, Мөрәсимнән Максут белән Ырысколны, Торналыдан Йосыф мулланы үзе янына чакыра. Аларга Мостафа улы Борһан да кушыла. Батыршаның өендә зур киңәшмә үткәрелә. Биредә гыйсъянчылар җитәкчесе көрәштәшләренә иң яхшы атларга атланып, Гәйнәгә барып восстание башларга чакыра. Алар анда Төңгәк авылыннан Исхак мулла белән очрашып фетнә башларга һәм аны Уса юлындагы Уран, Ирәкте, Гәрәй вулысларына җәелдерергә тиеш булалар. Фетнәчеләр Карышта җыелганнан соң, Уфага поход оештырып, Ногай юлында барган көрәшкә ярдәм итмәкче булалар. Соңрак Батырша баш күтәрүгә Себер юлы халкы да кушылыр дип уйлый. Киңәшмәдә катнашучылар, дин өчен җаннарын кызганмаска әзерлекләрен белдереп, өйләренә таралалар, Гәйнәгә китәргә әзерләнәләр.

Батырша гәйнәлеләр белән иң ышанычлы 4 кешене — 2 шә-

[173] Сенатский архив.— Т. 9.— С. 406.
[174] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч.2, л.198—199 об.

кертен (Исмәгыйль Апкин, Әхмәр Кучеков), Мөрәсим авылыннан 2 кешене (Ырыскол Исланов, Максут Гайсин) озата.

Батыршаның көрәштәшләре Максут, Ырыскол, Исмәгыйль һәм Әхмәр Гәйнә вулысына августның икенче яртысында восстаниегә өндәү, аны оештыру өчен киләләр. Гәйнәгә кайту юлында Исхак Морзалиев, туган ягы — Ирәкте вулысында туктап, авылларда халыкны фетнәгә чакыра. Исхак мулла Төңгәктә яшәсә дә, документларда Ирәкте вулысыннан диелгән. Элекке тәртип буенча башкортларны, кайсы авылда яшәвенә карамастан, туган вулысы составында теркәгәннәр.

Нури Баскунов, Акчура Ягутеев, Исмәгыйль Апкин, Әхмәр Кучеков, Ырыскол Исланов, Максут Гайсиннан торган төркем Кайпан вулысындагы Тимбай Имангулов йортында туктап ял итәләр. Бирелән алар Төңгәк авылына юнәләләр.

Исхак Морзалиев, Ирәкте вулысында эшләрне бетереп, Төңгәк авылына кайтып төшүгә, Чурагол мулла белән очраша, аңарга Батырша белән очрашу турында сөйли. Ул вакытта Батыршаның кешеләре Башап авылында булалар.

Икенче төнне Исхак Морзалиев янына гәйнәлеләрдән 2 кеше килеп төрле авыл кешеләре Батырша авылына барыр өчен җыйналулары турында хәбәр итә. Исхак мулла, килгән кешеләргә кушылып, Аклыш авылына юнәлә. Ул авылда җыелган фетнәчеләрнең саны 30га җитә. Биредә Чурагол Миңлебаев та була. Аклыштагы җыенда Мостай Теребердин, Кажмакты авылында башкорт аксөякләреннән Туктамыш фетнәгә кушылырга теләми, безгә каршы чыкмакчы, дип чыгыш ясый[175]. Аклышта җыелган фетнәчеләр барысы да атларга атланган, кылычлар, кайберләре хәтта мылтык йә җәя-ук белән коралланган булалар. Фетнәчеләр Тол буендагы авылларда халыкны баш күтәрүгә чакыру, урысларны һәм фетнәгә кушылмаган башкортларны чапкылау теләген белдерәләр.

Чурагол мулла Батыршаның ике кешесе белән, Солтанай, Сараш, Аймуш, Башап авылларында җыеннар җыеп, халыкны баш күтәрергә чакыралар[176].

1755 елның 27— 28 августларында Мостай Теребердин белән Акбаш Андрюшев җитәкчелегендәге фетнәчеләр «чамасыз салым-акча җыючы» һәм колониаль хакимиятнең иң әшәке вәкилләреннән берсе булган Гәйнә вулысы старшинасы Әбдүк Хуҗагуловны үтерәләр[177]. Солтанай авылында Сәгыйть Чубаркин сугыш кирәк-ярагын әзерли башлый. Күп кенә авылларда, мәсәлән, Башапта, Солтанайда, Төңгәктә, Аклышта халык җыеннары үткәрелә, анда башкортлардан Чурагол мулла, Исхак мулла һәм ясаклы татар Акчура мулла Ягутеев ялкынлы чыгышлар ясый-

[175] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 2, л. 134—135.
[176] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 2, л. 183.
[177] Чулошников А.П. Курс. хезм.— 86 б.

лар. Бу җыеннарда Батыршаның «Өндәмә»се укыла һәм ул халык тарафыннан ачыктан-ачык көрәшкә чакыру итеп кабул ителә. Кыска вакыт эчендә Тол буендагы авылларның барысы да диярлек баш күтәрүчеләргә теләктәшлек белдерә: хәрби отрядлар төзиләр, төбәктәге баскыннар хакимиятенең терәге булган Уса һәм Көңгергә һөҗүм итәргә өндиләр. 1 сентябрь көнне гомуми һөҗүм башларга карар кылына.

Уса, Көңгер якларындагы урыслар, баш күтәрүгә хәзерлек барганын сизеп, пошаманга калалар. Алар арасында ясаклы татарларның һәм башкортларның Шавкуново бакыр заводына һөҗүмнәре, Торговижск, Сокольск кальгаларын, Медянка авылын камап торулары хакында хәбәрләр киң тарала, һәм алар биредә чын сугыш башланырга мөмкин дип тә уйлыйлар. Быково авылы кешеләре, йортларын ташлап, хатыннары һәм балалары белән Красноуфимск янындагы Ачит кальгасына күчеп китәләр. Ирән елгасы буендагы авылларда яшәүче татарларның восстаниегә әзерләнүе турындагы хәбәрләр юкка гына таралмаган булса кирәк, чөнки Батыршаның бер шәкерте — Дәүләтбай Хуҗагулов — Көңгер өязендәге Йанапай авылыннан була һәм ул восстание әзерләүдә бик актив катнаша; бәлки, ул гыйсъянчы мулланың «Өндәмә»сен бу якларда халык арасында тараткан булгандыр.

Бу вакыйгалар Көңгер елъязмасында үзенчәлекле, кызыклы чагылыш тапкан. Анда 1755 ел астында болай дип язылган: «Кайбер карак башкортлар Урал тауларында һәм Казан кальгасы янында Русия кешеләренә һөҗүм итәләр һәм үтерәләр, шулай ук чиктәш Гәйнә вулысының Көңгер һәм Уфа өязләрендәге башкортларда да шул чакта ризасызлыклар булды — шуның өчен Көңгердәге һәм өяздәге кальгаларда бу карак башкортлардан саклану чаралары күрелде: шул вакытта Ырынбурда яшәгән хакыйкый яшерен киңәшче һәм кавалер И.И.Неплюев әфәнде башкорт фетнәчеләрен тынычландыру өчен ике регуляр атлы полк җибәрде һәм Көңгер шәһәре белән өязе карак башкортлардан сакланып калды»[178].

Ләкин күптән уйланылган уй-теләкләр тормышка ашырылмыйча, киң җәелдерелгән әзерлекләр җитди хәрби хәрәкәтнең башы була алмый кала. Моның төп сәбәбе — Гәйнә вулысының элекке старшинасы үтерелгәннән соң сайланган Туктамыш Иҗбулатовның кискен хәрәкәткә күчүе. Старшина итеп сайлангач та, ул вулыста хөкүмәткә каршы юнәлдерелгән фетнәне туктату өчен кыю чаралар күрә. Чөнки шулай эшләгәндә генә, ягъни вулыста фетнәне булдырмыйча, ул үзенең чын старшина икәнен раслый алыр иде.

Кызыл Яр (Әрҗән) авылы фетнәчеләр белән аларга каршы чыгучыларның көрәш мәйданына әйләнә. Бирегә җыелган фет-

---

178 Кунгурская летопись Пиликиных.— Пермь, 1886.— С. 16—17.

нәчеләр саны — 50—60, икенче мәгълүматлар буенча 200 була. Туктамыш яклылар, зур каршылыкка очрамыйча, җыенны куып тараталар[179]. Тол буенда әзерләнгән фетнә кабына алмыйча сүнә. Туктамыш Ижбулатовның гыйсъянчыларны тарату өчен кылган эшләре Гәйнә иленең яңа старшинасының көчен һәм кодрәтен күрсәтә. Тиздән ул бу төбәкнең генә түгел, бөтен Башкортстанның иң мәртәбәле старшиналарына әверелә; соңрак ул Әби патша 1767 елны җыйган махсус Уложенная комиссия составына сайлана, анда берничә мәртәбә нотык та сөйли.

Шушы вакыйгадан соң фетнәчеләр оешканлык күрсәтә алмыйлар, тирә-якка таралалар; кайберләре Батырша белән очрашу өчен Карышка юнәләләр, тик алар килеп җиткәндә, Батырша инде авылда булмый.

Шушы ук вакытларда Батырша мулла борайлылардан «денсезләр һәм хаиннар бу төндә сезне үтерергә уйлыйлар, үзегезне коткару өчен ашыгыч һәм саклык белән чаралар күрегез» дигән кисәтүле хат ала. Мондый шөбһәле хат алганнан соң, Батырша, бу хәлдән котылу чарасын эзләп, «бернәрсәгә дә карамыйча, тәвәккәлләп, изүчеләргә каршы көрәшкә ташланыргамы, әллә актив хәрәкәтләрдән ваз кичеп торыргамы?» дип уйланып, йокысыз төн үткәрә. Хакимияткә аз гына булса да каршылык күрсәтү халыкка гаять зур афәт һәм бөлгенлек китерәчәге аңа яхшы мәгълүм була. Әмма ул барча мөселманнар киләчәктә дә даими көчәйгән рухи һәм икътисади изүгә тыныч кына түзеп тора икән, денсезләрнең мөселманнарны тәмам җиңәчәкләрен дә яхшы аңлый. Дин өчен, хөррият өчен, халыкларны колониаль изүдән коткару өчен көрәш юлын ул аңлы рәвештә сайлый, ләкин шөбһәләнер өчен дә урын кала.

1755 елның 1 сентябрендә Батырша, сөңге, җәя һәм уклар белән коралланып, гаиләсен (хатыны Зөлхәбирә, 7 яшьлек улы Таҗетдин, 3 яшьлек кызы Зөләйха, 1 яшьлек кызы Салиха), иң якын булган шәкертләрен (Яхъя, Мөхәммәдшәрип, Моталлип, Касыйм, Габделкәрим, Мирәхмәт, Мөслим, Габделгаффар, Дәүләтбай Хуҗагулов, Сәфәр Агаферов) алып, урманга кача. Батырша янына килгән гәйнәлеләр, аны Карышта очрата алмыйча, туган якларына кайтып китәләр.

Тикшерү вакытында Мостафа Хәсәнов сөйләвенә караганда, Гәйнә илендә Исмәгыйль Апкин, Әхмәр Кучеков кулга алынганын ишеткәч кенә, Батырша урманга качу турында карарга килә. Тагын шуны күрсәтеп китү кирәк дип уйлыйбыз: С.М.Васильев фикеренчә, Батырша патша җәлладлары кулына шунда ук эләгә. Тик бу фикер дөрес түгел.

Фетнәнең чикләре киңәюдән, бигрәк тә анда Казан татарлары кушылудан курыккан Русия хакимияте, төрле ташламалар биреп, мөселман халыкларын тынычландырмакчы була. Бу восс-

[179] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 2, л. 208.

таниенең милли һәм дә дини эзәрлекләү, көчләп чукындыруга каршы булганлыгын патшабикә үзе имза куйган фәрманнар яхшы күрсәтә. Тиз арада (ә мондый хәл бу чорга бөтенләй хас нәрсә түгел, юк кына мәсьәләләр дә еллар буе чишелмичә, чиновниклар өстәлендә тузанланып яткан вакытта), сентябрь башында ук, кайбер карарлар кабул ителә. 1755 елның 3 сентябрь көнендә чыккан указ нигезендә Казан һәм башка губерналардагы керәшеннәр белән бер авылда яшәгән чукынмаган татарларны икенче төбәкләргә күчереп утырту тыела, ә яңа чукынган керәшеннәрнең татарларга каршы булган шикаятьләрен губерна кәнсәләре православие руханилары белән бергә тикшерергә тиеш була. Чукынган татарларның салымнарын чукынмаганнарга түләтү бетерелә. Шулай итеп, татарларны кимсетә, икътисади бөлгенлеккә китерә торган төрле якларга күчереп утырту, өстәмә салым түләү тыела, керәшеннәр белән мөселманнар арасында килеп чыккан шикаятьләрне дөньяви хакимият даирәләре тикшерергә тиеш була. Бу фәрманда тагын игътибарга лаек бер урын бар: үзара гаепләүләрне, «билгеле вакыйгаларны» искә алып, дикъкать белән тикшерү зарур дип карала. Бирედәге «билгеле вакыйгалар»ны турыдан-туры Батырша восстаниесенә ишарә итү дип карарга кирәк.

Соңрак адмиралтействога кораблар төзү эшенә беркетелгән йомышлы татарларның һәм морзаларның кайбер таләпләре канәгатьләндерелә. 1756 елның 23 августында кабул ителгән указ нигезендә Казан, Нижгар, Әстерхан, Себер губерналарында мәчетләр төзергә рөхсәт ителә[180].

Ислам динен эзәрлекләү, мөселманнарны һәм мәҗүси халыкларын көчләп чукындыру буенча шөһрәт казанган Казан епискобы Лука Канашевич һәм Тубыл митрополиты Сильвестр Главацкий мөселманнар булмаган епархияләргә күчереләләр.

1755 елның 25 сентябрендә Уфа өязенең Уса юлына, фетнәне бастыру өчен, Троицк драгун полкыннан капитан Жеребцов җитәкчелегендә гаскәриләр командасы җибәрелә. Бу җәза отрядына оешкан каршылык күрсәтелми. Урындагы старшиналар, гаскәриләр килгәнгә кадәр ук, Батыршаның актив тарафдарларын кулга алып, хакимият органнарына тапшыралар. Батыршаның көрәштәшләрен кулга алуда старшиналардан Яныш Абдуллин, Шәрип Кииков, Туктамыш Ижбулатов бик зур ярдәм күрсәтәләр. Яныш Абдуллинның бу тырышлыгын исәпкә алып, хакимият аны старшиналардан беренче итеп кылыч, көмеш чүмеч һәм йөз тәңкә акча белән бүләкли.

* * *

[180] Полное собрание...— Сер. II.— Т. 4.— С. 230—234.

Восстаниенең җинелүе һәм анда катнашучыларның язмышы

Восстаниенең җиңелүе һәм әһәмияте

Старшина Туктамыш Ижбулатов һәм аның писаре Алексей Абдалов 1 сентябрьдә үк Уса воевода кәнселәренә Чурагол Миңлебаевны һәм Баскын Ербагышевны тотып алып киләләр. Тотылганнарны шунда ук кыйнап сорау алалар. Беренче сорау алуда ук старшина Әбдүк Хуҗагуловны үтерүче итеп Акбаш Андрюшев күрсәтелә. Акбаш Андрюшевтан Усада 3 сентябрьдә сорау алына. Ул старшина Әбдүк Хуҗагуловны иптәше Мостай Теребердин белән үтерүе турында әйтә. Сорау алганда старшинаны үтерүдә Яныш старшина авылыннан да ике кеше катнашуы билгеле була[181]. Старшинаны үтергән Мостай Теребердин үзе дә тоткан вакытта каршылык күрсәтә һәм үтерелә.

Батыршаның шәкертләре булган Уфа өязе Себер юлыннан Мөрәсе авылы мишәр-татары Ырыскол Ислановтан һәм Казан өязе Алат юлы Куныр авылы (хәзерге Татарстан Республикасы Балтач районы) ясаклы татары Исмәгыйль Апкиннан Уфа провинция кәнселәрендә 4 сентябрьдә сорау алалар. Димәк, Гәйнә вулысына восстание әзерләргә килгән шәкертләр бик тиз кулга алыналар.

Ирәкте вулысы старшинасы Шәрип Кииков Көчекбай Имангуловны Башап авылында кулга төшерә; Нури Баскуновны һәм Акчура Ягутеевны Солтанай авылында 23 сентябрьдә тота[182]. Шәрип Кииков шулай ук Исхак Морзалиевны да тотып тапшыра. Болардан тыш Гәйнә вулысында фетнәдә актив катнашкан Чурагол Миңлебаев, Сәгыйть Чубаркин, Кусьма Минкин, Сөяргол Никитин кулга алына. Чурагол Миңлебаевның өендә «Өндәмә» табыла. «Өндәмә»нең бер экземпляры Батыршаның келәтендә табыла[183].

Декабрь аенда Батыршаның шәкерте Дәүләтбай Хуҗагуловны туган ягы Көңгер өязе Йанапай авылына кайтып барганда Уфа өязе Байки авылында старшина Якуб Чыкмурзин кулга ала һәм Елдяк кантурына тапшыра. Елдяк кантурыннан аны Уфа төрмәсенә озаталар. Батыршаның шәкертләреннән Мөслим Ибраһимов 1756 елның 9 гыйнварында чукындырылган морза Тәфки-

---

[181] РГАДА.— Ф. 7, оп.1, д.1781, ч. 3, л. 44.
[182] РГАДА.— Ф. 7, оп.1, д. 1781, ч. 2, л. 182.
[183] РГАДА.— Ф. 7, оп.1, д. 1781, ч. 2, л. 260.

левның улы Йосыфта мулла булып хезмәт итүче Нурмөхәммәт булышлыгы белән кулга алына[184].

1755 елның 8 октябрендә Батыршаның хатыны Зөлхәбирә Хәсәнова һәм Батыршаның ике шәкертеннән Уфада сорау алына. Димәк, Батырша хатыны һәм шәкертләре белән Бөре елгасы буе урманнарында, чикләвек, җиләкләр белән тукланып, бер ай чамасы гына бергә була алган. Зөлхәбирә янында улы Таҗетдин, кызлары Зөләйха һәм Салиха да булган. Сорау алганда Зөлхәбирә ире турында бер начар сүз дә әйтми, үзенең Исәт провинциясе Мөслим старшинаның Олыкош авылы мишәр-татары Хәсән Такаев кызы булуы, утыз яшьтә, сигез ел элек Батыршага кияүгә чыгып, аның бердәнбер хатыны икәнлеген генә күрсәтә; Бөре урманнарында Батырша һәм башка шәкертләр белән бергә качып йөрүләре, анда Карамыш авылыннан урлап алынган атны суеп тукланулары турында сөйли[185].

Зөлхәбирә белән кулга алынучылар арасында аның энекәше, Батыршаның шәкерте һәм каенэнесе Мостафа Хәсәнов та була. Аннан да сорау алалар. Зөлхәбирәне балалары белән хезмәтче итеп тайный советник Борис Федорович Щербаковка тапшыралар, ә шәкертләрне төрмәгә утырталар.

Восстание әзерләүдә гаепләнеп барысы унбиш кеше кулга алына һәм Уса, Уфа төрмәләренә ябыла. 1756 елның 5 мартындагы указ нигезендә аларның барысын да Уфа төрмәсенә җыялар. Тик аларның барысы да ул вакытта инде исән-сау булмыйлар. Шул арада дүрт кеше — Максут Гайсин, Көчекбай Имангулов, Чурагол Миңлебаев һәм Нури Баскунов төрмәдә сорау алган вакытта вафат булалар.

1755 елның 26 сентябрендә Уфа өязендәге вакыйгаларны сенат, тышкы эшләр һәм военная коллегия берләштерелгән утырышында яңадан тикшерәләр. Восстаниене тар-мар итү хакында төрле яктан тирәнтен сөйләшкәннән соң, патшабикә галиҗәнапларына урыс булмаган халыклардан керәшеннәр өчен өстәмә салым түләтүне, рекрут алуны туктату, Тубыл митрополитын һәм Казан архиереен икенче урынга күчерү турында тәкъдим кабул итеөлә. Иртәгесе көнне чукынырга теләмәгән татарларны архиерей йортына япмаска, ә эшләрен губерна кәнсеәләренә тапшыру турында тәкъдим эшләнә[186].

2 октябрьдә сенат кабул иткән фәрман нигезендә Казанга губернатор итеп тайный советник Головин, гаскәрләргә ярдәм итәр өчен генерал-майор Иван Салтыков, генерал-майор Федор Ушаков һәм бригадирлардан Костюрин һәм Кнутов җибәрелә. Башкортстанга җыелган гаскәрләрнең җитәкчесе итеп И.А.Салтыков билгеләнә.

---

[184] Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 78 б.
[185] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 2, л. 139—141.
[186] Сенатский архив.— Т. 9.— С. 442.

Мәрҗани мәчете

Батырша.
Н.Хаҗиәхмәтов рәсеме







Татарларның мәчет төзергә рөхсәт сораган гариза күчермәсе

Зөядәге Богородицкий монастыре

Императрица Елизавета Петровна

Батырша. Р.Шәмсетдинов рәсеме

Петропавел крепосте



Петров капкасы

Шлиссельбург крепосте

Шлиссельбург крепостенда җимерелгән казематлар





Шлиссельбург крепостеның планы

1. Король манарасы. XVI г.
2. Байрак манарасы. XVI г.
3. Головкин манарасы. XVI г.
4. Головин (баш?) манарасы. XVI г.
5. Падишаһ (Государева) манарасы. XVI г.
6. Меньшиков манарасы (сакланмаган)
7. Светличная манарасы
8. Тегермән (Мельничная) манарасы (сакланмаган)
9. Чаң (Колокольная) манарасы (сакланмаган)
10. Яшерен (Секретный) йорт (Иске төрмә). XVIII — XIX г.
11. Яңа (народоволецлар) төрмә. XIX г.
12. Орешекны 1941 — 1943 елларда яклау хөрмәтенә төзелгән истәлек комплексы.
13. Дүртенче төрмә корпусы. 1911
14. 1702 елда Нотебургны штурмлаганда һәлак булган Семеновский һәм Преображенский полклары солдатлары кабере

Батыршаның соңгы көне.
К.Нәфиев рәсеме



Батырша.
Т.Хаҗиәхмәтов рәсеме
(Җ.Рәхимовның «Батырша»
китабы тышлыгы)

Моннан бер ай элек, 4 сентябрьдә, фетнәчеләргә каршы көрәштә зур тәҗрибә туплаган чукындырылган татар морзасы бригадир А.И.Тәфкилев чакырып алына. Генерал-майор дәрәҗәсе биреп, аны, качып киткән башкортларны кире кайтарыр өчен, казакъ ханнары янына озаталар. Аның тырышлыгы белән 5545 башкорт туган ягына әйләнеп кайта[187].

Хакимият органнары Батыршаны тотмыйча фетнә тулысынча тар-мар ителде дигән нәтиҗә чыгарып булмаганлыгын яхшы аңлаганнар. Шуңа күрә кинәт юкка чыккан Батырша мулланы табу өчен төрле чаралар күрелә. 2 октябрьдә «тынычлыкны бозучы мулла Габидулла Мәзгытдинне, кушаматы — Батырша, тере килеш тотып биргән өчен 500 тәңкә акча» вәгъдәләнә. Шул ук вакытта Казан губернасында яшәүче йомышлы һәм ясаклы татарларга, Ырынбур губернасындагы башкорт халкына манифест игълан ителә. Биредә Батырша фетнәсе тар-мар ителде, диелә. Шушы манифестта хакимият фетнә башлануның төп сәбәбе — дини кысрыклауны танырга мәҗбүр була. Бу мәгънә түбәндәге сүзләр белән бирелә: «Батырша хатында дини кысрыклау турында әйтелсә дә, Башкортстанда һәм башка урыннарда андый нәрсә бөтенләй юк»[188],— дип ассызыклана.

Кинәт юкка чыккан Батырша мулланы төрле төбәкләрдә бик тырышып эзләсәләр дә, таба алмый аптырыйлар. Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев аның турында нинди хәбәр ишетсә, шуны тиз арада сенатка җиткерергә тырыша. Иң башта Батырша казакъ далаларына качкан, дигән хәбәр алына; аны башкортлар үтергән, имеш, дигән хәбәр килә; Уфа өязенең Уса юлында качып йөри, дигән хәбәр ишетелгәч, 200 кеше, чаңгы киеп, урманнарны айкап чыга, тик таба гына алмыйлар. Бу хәбәрләр берсе дә дөреслеккә туры килми, чөнки ул бөтенләй икенче якларда качып йөргән була.

Азык-төлек эзләп киткән шәкертләре әйләнеп кайтмагач, Батырша Яхъя исемле шәкерте белән төрле төбәкләрдә качып йөриләр. Юлларда тикшерү көчәю сәбәпле, алар Казан өязенә чыгып китә алмыйлар. Кышка кергәч, Бөгелмә якларында, шәкерт чакларында билгеле булган Нәдер вулысында качып яшиләр. Авылдан авылга, өйдән өйгә кереп соранып йөргән ике мосафир үзләрен Габдеррахман мулла шәкертләре итеп күрсәтәләр[189]. Иске Нәдер авылы мәчете идән астында кыш чыгалар. Җәй җиткәндә Батырша шәкертен югалта һәм берүзе туган якларына юл ала.

Батырша туган авылына кайтып җитә алмый, 1756 елның 8 ав-

---

[187] Разные бумаги генерал-майора Тевкелева об Оренбургском крае и киргиз-кайсацких ордах, 1762 год // Временник Имп. Моск. общ. истории и древностей российских.— М., 1852.

[188] Сенатский архив.— Т. 9.— С. 446.

[189] Ислаев Ф.Г. Мулла Батырша и Альметьевский край // Альметьевский регион: Проблемы историко-культурного наследия.— Альметьевск, 1999.— С. 67.

густында Уфадан йөз илле чакрым ераклыктагы Әзекәй дигән йомышлы татарлар авылында (хәзерге Башкортстанның Борай районы) старшина Сөләйман Диваев һәм аның ярдәмчеләре тарафыннан кулга алына. Вахит Имамов, Клара Синицына мәгълүматларына караганда, Батырша мулланы Бөгелмә якларындагы Сугышлы (Иске Нәдер) авылында тоталар[190]. Әлбәттә, бу дөрес фикер түгел.

Батыршаның Әзекәй авылында кулга алынуын Сөләйман Диваев түбәндәгечә хәбәр итә. 1756 елның 8 августында төштән соң старшина янына мишәр хатыны Фәриз Шибанов кызы Йосупова (документта исеме бирелмәгән.— *Ф.И.*) килә һәм түбәндәгеләрне сөйли: кемдер аларның умартасыннан бал урлый, шул ук төнне, кояш чыгар алдыннан, өй тәрәзәсен шакып, Ишназар Йосупов өйдәме, дип сорый. Улым печәндә, дип җавап биргәч, билгесез кеше тәрәзә яныннан китә; бу кеше китеп бераз баргач та, өйләреннән 20 сажин тирәсендә булган мәчеттә ишек шыгырдаганы ишетелә. Бу хәбәрне ишетү белән Сөләйман старшина тикшерү оештыра: өйләрендә булган авыл кешеләрен бергә җыярга, булмаганнарының кайда икәнлеген белергә куша. Иң беренче булып Сөләйман старшина янына Исхак Якупов, Рәсүл Карамышев, азанчы Исмәгыйль Ибраев килеп җитә. Старшина аларга Йосупова йортыннан бал урлану турында хәбәр итә, авылда тентү үткәрергә боера. Мәчет ишеге намаз вакытында түгел, ә мәчеткә кеше килми торган чакта ачылганлыктан, ул азанчы Исмәгыйль Ибраевка мәчетне тикшерергә куша, балны урлаган вур шунда качып ятмый микән, дип әйтә. Мәчеткә керү белән Исмәгыйль Ибраев: «Вур монда!» — дип кычкырып җибәрә; шул ук вакытта мәчетнең тәрәзәсе аша яланаяклы, ярымкафтан, бүрек кигән кеше сикереп чыга һәм каенлыкка таба йөгерә башлый. Сөләйман старшина һәм аның белән бергә булган Исхак Якупов, Рәсүл Карамышев бу кеше артыннан куып китәләр. Таныш булмаган кеше ярымкафтанын һәм бүреген салып ташлап калдыра, бик тиз каенлыкка таба йөгерә. Ул шулкадәр тиз йөгерә ки, аны куып җитәргә мөмкин булмый. Сөләйман старшина, ташлап калдырылган ярымкафтанны һәм бүрекне кулына алганнан соң: «Тизрәк атлар китерегез!» — дип кычкыра башлый. Шул арада Сөләйман старшинаның Даут исемле улы атка атланып чабып килеп тә җитә. Ул чабып килгән атка Рәсүл Карамышев атлана һәм качакны куып китә. Аны ул Әзекәй авылыннан бер чакрым ераклыкта куып җитә. Сөләйман старшина, аның улы Даут, Исмәгыйль Ибраев, Исхак Якупов, Рәсүл Карамышевлар да качак артыннан йөгерүне дәвам итәләр; җәяү йөгерүчеләрне атка атланып Сөләйман старшинаның кече улы Колмөхәммәт куып җитә. Колмөхәммәт атына Сөләйман старшина үзе

---

[190] Имамов В. Запрятанная история татар.— Набережные Челны, 1994.— С. 75; Синицына К.Р. История Татарстана и татарского народа.— Казань, 1995.— Ч. 2.— С. 111.

атланып, качак артыннан чаба башлый. Рәсүл Карамышев куып җиткән кеше аңа пычак белән янап, качып китәргә тырыша.

Бераздан Исхак Якупов, Исмәгыйль Ибраев, Даут йөгереп килә. Качкын тотыла. Ул Батырша Алеев булып чыга. Шул арада бирегә писарь Муксин Габделсәлимов, Әбдүк Дәүләтсаров, Бакый Юнеевләр дә килеп җитәләр. Тотылган Батырша мулланы Сөләйман старшина йортына алып кайталар.

Сөләйман старшина Батыршаны кулга алу турында улы Даут, писарь Муксин белән Уфа кәнселәренә рапорт юллый. Диваев Сөләйман Батыршаны, аяк-кулларын богаулап, махсус сак астында шул ук көнне Уфага үзе алып китә[191].

И.И.Неплюев 12 августта Уфа кәнселәреннән Батыршаны кулга алу турында күптән көтелгән сөенечле хәбәрне ала. Шунда ук Уфага Батыршаны Ырынбурга алып килү турында күрсәтмә белән курьерны озата. Уфадан Ырынбурга гыйсъянчы мулланы капитан җитәкчелегендәге 60 кешелек драгун, 40 кешелек казак отряды саклап алып бара. Батыршаны озатучы гаскәриләргә аны бернинди маҗарасыз һәм яшерен рәвештә кирәкле җиргә илтеп җиткерергә күрсәтмә бирелә. Мондый кискен саклык чаралары юкка гына кулланылмаган, күрәсең, чөнки ул хакимият өчен зур куркынычлык тудырган кеше булган. 23 августның кичендә И.И.Неплюев аның белән очраша, кыйный һәм сорау ала.

Императрица Елизавета Петровна 25 августта, Батыршаны кулга алу турында хәбәр алгач та, аны кичекмәстән яшерен рәвештә Санкт-Петербург шәһәренә китерү һәм яшерен кәнселәргә тапшыру турында карар кабул итә. 1756 елның 16 сентябрендә капитан кенәз Иван Болховский, поручик Левашов 1 унтер-офицер, 1 капрал һәм 36 драгуннан торган көчле сак астында Ырынбур — Самара — Арзамас — Владимир — Мәскәү — Санкт-Петербург маршруты белән Батыршаны озын юлга алып чыгалар. Юлга чыгар алдыннан мулланы киендерәләр: аңарга яңа тун, кафтан, ыштан, бүрек, бияләй, итек бирәләр. Батырша ябык арбада, кулларында корылган мылтык тоткан ике ягындагы ике сакчы күзәтүе астында сәфәргә чыга.

Казакълар арасындагы качаклар: язмыштан узмыш юктыр

Качып килгән фетнәче башкортларны казакълар башта бик яхшы, көтеп алынган кунаклар шикелле каршылыйлар. Бигрәк тә Кече урда Джагалбайлы ыруы старшинасы Серкә батыр качак башкортларны гаиләләре белән казакълар арасына кунак шикелле тарата. Мондый хәлне ишеткән И.И.Неплюев Айчуәк солтан янына капитан Яковлевны җибәрә. Әлбәттә, башкортларның казакълар арасында булуын белү өчен генә түгел. Аның

[191] Витевский В.Н. Күрс. хезм.— 880 б.

башта казакълар арасында булган качакларны чын әсир итәсе, фетнәчеләрне казакъ аксөяк-феодалларыннан талатасы, ә соңыннан качакларны Русиягә кайтарасы килә.

Ырынбур губернаторы И.И.Неплюевның качакларга карата мөнәсәбәте чукынган татар морзасы кенәз Максютов белән җибәрелгән хатта яхшы күрсәтелә. Бу хатта ул казакъларны качып килгән башкортларны таларга, хатыннарын кечкенә балаларыннан аерырга этәрә, ә фетнәдә катнашкан башкортларны тиз арада Русиягә кире кайтаруны таләп итә. Биредә губернаторның фетнәчеләрне кайтару һәм казакълар белән башкортлар арасында низаг чыгару теләге күренә.

Казакълар белән качаклар арасында мөнәсәбәтләр качакларның саны артканнан соң кискенләшә башлый. Шул арада качаклар саны бик тиз арта. Тарихчылар аларның санын 10000 нән алып 50000 кешегә кадәр дип күрсәтәләр[192].

Казакъларның качакларга карата карашын үзгәртү өчен И.И.Неплюев ханнарга, солтаннарга, аксөякләр нәселеннән булган казакъларга төрле бүләкләр, сый-хөрмәт күрсәтә. Нурали ханга елына 600 сум жалованье билгеләнә, казакъларга кыш көне Җаек елгасының эчке ягында мал-туар тотарга рөхсәт ителә.

И.И.Неплюев август урталарында Эрали солтан белән очрашып, качып казакълар арасына килгән башкортларның язмышы, фетнәчеләрне кире Русиягә кайтару хакында сөйләшүләр алып бара. Биредә ул беренче мәртәбә турыдан-туры казакъларга башкортларның хатыннарын, кечкенә сабыйларны кол итеп алырга рөхсәт бирә. Бу хакта И.И.Неплюев сенатка болай дип хәбәр итә: «Жон же и малых их, воров детей, также и пожитки их, что чего при них есть, позволили ему (Эрали султану) и тем, кои при том будут служить, себе в добычь употребить»[193]. Бу турыдан-туры качакларны талауга чакыру иде.

1755 елның август ахырында Ирбайты, Караганла, Камышак елгалары тирәсендә Табын ыруының 1000 тирмә, Джагалбайлы ыруының 500 тирмәсе булган Алчин ыруы казакълары качак башкортларын кабул иткән, ханнарына һәм аксөякләргә башкортларны таларга бирмәгән. Җидеыру ыруына вәхшиләрчә һөҗүм оештыралар. Ике ыру арасында 4 көн рәхимсез сугыш бара: Алчин ыруы казакълары бик күп тирмәләрне ваталар, бала-чагаларны имгәтәләр. Бу сугышта ике яктан 15 кеше һәлак була, 100 кеше яралана. Далада аяныч күренеш пәйда була: анда да, монда да имгәнгән һәм үлгән кешеләр яталар, кайберләрнең күзләре агып чыккан, башлары тишелгән, куллары кылыч белән чабылган, кабыргалары сындырылган. Бу сугышта җиңеп чыккан Алчин ыруы казакълары качак башкорт-

---

[192] Рычков П. Күрс. хезм.— 263 б.; Неплюев И.И. Записки.— С. 155; Витевский В.Н. Күрс. хезм.— 872 б.; Вәлиди Ә. Күрс. хезм.— 165 б.

[193] Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 98 б.

ларның ирләрен 10лап, хатын-кызларын, сабыйларын 15әрләп кол итәләр. Нурали хан калган фетнәче башкортлар белән нәкъ шулай эшләүне туганы Эрали солтан кулына тапшыра[194].

Соңыннанрак Исәт тарханга буйсынган Тамьян ыруына килеп урнашкан башкортлар талана. Тик шуны күрсәтү дә кирәк дип уйлыйбыз: күп кенә казакълар башкорт качакларын талауны, кыерсытуны хупламыйлар, «үзебез үлмичә, сезне беркемгә дә бирмибез!» дигән фикердә калалар.

Кызларын һәм хатыннарын казакъларның көчләве турында хәбәрләр алган башкортлар, отрядларга тупланып, казакъ авылларына хатын-кызларын, туган-тумачаларын коллыктан, көчләүдән коткару өчен ярсулы һөҗүмнәр оештыралар. Шул рәвешчә, ике халык бер-берсен үтерү, талау, бер-берсеннән үч алу юлына баса.

Шулай итеп, Ырынбур губернаторы И.И.Неплюевның «башкортлар һәм казакълар арасында үзара сугышлар, эчке бозыклык Русия дәүләтенә яманлык түгел, ә файда китерә торган гамәл, чөнки мондый хәл Русиянең көчле һәм куркыныч дошманы була ала торган ике халык арасында бердәмлекне юкка чыгара»[195] дигән теләге тормышка ашырыла.

Батыршаның аркадашлары

Гыйсъянчы мулла артыннан фетнәдә катнашулары өчен кулга алынган 11 кеше — көрәштәшләре һәм шәкертләре — Санкт-Петербург шәһәренә, яшерен кәнсәләргә, шул ук маршрут белән озатыла. Гәйнә вулысында фетнәдә актив катнашучылар 15 кеше кулга алынган булса, аларның 4се сорау алганда төрмәдә вафат була. Сорау алганда тикшерүчеләрнең протоколларга «камчы белән кыйналды», «каты кыйналды» дигән сүзләр еш теркәлгән. Кече яшьтәге шәкертләргә караганда фетнәдә катнашучыларның бигрәк тә олыракларын, оештыручы булганнарын каты җәзалыйлар. Тикшерү барган вакытта үлүчеләр арасында шәкертләр булмый. Бу факт нигезендә шәкертләрне бик нык җәберләмәгәннәр, кыйнамаганнар дигән фикергә киләбез.

Санкт-Петербургка озатылган төркемдә күпме кеше булганлыгы хәзергә төгәл билгеле түгел. В.Н.Витевский мәгълүматларына караганда, 15 кулга алынган кеше озатыла. Шушы ук саннарны башка тарихчылар да кабатлый[196]. Тик бу дөрес түгел.

Чыннан да, Гәйнә вулысында чуалышларны бастырганда, 15 кеше кулга алына. Төрмәдә тикшерү барганда, Максут Гайсин, Көчекбай Имангулов, Нури Баскунов һәм Чурагол Миңлебаев

---

194 Шунда ук.— 98 б.

195 Витевский В.Н. Курс. хезм.— 874—875 б.

196 Алишев С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу.— С. 50; Синицына К.Р. Курс. хезм.— 111 б.

вафат булалар. Болар — Гәйнә вулысында чуалышларны оештырган кешеләр, фетнәнең җитәкчеләре. Төрмәдә утыручылар арасында фетнә оештыручылардан Исхак Морзалиев кына исән кала. Ул сорау алганда тикшерүчеләргә төгәл һәм тулы җавап бирә. Сорау алу протоколында Исхак Морзалиев җаваплары күләме һәм эчтәлеге белән башкаларныкыннан аерылып тора. Беренче мәртәбә биргән җавапны икенчесендә алынган җавап белән чагыштырганда аерма бик күп. Ул шулай итеп гомерен саклап кала. Вафат булучылар арасында Батыршаның шәкертләре юк. 11 кешедән торган арестантлар төркемен каравыллап бару өчен капитан Леонтий Львов җитәкчелегендә 24 драгун һәм 12 казакъ беркетелә[197]. Капитанга арестантлар Рогервикка озатыла, дигән инструкция бирелә; шул ук вакытта аларны Санкт-Петербургка, яшерен кәнселәргә тапшыру турында яшерен указ кабул ителә.

Кулга алынган 15 кеше арасында мишәрләр, башкортлар, ясаклы татарлар да була, без аларның тулы исемлеген китерәбез. Мәскәү архивында эшләү безгә фетнәчеләрнең кайсы төбәктән икәнлеген дә ачыкларга мөмкинлек бирде.

— Ырыскол Исланов — Уфа өязе Себер юлы Мөрәсим авылы йомышлы татары, хәзер бу авыл Башкортстан Республикасы Караидел районында исәпләнә;

— Исмәгыйль Апкин — Казан өязе Алат юлы Куныр авылы ясаклы татары, хәзер Татарстан Республикасы Балтач районы;

— Мирәхмәт Әхмәтов (Әймәтев дип тә укып була) — Уфа өязе Себер юлы Күл авылы (урысча Кулевой дип язылган) йомышлы татары;

— Ибрай Тимергозин — Уфа өязе(?) Себер юлы Өреш авылы йомышлы татары;

— Әхмәр Күчәков — Исәт провинциясе Мөслим авылы йомышлы татары, хәзер Чиләбе өлкәсе Кунашак районы;

— Исхак Морзалиев — Уфа өязе Уса юлы Гәйнә вулысы Төңгәк авылы башкорты;

— Мостафа Хәсәнов — Исәт провинциясе Олыкош авылы(?) (Чүлмәкәй авылы(?)) (Чиләбе өлкәсе Кунашак районы) йомышлы татары, Батырша хатынының энесе;

— Акчура Ягутеев — Уфа өязе Уса юлы Гәйнә вулысы Башап авылы ясаклы татары, хәзер Пермь өлкәсе Барда районы;

— Сәфәр Ягъфәров — Исәт провинциясе Әй вулысы Исмәгыйль авылы башкорты;

— Дәүләтбай Хуҗагулов — Көңгер өязе Ирәнбаш вулысы Йанапай авылы ясаклы татары, хәзер Пермь өлкәсе Октябрь районы;

— Мөслим Ибраһимов — Уфа өязе Казан юлы Төреш (Тяреш(?)) авылы йомышлы татары;

---

[197] Витевский В.Н. Курс. хезм.— 882—883 б.

— Максут Гайсин — Уфа өязе Себер юлы Мөрәсим авылы башкорты;

— Нури Баскунов — Уфа өязе Уса юлы Гәйнә вулысы Төңгәк авылы башкорты, хәзер Пермь өлкәсе Барда районы;

— Көчекбай Имангулов — Уфа өязе Уса юлы Гәйнә вулысы Башап авылы башкорты, хәзер Пермь өлкәсе Барда районы;

— Чурагол Миңлебаев — Уфа өязе Уса юлы Гәйнә вулысы башкорты[198].

Биредә китерелгән исемлек В.Н.Витевский хезмәтендә китерелгән исемлектән шактый аерыла.

Татарстан Республикасы Милли архивында Казан өязе буенча 1762 елны халык санын алган материаллар сакланып калган. Аларны җентекләп караганнан соң, Исмәгыйль Апкинның әтисен-әнисен, туганнарын һәм яшен ачыкларга мөмкинлек булды. Восстаниене хәзерләүдә иң актив катнашкан шәкертләрнең берсе булган Исмәгыйльгә ул вакытта 20 яшь булган. Архивта табылган документка караганда, Исмәгыйль Апкин 1756 елда Рогервикка озатылган. Әтисе Әпкә Ильмяков шул ук елны вафат булган, сәбәбе күрсәтелмәсә дә, без, башка чыганаклар файдаланып, аның Казан төрмәсендә үлүен ачыкладык. Димәк, Казан якларында да восстаниедә катнашучыларны эзәрлекләгәннәр булып чыга. Исмәгыйльнең Искәндәр һәм Рахманкол исемле ир туганнары, Сәгыйдә һәм Гөлзәбирә исемле кыз туганнары да була. Аларны Исмәгыйль өчен эзәрлекләмәгәннәр бугай[199].

Дәүләтбай Хуҗагуловның Көңгер өязеннән икәнлеге күптәннән билгеле булса да, вулысы һәм авылы төгәл билгеле түгел иде. Архив материалларын өйрәнү бу сорауларга ачыклык кертергә мөмкинлек бирде. Ул Югары Ирән вулысы Йанапай авылы кешесе булып чыкты.

Батырша мулланың даирәсен милләтләре һәм нинди катлаудан булуларыннан чыгып тикшергәндә, кайда яшәвенә, милләте һәм сословиесе кем булуга карамастан, бөтен мөселманнарның да дини сәясәткә, христианлаштыруга, салымнар артуга каршы булганлыгын күрергә мөмкин. Ә мишәр-татар вәкиле Русия империализмының колониаль сәясәтенә каршы ислам динен сакларга җиһадка өндәгән күтәрелешнең идеологы һәм оештыручысы була. Батырша восстаниесен канга батырган И.И.Неплюев соңрак, тарихи дөреслеккә хилафлык итеп: «Типтәрләр, мишәрләр зур ачу белән башкортларга каршы күтәрелделәр»,— дип язды. Урыс колониализмының күренекле вәкилләреннән берсе, аңлы рәвештә ялганлау юлына басып, халыкларны бер-берсе белән талаштырса, аның шушы фикерләре хәтта бүгенгә кәндә дә тарихи җирлекне бозу өчен төп дәлил итеп кулланыла.

---

[198] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 1, л. 162—162 об.

[199] Ислаев Ф.Г. Исмагил Апкин — соратник муллы Батырши // Гасырлар авазы— Эхо веков.— 1999.— № 1—2.— С. 273—275.

В.Имамовның Батырша турындагы хезмәтен тәнкыйтьләп, тарихчы И.Г.Акманов 15 кулга алынган кешенең 14е Батыршаның шәкертләре, дип яза. Без, сакланган чыганакларны тикшергәннән соң, кулга алынган кешеләр арасында 8 кешене генә шәкертләр рәтенә кертергә мөмкин, дигән фикердә калабыз. Менә алар: Мирәхмәт Әхмәтов, Ибрай Тимергозин, Әхмәт Күчәков, Исхак Морзалиев, Мостафа Хәсәнов, Сәфәр Ягъфәров, Дәүләтбай Хуҗагулов, Мөслим Ибраһимов. Кулга алынган башка фетнәчеләр — төрле авыллардан ислам дине өчен көрәшкә күтәрелгән мөселманнар.

Императрицага хат

Санкт-Петербургка барган юлда 1756 елның 1 октябрендә, Муром шәһәренә җитәрәк, Батырша мулла, кулындагы һәм аягындагы богауларны ачып, аны саклап арбада рәттән утырып йокымсырап барган капралны һәм драгунны сугып төшерә һәм урманга таба йөгерә башлый. Тик йөгереп бик ерак китә алмый, капрал һәм драгуннар аны куып җитәләр. Муром шәһәренә җитү белән Батыршаның кулына һәм аягына тагын богау салалар.

Мәскәүгә килгәч тә Батырша яшерен кәнселәр төрмәсенә ябыла. Төрле китапларда Батырша мулла авырып, шактый вакытка Мәскәүдә туктала, дигән мәгълүматлар бар. Ул чыннан да шулай була. Тик аның сәбәбе генә ачыкланмый, аңлатылмый. Безнеңчә, Батырша мулланы юлда качканнан соң тотып алгач та сакчылар бик каты кыйнаганнар шикелле. Мөгаен, менә шушы чамадан тыш кыйнау һәм аның нәтиҗәләре Батыршаны Мәскәүдә шактый тукталып торырга да мәҗбүр итә дә инде. Анда ул ашаудан да баш тарта, хәзергечә әйтсәк, ачлык игълан итә. Батырша мулла авыру булуга карамастан, аннан сорау алалар, сорау алганда Батыршаның җавапларын чукынган татар морзасы Илья Муратов тәрҗемә итә. Тикшерүче аның кем, ничә яшьтә, кайда туган, нинди милләттән икәнлеген беләсе килә. Бу сорауларга Батыршаның җавабы түбәндәгечә була: аңа 30 яшьтән артык, күпме икәнен төгәл әйтә алмый; тумышы буенча мишәр таифәсеннән, Уфа провинциясе Карыш авылыннан. Ул шушы авылда хатыны һәм балалары белән яши; дини яктан укымышлы булганлыктан, анда яшәгән халыклар теләге белән мулла итеп сайлана, дини җитәкче булганлыктан, халык аны тыңлый[200].

Восстание оештыру, анда катнашучылар турында сорауларга ул җавап бирми, фетнә серләрен тәфсилле итеп, катгый рәвештә императрицадан башка беркемгә дә берни сөйләмәячәген белдерә. Яшерен кәнселәрнең Мәскәү кантуры җитәкчесе Михаил Хрущев сүзләренә караганда, тәрҗемәче аша йомшак мөгамәлә дә ярдәм итми. Шул вакытта ул ашаудан баш тарта.

---

[200] Письмо Батырши...— С. 116.

1756 елның 24 октябрендә Батырша мулланы күзәтеп торган табиб аның терелеп килгәнен, тик бите генә шешенеп торганын, кирәк булса, юлга җылы кием киеп чыгарга мөмкинлеген күрсәтә.

Батыршаны патшабикәгә язма мәгълүматлар бирергә күндерәләр. Батырша императрица белән очрашу теләгеннән кире чикми, үз сүзендә катгый торуны дәвам итә. 28 октябрьдә яшерен кәнсеЛәр Батырша теләген императрицага җиткерә; Батырша авыру булганлыктан, императрица аны кабул итә алмый. Бәлки, шушы сәбәпне исәпкә алып, Батырша патшабикәгә хат язарга ризалык биргәндер. Фетнә хакында бөтен мәгълүматларны Батырша патшабикә исеменә хат итеп язып, аны үзенең тамгасын (мөһерен) салып тапшырырга тиеш була.

3 ноябрьдә шушы хәбәрне Михаил Хрущев аша Батыршага җиткерәләр. Шунда ук Михаил Хрущев «бөтен язган сүзләрнең патшабикәгә җиткереләчәге» турында Батыршага тагын кабатлый.

Батырша бу тәкъдим белән килешергә мәҗбүр була. Озак уйланулар шундый нәтиҗәгә китерә: һаман да патшабикә белән күрешеп сөйләшүне таләп итеп торуның мәгънәсе юк, чөнки, төрле сәбәп табып, аны барыбер патшабикә белән очраштырмаячаклар. Мондый очракта, хат та язмаса, мулла мөселманнарның Русия империясендәге халәте турында бер хәбәр дә бирә алмас иде. Тик ул язган хатын бер кешегә дә укытмауларын, ә аның мөһере белән бары тик императрицага турыдан-туры тапшыруларын үтенеп сорый. Михаил Хрущевтан ул элекке сорауларны, хәтердә тоту өчен, тәрҗемәченең татарча язып, үзенә бирүен үтенә. Тылмач Илья Муратов Батыршага бирелгән сорауларны шунда ук татарчага тәрҗемә итеп тапшыра. Сорауларны укыганнан соң ул тулы канәгатьлек белдерә һәм хатны иртәгесе көнне яза башларга сүз бирә. Батыршаның патшабикәгә язган хатын урысчага тәрҗемә итү Илья Муратовка тапшырыла[201].

4 ноябрьдә иртә белән Михаил Хрущев тылмач Илья Муратов аша Батырша белән сөйләшүне дәвам итәләр. Михаил Хрущев Батыршага кабат бүгенге көннән хат яза башларга кирәклеген әйтә; Батырша үзе язган хатны бер кеше дә ачып укымаска, патшабикә Елизавета Петровна үзе генә укыячагына ант иттерү теләген яңадан кабатлый. Михаил Хрущев Батыршаны, нәкъ шулай булачак, дип тынычландыра.

Батыршаның язган хаты патшабикәгә барып җитү-җитмәү турында кайгыртуын аңлап та була. Шушы мәсьәләне күтәрү, безнеңчә, Батыршаның хат язарга килешүе турында һаман уйлануы, шикләнүе турында сөйли. Хат язу өчен Батыршага кара, 7 татарча эшләнгән каурый каләм, бау белән бәйләнгән ак кәгазь, моңа өстәп, Батыршаның соравы буенча, каралама язу өчен өстәмә кәгазь тапшырыла.

Каравыл начальнигы кенәз Болховский Батыршаның хат язу-

---

[201] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 1, л. 154.

ын һәрдаим күзәтеп торырга тиеш була. Язылган кәгазь юкка чыгарга, ертылырга тиеш түгел. Хат язу турында кенәз яшерен кәнселәргә көн саен хәбәр итеп торырга тиеш була. Архивта сакланган кенәзнең язмалары Батыршаның хат өстендә эшләвен бик яхшы сурәтләүче документ булып тора.

1756 елның 4 — 21 ноябрендә Батырша көн саен императрица исеменә хат яза; башта каралама языла, аннары ул чиста кәгазьгә күчерелә. Гайса Хөсәенов мәгълүматларына караганда, Батырша 4 ноябрьдә — 1 бит; 5 ноябрьдә — 1 бит, ярты битне чиста кәгазьгә күчерә; 7—10 ноябрьдә — 2 бит каралама, 5 бит чиста; 11 ноябрьдә — 1,5 бит чиста; 12 —13 ноябрьдә — 2 бит чиста; 14 ноябрьдә — яртышар бит каралама һәм чиста; 15 —17 ноябрьдә — 3 бит; 18 — 20 ноябрьдә берәр бит яза[202].

Без караган чыганаклар буенча Батырша хат язуны 7 ноябрьдә башлый; 7—10 ноябрьләрдә барысы бер бит ярым гына языла; әкренләп язу күләме арта: 12 ноябрьдә — 4 бит, 15 ноябрьдә шулай ук 4 бит. Күренгәнчә, хат язу темпы бик зурдан булмый — көненә ярты биттән алып 2 бит тирәсе, әкренләп ул сан 4кә җитә[203]. Хат язуның темпы тиз булмауны патшабикәгә хат хәзерләүнең катлаулылыгы, һәрбер сүзне күп мәртәбә уйлап, күп мәртәбә үлчәп һәм чагыштырып язу кирәклегеннән аңлатып булыр иде. Батыршаның язу тәҗрибәсе булуга карамастан, патшабикә галиҗәнапларына баш күтәрүнең чын сәбәпләрен төрле яктан күрсәтү — бөтенләй икенче мәсьәлә.

Бигрәк тә баштагы хат юллары Батыршага авыр бирелә: беренче язылган бик күп сүзләрне, хәтта җөмләне дә күп мәртәбә язарга, сызып, яңадан язарга туры килә. Ахыргы вариантта түбәндәге сүзләр калдырыла: «Гыйззәтле, дәүләтле падишаһымыз газим хәзрәтләренә кем тәхте вилайәтендәдур рус мәмләкәте вә һәм гайреләр, вә һәм гайреләр, вә һәм гайреләр»[204].

Ике атнадан артык вакыт эчендә Мәскәү төрмәсендә Батырша патшабикә исеменә хатын тәмамлый. Тарихта ул «Гарызнамә» исеме астында билгеле. Әдәбият галиме һәм тарихчы Мәсгуд абый Гайнетдин фикеренчә, «Гарызнамә» — XVIII йөз татар әдәбиятының иң кыйммәтле энҗеләреннән берсе. Халык тормышын көчле хәрәкәткә китергән, чор тарихын иңләгән каһарманлыклары булмастан, шул «Гарызнамә» авторы буларак кына танылса да, Батырша тарихыбызның якты, онытылмас шәхесләреннән булыр иде. XVIII йөз уртасы караңгылыгында ул әдәбиятыбызда кайнар реалистик публицистика, күренекле вакыйгалар турында тарихи-әдәби очерк, сәяси-полемик көрәш әсәре мәйданга китереп калдыра алган. Батыршаның бу әсәре татар иҗтимагый фикерен, урта гасырлыктан бердән йолкып алып, яңа,

---

202 Письмо Батырши...— С. 117.
203 РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч.1, л. 218—223.
204 Письмо Батырши...— С. 26.

мәгърифәтчелек киңлекләренә чыгара. Җанлы тормыш хәлләрен, көнкүреш күренешләрен һәм вакыйгаларын, дөньяви яшәеш кайнарлыкларын сүз сәнгатебез мәйданына башлап Батырша алып керә... «Гарызнамә» чал тарихыбызның хәзерге яңаруга кискен борылыш чатында иң якты маяк булып тора[205].

Хат башында Батырша үзе белән таныштыра; төрле төбәкләрдә белем алуын, Гәйнә вулысында, Исәт провинциясендә, Карыш авылында имам булып Аллага хезмәт итүен, мәктәп-мәдрәсәдә балалар тәрбияләвен күрсәтеп китә.

Мөселманнарның ризасызлыгына Батырша махсус тукталa. Ул бигрәк тә «диндәшләремезне, ягъни Казан, вә Оренбур, вә Тубыл губернасындагы мөхәммәди мөэминнәрне рус җәмгыятенең архәрейлары, яки поплары, яки үзгәләре тәгълим вә тәһдидләр илә, вә хәйлә вә тәхәввефләр илә ничекдур кем мөмкин әүлә анларны җәбран вә икраһан ислам динендән чыгаруб, рус диненә кейуруб, анларны ризалыкы вә деләмәке һәйәтенчә гарызнамәләр язуб, тамгаларны салдылар»[206].

«Вә дәхи ул ислам динендән чыкарылынларның ясакларын вә үзгә хезмәтләрен калган мөселманнарның өстенә салдылар. Ул мөселманнарны үзләренең динләрендә сабит булуб торган өчен анларны хур күреп, гаһед кадимдә өстләрүнә лазем улмаган йөкләрне йөкләделәр;

Аллаһының хәзинәсе булган күлләрдән тоз алуны бетереп, аны сатып алырга көчләделәр;

Түрәләрнең хисапсыз гади халыкны изүе, төрле сәбәпләр табып күп кечкенә мәсьәләләр айлар, еллар буе чишелми; вулыс старшиналары эчеп исерәләр, кылыч белән кешеләрне кисәләр, кулларын чабалар;

Йомышлы урысларның чамадан тыш «җәфалары», «кыйнамак, сукмак вә алум алмак вә угырламак, кешеләрне үтермәк»[207].

Батырша фикеренчә, шушы сәбәпләр аркасында Ногай, Себер, Уса юллары башкортлары яшерен рәвештә корал әзерли башлыйлар. Халыкның тормышын, тормышта булган авырлыкларга мөнәсәбәтен белер өчен Батырша Башкортстанның төрле төбәкләрендә була, анда яшәгән төрле халыклар белән аралаша. Исәт провинциясендә Мөслим старшина авылларындагы йомышлы татарлары, Салжугут вулысы башкортлары, Уса һәм Казан юллары халыклары арасында сөйләшкәннән соң, «кяферләрнең такать тоткысыз җәфалары сәбәбендә кяферләрне мәнегъ идәргә вә анлардан үч вә дад алырга» хәзер икәнлеге ачыклана. Моннан соң да Батырша шәкертләр, таныш-белешләр аша төрле яктагы халыкның рухын тикшереп тора.

Батырша «Тәзкир вә тәхризнамә» яисә «Үгетләмәк вә кыздыр-

---

[205] Гайнетдин М. Батырша // Иман нуры.— 1997.— Июль.— 30—31 б.
[206] Письмо Батырши...— С. 27.
[207] Шунда ук.— 27—30 б.

мак» — «Өндәмә» язу, аны төрле төбәкләрдә тарату турында да аз булса да белешмәләр биреп китә.

Урыс дәүләтенең колониаль сәясәтен тормышка ашыручы старшиналарга булган мөнәсәбәтен Батырша үз авылы старшинасы «заһирдә дуст булып, батыйда дошманлыкымыз» Яныш Абдуллин аша күрсәтә. Аның кимчелекләре: «бервакыт тәһарәтләнеп, Ходайга сәҗдә кылмышы юкдур», «акча бирмәгәннәрне пахутка җибәрәдер», «угрыдан мал алуб, аның өстенә хөкем йөретми», «дәгъвачыларны гаепсезләрдән гаеп табып суктырадыр», хатыннарны ирексездән зина кыла, гаепсезләргә ялгыш һәм «батил» хөкем чыгара. Мөселманнарның җәфа чигүендә Батырша старшиналарны гаепли. Старшиналарга каршы мондый фикер фетнәчеләр арасында шактый таралган фикер булганга күрәдер, фетнәчеләр берничә старшинаны үтерәләр.

Батырша хатында шактый урынны восстание хәзерләүгә багышлый. Биредә шәкертләрнең «Өндәмә»не төрле төбәкләрдә таратуы, Ырынбурга бару, сөйләшүләр алып бару, гәйнәлеләр белән аралашу һ.б. языла.

Ахырда гаиләсе һәм шәкертләре белән качып китүе, бер ел буе күргән авырлыклары, 1756 елның август аенда Сөләйман старшинага бирелгәнлеге, Уфа, Ырынбур аша Мәскәүгә кадәр юлда булган вакыйгалар хакында мәгълүматлар биреп китә.

Хат императрицага яңадан мөрәҗәгать белән тәмамлана[208].

Хат, язылып тәмамлангач, караламалар белән бергә махсус пакетка салына. Батырша пакетка үз мөһерен куя. Бу хат белән патшабикә Елизавета Петровна танышканмы, әллә ул тикшерүчеләр өчен төп чыганак булганмы, монысын төгәл әйтеп булмый. Һәрхәлдә, әлеге хат яшерен кәнсәләр фондында, Батыршаның җинаятен тикшерү материаллары арасында бүгенге көнгә кадәр сакланган.

Хат язылып бетүгә, тикшерүне дәвам итәр өчен, 30 ноябрьдә Батырша мулланы Мәскәүдән Санкт-Петербургка озаталар.

Шул ук елның 12 декабрендә Батыршаның хатыны Зөлхәбирәне балалары белән яшерен кәнсәләргә, ягъни Санкт-Петербургка озатырга, дигән карар кабул ителә һәм 20 декабрьдә ул кызлары белән башкалага озатыла. Димәк, бу вакытта инде Батырша мулланың олы улы Таҗетдин үлгән булып чыга, чөнки чыганакларда аның турында бернинди дә белешмә юк.

Санкт-Петербургтагы тикшерү

Батыршаның көрәштәшләреннән торган 11 кешелек төркем Санкт-Петербургка ноябрь башында килеп җитә. Яшерен кәнсәләр җитәкчесе генерал-аншеф Александр Иванович Шува-

208 Письмо Батырши...— С. 26–70.

лов 1756 елның 8 ноябрендә «Мәскәү драгун полкы капитаны Леонтий Львов каравыллап алып килгән агач богаулы тоткыннарны (колодникларны) яшерен кәнселәрдә урнаштырырга, ә каравыл вазифасын шул ук капитанга тапшырырга» дигән приказ чыгара[209].

Ул вакытта арестантларны урнаштырган тикшерү төрмәсе дә, яшерен кәнселәр дә Нева елгасының уң ягындагы утрауда төзелгән Петропавел крепостенда урнашкан була. Санкт-Петербургта булып киткән чит ил кешеләре Петропавел крепостен французларның Бастилиясе белән тиңлиләр. Калын һәм биек таш стена белән чолгап алынган, бер яктан елга, икенче яктан ермак (канал) җирдән килү өчен уңайсыз бу крепость арестантлар кача алмый торган төрмәгә әверелә.

Безгә яшерен кәнселәр, төрмә урнашкан биналарның ул вакытта кайда урнашкан булганлыгы төгәл билгеле түгел. Төрмә бинасы бер яисә ике этажлы, агачтан яисә балчыктан ясалган бинада урнаштырыла. Арестантларны сорау алганда җәзалау өчен махсус камера җиһазландырыла. Анда арестантны асып тору өчен җайланма, түшәмдә аркылы борыс, стенага кагып куелган ыргак була.

Арестантларны камераларда көне-төне 3 солдат каравыллаган. Каравылдагы солдатлар арестантлар белән бергә торганнар. Дежурда булмаган солдатлар крепостьтан чыгып шәһәрдә үз эшләре белән шөгыльләнә алганнар. Камераларда һәрвакыт туктаусыз шәм янган. Батыршаның көрәштәшләрен каравыллау Преображенский лейб-гвардия полкы солдатларына һәм подпоручик Петр Насоновка тапшырыла.

Яшерен кәнселәрнең начальнигы итеп 1747 елда императрицаның иң якын, ышанычлы вәкилләренең берсе граф Александр Иванович Шувалов билгеләнә. Тирә-яктагы кешеләр аның бер як бит мускуллары кинәт тартыша башлаганда бик курка торган булалар. «Александр Шувалов үзе начар кеше булганлыктан түгел, ә Яшерен кәнселәрия (Тайная канцелярия) дип аталган инквизиция суды начальнигы булып үтәгән дәүләт вазифасы белән бөтен сарай даирәләрен, башкала һәм бөтен империя халкын куркыта иде. Ул, вазифасын үтәгәндә, шатлык, ачу, курку шикелле дулкынлану хисләрен кичергәндә, һәрвакытта күзеннән алып иягенә кадәр бөтен уң як бите тартыша башлый иде»,— дип тасфирлый Әби патша Екатерина-сания А.И.Шуваловны[210].

Яшерен кәнселәр җитәкчесе гаепләнүчеләрдән сорау алуларда үзе катнаша яисә тикшерүне алып баруны күзәтеп тора. Башкортстанның төрле төбәкләрендә патша властена каршы баш күтәрүне оештырган Батыршадан Александр Шувалов үзе сорау алган булырга тиеш дигән фикердә калабыз. Моның та-

---

[209] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 4, л. 214.
[210] Екатерина II. Записки императрицы.— М., 1990.— С. 356.

гын бер сәбәбе бар: чөнки ул, дәүләт дошманнары белән көрәшүдән тыш, коммерция белән дә шөгыльләнә. Ногай юлындагы восстание вакытында Шуваловлар заводы зыян күрә.

Гыйсъянчы мулланың сөйләшүен урысчага тәрҗемә итү өчен, яшерен кәнсәләргә төрек, татар телләрен белгән тылмач Александр Турчанинов чакырыла[211]. Аны сорау алганда белгән мәгълүматлар турында кешегә сөйләргә ярамаганлыгы турында кисәтеп куялар. Төрмәдә тикшерү дәвам итә.

Тикшерүне оста, мәрхәмәтсез, зирәк тикшерүче-психолог Степан Иванович Шешковский алып бара. Аның ата-анасы Гродно шәһәрендә яшәгән поляклардан була. Яшерен кәнсәләрдә 16 яшьтән, 1743 елда ук эшли башлый. Кушкан барлык эшне җентекләп үтәве, иң буталчык җинаятьләрне уңышлы тикшереп бетерүгә белән танылa бу шәхес. Кыска, төгәл һәм дөрес итеп протокол, җитәкчеләр өчен «экстрактлар» язуда аеруча уңышка ирешә. Яшерен кәнсәләр җитәкчесе граф Александр Шувалов белән дә ул яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыра. Шувалов аны архивариус, 1754 елда протоколист итеп билгели. 1757 елда А.Шувалов императрицага доклады нәтиҗәсендә яшерен кәнсәләр секретаре дәрәҗәсен ала. Бу эшкә билгеләүне иң кирәкле хезмәтләрдә кыю, үрнәк алырлык, мактаулы, намуслы эшләре өчен бүләк дип карарга кирәк. Бу вакыт Батырша җинаятен тикшерүне тәмамлау вакытына туры килгәнлектән, С.И.Шешковскийның шундый дәрәҗәгә җитүдә казанышлары искә алынган дип уйларга урын бар.

Яшерен кәнсәләр хезмәткәрләре арасында С.И.Шешковский иң авыр, үз сүзендә нык торган арестантларны да сөйләштерә, кирәкле мәгълүматларны таба белгән иң зур, алыштыргысыз тикшерүче була. Кемне кайчан тәмле сүз белән ышандырырга, кайчан димләп күндерергә, кайчан куркытырга кирәк икәнен ул яхшы белгән һәм нәтиҗәле файдаланган. Арестантларны, сорау алганда, үзе сыек чыбык, камчы белән искиткеч осталык белән кыйнаган. Кечкенә буйлы, кулын һәрчак кесәләренә тыккан чирләшкә гәүдәле бу кеше арестантларда гына түгел, аны кем икәнлеген белмәгән кешедә дә бик нык курку хисе уята торган була.

Данлыклы урыс язучысы, азатлык өчен көрәштә шөһрәт казанган Радищев, аны кулга алырга С.И.Шешковский килгәнен ишеткәч, аңын югалтып егыла. Бу кеше заманасы өчен һәрбер кеше белән бөтен нәрсә эшләргә хокуклы дәүләт символына әверелә. Менә шундый кеше белән очрашырга, аның сорауларына җавап бирергә тиеш була Батырша. Кызганыч, без әле Шешковский алып барган тикшерү протоколлары белән таныша алмадык.

Батырша мулла 1757 елның яз айларында христиан дине хакында гәпләшү өчен православие дине әһелен күрергә теләвен белдерә: янәсе, православие кануннарының ислам тәгълиматларыннан өстен икәнлегенә инанса, чукыначак һәм христиан

---

[211] РГАДА.— Ф. 7, оп 1, д. 1781, ч. 4, л.288.

булып үләчәк[212]. Ул чыннан да православие дине өстенлекләрен белергә теләгәнме, әллә хөкем чыгару көнен бераз ерагайтырга уйлаганмы — хәзер асыл нияте ни булганын әйтүе кыен. Һәрхәлдә, ул хөкем ителгән җинаятьчеләрнең чукынып җәзадан котыла алганлыгын яхшы күз алдына китерә алган булырга тиеш. Тик аның православие рухание белән бәхәсе җәзадан котылу өчен корылган бәхәс дип уйлый алмыйбыз. Батырша мулланың бу үтенече канәгатьләндерелә һәм аңарга 1757 елның 24 мартында Петропавел соборы рухание Итеро Лепицкий белән сөйләшү мөмкинлеге бирелә. Аларның сөйләшүен тылмач Александр Турчанинов тәрҗемә итә. Бу сөйләшүдән соң Батырша мулла православие руханиеның үзе янына тагын килүен үтенә, аның аша христиан динен тирәнтен өйрәнү теләген белдерә. Мулла каравылда торган унтер-офицер, капрал белән солдатларның үз диннәрен тотулары, дулкынланып дога кылуларына игътибар итә.

Батырша бу очрашуда императрица белән очрашу турында мәсьәләне яңадан күтәрә. Ул попка «мөселманнарның күтәрә алмаслык рәнҗү хисен, бигрәк тә ислам диненнән христиан диненә көчләп чукындыру һәм хатта язылган кимсетүләр турында патшабикәгә үзем җиткерәсе килә» дип әйтә.

Очрашуның ахырында Батырша православие руханиеның кабат килүен үтенә. Христиан дине ислам диненнән өстен икәнлегенә төшенсә, ул, ислам динен калдырып, православие динен кабул итеп үләрмен, дип әйтә[213].

Кызганыч ки, чыганаклар аша Батырша мулланың православие рухание белән тагын очрашып сөйләшүе турында хәзергә ныклап әйтеп булмый. Тик шунысы бәхәссез: танылган ислам тәгълиматлары белгече, оста моназарачы булган Батыршаны Итеро атакай христиан диненең өстенлегенә ышандыра алмаган, күрәсең. Очрашу-очрашмауны тикшерүчеләр хәл иткәнлектән, икенче очрашу булмагандыр, дип әйтергә дә мөмкин.

Тикшерү бик җентекләп алып барыла. Арестантлардан алынган мәгълүматларны чагыштырып, бер үк эпизод буенча берничә мәртәбә сорау алалар. Болар барысы да җинаятьне тулысынча ачу, гаеплеләрне фаш итү өчен эшләнә. Батыршаны һәм аның көрәштәшләрен махсус төзелгән сораулык ярдәмендә тикшерәләр. Ул сораулар арестантларның гаебен табу, җинаятьчене фаш итү, тәүбә кылу, хаталарны тану, җинаятьне бөтен вагытөяге белән сөйләп бирү, аның максатын, катнашучылары турында тулы мәгълүмат җыюдан чыгып төзелә.

Батыршаның җинаять эшен тикшерү Петропавел крепосте төрмәсендә тагын ярты ел тирәсе дәвам итә. 1757 елның уртасында Батырша яла ягулы хат язуда, фетнә оештыруда гаепле дип танылa, камчы белән суктырыла, тимер кыскыч белән борын

[212] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 4, л. 300.
[213] РГАДА.— Ф. 7, оп. 1, д. 1781, ч. 1, л. 297—300 об.

тишеге ертыла һәм гомеренең ахырына кадәр зинданга ябылырга хөкем ителә[214].

Хөкем чыгару датасы хәзергә кадәр төгәл билгеләнмәгән. И.Г.Акманов мәгълүматларына караганда, приговор 1758 елның декабрь аенда гына чыгарылган[215]. Бу фикер белән килешеп булмый, чөнки фетнә буенча тикшерүне туктату турында карар 1757 елда чыга. Шушы вакыттан чуалышлар тәмамланды дип исәпләнә[216].

Батыршага, бәлки, үлем җәзасы чыгарылган булгандыр. Ул замандагы тәртип буенча патшабикә Елизавета Петровна үлем җәзасын камчы белән кыйнау, борынны ерту, төрмәгә утырту белән алмаштыра. Батыршаның көрәштәшләренә нинди хөкем карары чыгарылуы хәзергә билгесез. Безнеңчә, аларның барысын да, яисә өлешчә, Рогервик каторжан төрмәсенә утыртканнардыр.

Приговорда камчы белән ничә мәртәбә сугу турында мәгълүматлар сакланмаган. Мондый очракта Батырша җәзалаучы кулында кала. Камчы белән күпме сугу турында приговорда язылмаса да, якынча 25 — 50 тапкыр булуы безгә билгеле. Ул вакытта палач 6 — 7 сугуда кешене үтерә алган. Бу җәзадан Батыршаның исән калуы аның физик.яктан бик таза булуы хакында сөйли.

Батырша мулла бик теләсә дә патшабикә Елизавета Петровна галиҗәнаплары белән очраша алмый. Киресенчә, Батыршаны Әзекәй авылында кулга төшерүне оештырган старшина Сөләйман Диваев Санкт-Петербургка чакыртып алына. Императрица аны 1756 елның 24 декабрендә кабул итә. Өстенә казаклар формасына охшаган куе алсу төстәге бәрхеттән кафтан, алтын һәм көмеш җепләр белән чигелгән ярымкафтан, шундый ук бәрхеттән, кеш тиресе белән матурланган бүрек киертелә, герб сурәте төшерелгән, язу белән чуарланган көмеш чүмеч, алтын хәрефләре белән язылган кылыч — барысы старшинага 1147,5 тиенлек бүләк тапшырыла. Тик 80 яшьлек старшинага яңадан авылына кире кайтырга насыйп булмый. 1757 елның 14 февралендә ул вафат була, башкаланың мөселман зиратында күмелә. Үләр алдыннан аның үз урынына старшина итеп олы улын калдыруны үтенә. Сенат аның малае Солтанбәкне старшина итеп билгели. Бүләкләрне писарь Муксин Габдессәламов һәм Ырынбур казагы Петр Ашмарин туган якларына алып кайтып китәләр.

Әзекәй авылында Батыршаны тотуда катнашкан башка кешеләр дә бүләкләнә: Рәсүл, Исхак, азанчы Исмәгыйль 100 сум, Сөләйман Диваевның улы Даут, писарь Муксин Габдессәламов, Әбдүк, Бакый 50 сум бүләк алалар[217].

---

[214] Сенатский архив.— Т. 12.— С. 130.
[215] Башкортостан: Краткая энциклопедия.— Уфа, 1996.— С. 148.
[216] Чулошников А.П. Күрс. хезм.— 108 б.
[217] Витевский В.Н. Күрс. хезм.— 888—890 б.

Батырша Санкт-Петербург шәһәреннән ерак булмаган, Ладога күленнән Нева елгасы башланып киткән урындагы кечкенә утрауда урнашкан Шлиссельбург кальга-крепостеның бер кеше утыра торган камерасына ябыла. Батыршаның аяк-куллары богаулана, янында һәрдаим сакчылар куела.

Бу крепость-төрмәдә дәүләт өчен иң куркыныч булган җинаятьчеләр утыра. Элегрәк яшерен кәнсеәр бирегә озаткан арестантлар арасында патшабикәләрдән Мария Алексеевна, Евдокия, кенәзләрдән Дмитрий Голицын, Михаил Долгорукий һ.б.ны күрәбез. Батырша белән бергә биредә элек император булырга тиешле Иван Антонович 1756—1764 елларда төрмәдә утыра, подпоручик Мировичның азат итәргә теләге беленгәч, каравылчылар инструкция буенча аны буып үтерәләр.

Әлбәттә, гади җинаятьчеләр белән патшага якын кешеләрне төрмәдә тоту төрлечә була. Гади арестантлар элекке солдат казармаларыннан эшләнгән камераларда утырганнар. Дәүләткә каршы җинаять кылган кешеләрнең төрмәдә серен саклау өчен өстәмә чаралар күрелгән: арестантның чын исемен каравылда торган солдатлар да белми, тоткыннар бер-берсе белән бөтенләй аралашмый, алар белән сөйләшергә каравылга рөхсәт ителмәгән. Батыршаның кулы да, аягы да богауда була.

Шулай итеп, биш ел үтеп китә. 1762 елның 24 июлендә Батырша үзенең каравылчылары белән бәрелештә вафат була. Гыйсъянчы мулла белән булган хәлләрне аңлату өчен крепость коменданты полковник Бередников сүзләрен китерәбез: «Оный колодник взял принесенный солдатом Хомутовым топор, по одиночке у капрала Никитина тем топором голову разрубил надвое; у солдата Хомутова головы левую сторону разрубил и правый висок проломил; у Лазарева в двух местах брюхо пропорото; у Епифанова, который был на часах, в двух местах голову разрубил же. Оный же колодник и сам умер без всяких язв и побой»[218].

Бәлки, Батыршага мондый адым эшләргә этәргеч 1762 ел башында аны Себергә, Нерчинск каторжан төрмәсенә күчерү турында сенат карары этәргеч булгандыр[219]. Хәзергә ачыкланмаган сәбәп аркасында яңа патша Петр III 1762 елның мартында арестантларны Нерчинскига озатуны тоткарлый, аларны махсус указга кадәр Шлиссельбург крепостенда калдырырга куша[220].

Патша төрмәләре тарихын өйрәнүче атаклы тарихчы М.Н.Гернет фикеренчә, Батыршаны каравылчылар үзләре үтерергә мөмкин. Сакланып калган архив документларына караганда, исән

---

[218] Дубровин Н.Ф. Күрс. хезм.— 270 б.

[219] Сенатский архив.— Т. 12.— С. 130.

[220] Переладов К.Г. Политическая борьба в России в середине XVIII века и ликвидация канцелярии тайных розыскных дел // Проблемы истории русской книжности, культуры и общественного сознания.— Новосибирск, 2000.— С. 367—377.

калган 2 каравылчы солдатны җаваплылыкка, җәзага тартмаска диелгән[221]. Батыршаны агулап үтерү мөмкинлеге турында Әхмәтзәки Вәлиди дә яза[222].

Татар халкы милли-азатлык хәрәкәтенең иң танылган шәхесләрнең берсенең, рухи һәм социаль-икътисади, колониаль изүгә каршы көрәш идеологының тормышы әнә шулай өзелә. Аның гәүдәсен кальга диварлары тышындагы бер чокырга күмәләр. Мәсгуд абый Гайнетдин сүзләре белән әйткәндә, «бу гаҗәеп язмышлы, җирдә яшәешен легендага әйләндерә белгән каһарман шәхес тоткын хәлендә тормыш юлын, соңгы адымнарын да соңгы бәрелештә, чая көрәштә, ирек давында тәмамлый белгән»[223].

Фетнәдә катнашканнарның язмышы кебек үк Батырша гаиләсенең язмышы да фаҗигале була. Улы Таҗетдиннең үлеп китүе турында язган идек инде. Зөлхәбирә Хәсәнова кызлары белән Санкт-Петербургка китертелә. Төпчек кызы Салиха (чукындырылгач — Наталья исеме бирелә) 1759 елны авырып үлә. Зөлхәбирәне чукындырып — Мария Александровнага, ә Зөләйханы Верага әйләндереп, 1763 елда кызлар монастырена урнаштыралар. Монастырьның кайда урнашканлыгы билгесез. Алар турында башка мәгълүмат табып булмады.

Төрмәгә ябылган Батыршаның тарафдарларыннан берсе, Гәйнә вулысы Башап авылы ясаклы татары Акчура Ягутеев, 1757 елның 19 апрелендә төрмәдә вафат була һәм шул ук көнне Санкт-Петербургтагы Выборг мәхәлләсендә җирләнә. Калганнарының язмышы хәзергә билгесез.

Татар халкының каһарман улы Батырша мулла исеме белән бәйле вакыйгалар әнә шулай фаҗигале тәмамлана. Ислам дине өчен, рухи азатлык өчен, халык бәхете өчен кулларына корал тотып көрәшүчеләр, гомерләрен корбан итеп, мөселманнарны тоташ чукындырудан коткаралар. Ислам динен юкка чыгаруны максат итеп куйган камчы һәм кылыч ярдәмендә алып барылган чукындыру сәясәтенә каршы мөселман татар халкының фидаи көрәше генә көчләп чукындыру сәясәтен туктатырга һәм Русия хакимиятен ислам динен рәсми тану юлына басарга мәҗбүр итә. Восстание җиңелсә дә, төп максат — патшабикә Елизавета Петровнага мөселманнарның аяныч хәле турында хәбәрләр барып җитә, ә хакимият органнары мөселманнарны тынычландыру өчен иң мөһим чараларны тормышка ашырырга мәҗбүр булалар.

---

[221] Гернет М.Н. История царской тюрьмы. В 5 т.— М., 1960.— Т. 1.— С. 229.

[222] Вәлиди Ә. Курс. хезм.— 165 б.

[223] Гайнетдин М. Батырша // Иман нуры.— 1997.— Июль.— 32 б.

Йомгаклау сүзе урынына: дини түземсезлектән толерантлык өчен көрәш

Без бу китапта Батырша восстаниесен көчләп христианлаштыруны туктату өчен мөселманнарның фидаи көрәше итеп карыйбыз. Дөрестән дә, восстаниене хәзерләү, аның барышы һәм нәтиҗәләрен анализлаганда шунысы күренә: Русия дәүләте, шушы восстание сабакларын үзләштерә башлау белән, игътибарын дини сәясәтне үзгәртүгә юнәлтә, мөселманнар арасында алып барылган миссионерлык эшендә турыдан-туры көчләү сирәгәя башлый, алымнар да әкренләп үзгәрә.

Бу тарихи хезмәт әдәбиятта Русия дәүләтенең дини сәясәте турында кайбер уйдырма фикерләрнең дөрес түгеллеген исбат итә. XVI — XVIII гасырларда дәүләт белән идарә итүче патшаларның исемнәре төрле булуга карамастан, дини сәясәттә үзгәрешләр сизелми, урыс булмаган халыкларны христианлаштыру дәвам итә. Идел-Урал халыклары арасында христианлаштыру эше бигрәк тә Бөек Петр, Анна Иоанновна, Елизавета Петровна чорында кискен алып барылган.

1731 елны миссионерлык эшен җәелдерү өчен Зөя шәһәрендә урнашкан Богородицкий монастыренда керәшен кантуры — Новокрещенская контора оештырыла. Русия империясенең мөселман һәм мәҗүси халыкларын көчләп чукындыру өчен төзелгән махсус оешма — чукындыру кантуры — 33 елга якын эшләгәннән соң, Идел буе халыклары тарихында тирән һәм дәвалана алмый торган яралар калдырып, эшен туктата. Мәҗүси халыкларның күбесе хакимият даирәләре һәм миссионерлар көчләве нәтиҗәсендә урыс диненә күчә. Мөселман татар халкы, моңа кадәр тарихта булмаган чыдамлык, бабалар диненә тугрылык күрсәтеп, ислам диненнән баш тартмыйча, аны иң кадерле ядкяр итеп саклап калды.

1731 елдан башлап архимандрит Алексий Раифский житәкчелегендәге чукындыру кантуры Идел буенда яшәүче мәҗүси халыкларны чукындыру буенча тәҗрибә туплый, һәм шушы тәҗрибә 1741 елдан империянең урыс булмаган барлык халыкларын күпләп чукындыру эшен башларга мөмкинлек бирә. Миссионерларның төп коралы булып Аллаһы Тәгалә сүзе түгел, ә төрле яктан куркыту, көчләү, чукынганнарга зур ташлама — льготалар бирү тора. Чукындыруда кискен үзгәреш 1741 елда башлана;

нәкъ менә шушы елда чукынганнар саны 30 мәртәбә арта. Мондый артым соңыннан бер елны да кабатланмый, гәрчә елына дин алмаштыручылар саны 113000 гә җитсә дә. Бу елны урыс булмаган халыкларның тарихында иң кара сәхифә дип карасак, ялгышмабыз, мөгаен.

Ислам руханиларының миссионерларга каршы фидаи көрәше, халыкның көндәлек тормышында мулла-абызларның, мәчетләрнең тоткан роле аларны миссионерлар тарафыннан җимерү, ватуга китерә. 1742 —1743 еллар эчендә империянең төрле төбәкләрендә 550дән артык мәчет җимертелә. Тик миссионерлар үз максатларына ирешә алмыйлар, татарлар арасында христиан динен кабул итүчеләр саны артмый, киресенчә, ислам дине ул чорда тик ныгый, сафлана гына. Ә манаралы мәчетләр урынына манарасызлары төзелә, дога уку өйгә, гаиләгә күчә. Шулай да татарлар арасында 1748 елда якынча 1000, 1749 елда 2041 кеше төрле сәбәпләр аркасында православие динен кабул итә. Бу елдан соң чукынучылар саны татарлар арасында әкренләп кими.

Коточкыч рухи һәм икътисади көчләүгә түзә алмаган татар-башкорт халкы 1755 елда Батырша мулла җитәкчелегендә баш күтәрә. Мөселман халыкларының баскыннарга, миссионерларга каршы көрәше нәтиҗәсендә генә татарларга караган милли һәм дини эзәрлекләү йомшара, мөселман динен курыкмыйча тоту мөмкинлекләре ачыла.

Батырша восстаниесен тар-мар итеп, халыклар арасында тынычлык урнашкач та, ислам диненә караш тиз генә үзгәрә алмый, дини һәм милли кыерсыту дәвам итә. 1762 елның 25 июлендә Казан епархиясенә җитәкче итеп Вениамин Пуцек-Григорович билгеләнә; аның утызынчы еллардан бирле актив миссионер булганлыгы турында язган идек инде. Тик бу заманда инде Русия хакимиятенең исламга карата карашы үзгәрә башлый. Хакимият органнары, миссионерлар мөселман татарларны көчләп чукындырып булмаячагына инде төшенгән булалар. Русия империясе исламны үз файдасына кулланмакчы була.

Шулай да Казан, Нижгар, Әстерхан, Ырынбур губерналарында 1762 елда 115 татар, 40 чуаш, 29 чирмеш, 15 удмурт, 3 мордва, 3 калмык, 3 башкорт, 17 әрмән — барысы 242 (чыганакта шулай) кеше чукындырыла[224]. Бу мәгълүматларга караганда, алтмышынчы еллар башында чукындырылган халыклар арасында татарлар күбрәк булу белән аерылып тора. Монысы да яхшы аңлашыла, чөнки мәҗүси халыклар ул вакытта инде чукындырылып беткән диярлек һәм миссионерлар бөтен көчлә-

---

[224] Макаров Д.М. Курс. хезм.— 209 б.

рен татарларга юнәлтәләр. Саннарга караганда, бу эшне бик нәтиҗәле дип әйтеп булмый.

Күпьяклап камчы һәм корал ярдәмендә үткәрелгән чукындыру сәясәтенә мөселман татар халкы гына каршы тора ала, миссионерлар ягында бөтен дәүләтнең көче булуга карамастан, аларны җиңеп тә чыга, изге динен саклап кала ала. 1769 елның 19 февралендә Еремей Иванов атлы миссионер Нижгар епискобы Феофанга түбәнге хатны юллый: «Минем приходта булган мөселманнарны күпме генә чукындырырга тырышып карасам да, бернинди нәтиҗәгә ирешеп булмады. Бу мәрхәмәтсез, бозыкгөнаһлы татарлар мөселман кануннарында шундый нык һәм кискен торалар ки, алар чукынудан гына баш тартмыйлар, христиан-урыс җәмгыяте әгъзасы булырга теләмичә, Алла сүзен тыңларга да чиктән тыш җирәнеп баш тарталар».

Миссионерлар тарафыннан татар халкына бирелгән бу иң дөрес бәяләрнең берсе. Тик ул Нижгар татарларына гына хас нәрсә түгел, ә бөтен халкыбызның исламга тугрылыгын дөрес тасвирлый торган мөһим чыганак. Православие дине әһелләре үткәргән чукындыруны безнең халкыбыз урыслаштыру сәясәте итеп кабул иткәнгә, аннан котылуны шәригать кануннарында күргән, ислам динен иң кыйммәтле, асыл хәзинә итеп караган, аннан көч-кодрәт алган.

Ислам динен дошманнан дуска әверелдерү өчен беренче адым — Әби патшаның чукындыру контурын ябу өчен чыгарылган указы. Әби патша ислам диненең дусты була алмаса да, тик аны ихтирам итәргә мәҗбүр булган. Атаклы миссионер Евфимий Маловның Екатерина патшалык иткән елларны «мөселманнар өчен бәхетле вә игелекле еллар» дип атавы юкка гына булмаган, күрәсең.

Ислам динен рәсми тану юлында беренче кискен адым булып 33 ел буенча мөселман һәм мәҗүси халыкларны эзәрлекләү, көчләп чукындыру белән махсус шөгыльләнгән оешманы ябу торды. Сенат боерыгы 1764 елның 6 апрелендә чыгарылган.

Чукындыру контуры тарафыннан 33 ел буе туктаусыз алып барылган миссионерлык эшенең җимеше итеп 400000 тирәсе чукынган мәҗүси һәм мөселманнарны санап булыр иде. Миссионерлар хезмәте нәтиҗәсендә татарлар арасында чукынганнар өлеше 7,6 процентка җитә.

Шушы ук елларда мәҗүси халыкларның күбесе христиан диненә күчә. Алар арасында чукынган татарлар 12000нән артып китә. Тик алар, көчләп яисә льгота алыр өчен генә христиан диненә күчкәнлектән, яңа динне ихлас күңел белән кабул итмиләр. Алар өчен урыс дине формаль дин булып кала. Керәшен авылларында хезмәт итүче руханилар күпме тырышса да, православие кануннары татар-керәшен тормышына бик авырлык белән генә үтеп керә, реаль нәтиҗәсе аз була.

Шулай да күп гасырлар буенча татарлар арасында алып барылган христианлаштыру эше нәтиҗәсендә халкыбыз дини яктан ике өлешкә бүленә. Бу бүленү керәшеннәрдә мәҗүси, ислам, христиан диннәре белән чуарланган яңа культура формалаша башлауга яңа юнәлеш бирә. Керәшеннәр арасында православие дине рухи һәм көндәлек тормыш рәвеше нигезе генә түгел, ул яңа этник үзаң формалашуга этәргеч тә була.

Мөселман татарлар дини, рухи азатлык өчен көрәшне һәрдаим дәвам итеп торалар. Бу бигрәк тә 1767 —1768 елларда Екатерина II инициативасы белән чакырылган Уложенная комиссия эшендә яхшы күренә. Бу комиссия эшендә катнашкан мөселманнардан 28 депутат вөҗдан иреге, һәр авылда мәчетләр төзү, хаҗга бару, шәригать нормаларын куллану иреген алу хакында сөйләшүләр алып баралар. Тик мөселманнарның бу теләге ул вакытта тормышка ашырылмый кала. 1773 елда синод тарафыннан дини иреклек турында кабул ителгән указ да ислам диненә карашны да, сәясәтне дә тамырдан үзгәртми. Тик тетрәндергеч Пугачев явы сабаклары, мөселман Кырым ханлыгын яулап алу гына ислам диненә карашны үзгәртергә, дәүләт тарафыннан мөселманнар өчен дини оешма — Ырынбур Диния нәзарәте төзүгә китерә. Мөфтиятне ачу — ислам динен рәсми тану, дип дөрес уйлыйбыз.

Тик татар халкы ислам дине өчен көрәшне дәвам итәргә мәҗбүр була. Ислам динен рәсми тану да Русиядә диннәрне тигезләми; православие дине дәүләти дин буларак аерым урында тора, православие динендәгеләргә башка динне кабул итү катгый тыела.

Православие дине кабул итүгә 50 — 60 ел вакыт узу белән, XIX гасыр башында ук, керәшеннәр арасында урыс диненнән ислам диненә яңадан әйләнеп кайту өчен көрәш башлана. Шулай да мөселман татар халкының бер өлеше православие динендә ныгып кала һәм алар бүгенге көндә дә татар милләтенең өзлексез бер тармагы булып торалар. Миссионерларның күп еллар дәвамындагы тырышлыгы белән бер тамырдан, бер рухи дөньядан илһам алган халкыбыз ике өлешкә бүленергә, ике Аллага дога кылырга мәҗбүр була. Тик бу ирексез бүленү халыкның бергә оешуның нигезе булган бер дингә кайту көрәшен кискен киртәләр булуга карамастан туктата алмый.

Бу авыр көрәшне беренче булып 1802 елда Нижгар епархиясендә яшәгән керәшеннәр башлый, икенче елны шул ук хәл Казан епархиясендә дәвам итә; ә 1827 елда 138 авыл кешесе, христианлыкны ташлап, ислам диненә күчә[225]. 1899 елда Казан губерна-

---

[225] Одигитриевский Н. Крещеные татары Казанской губернии.— М., 1895.— С. 18—19.

сында керәшеннәр саны 43570 исәпләнә, аларның 31737се мөселманлыкка кире кайта. Ислам диненә кире кайтучылар бигрәк тә Чистай (8167 кеше), Тәтеш (6830 кеше), Зөя (6743 кеше), Мамадыш (3515 кеше) өязләрендә күп була[226].

Ул чакларда да элеккеге шикелле үк Русия империясенең кануннары буенча мөселман диненә кире кайту кискен тыела, булган очракларда ислам диненә кире кайтучыларны озак вакытлар зинданнарга ябу, мәңгегә Себергә сөрү карала, тик алар гына ислам диненә кире кайтуны туктата алмаган. Киресенчә, ислам диненә кире кайткан татарлар халык арасында җинаятьче итеп түгел, ә Мөхәммәд пәйгамбәр өчен көрәшүче фидаи зат итеп бәяләнгән.

Мисал итеп Саба якларында булган хәлне китерәбез. 1866 елның 14 маенда чәчләрен кырып, түбәтәйләр кигән бер төркем ир-ат, шулар арасында берничә хатын-кыз — Елыш авылы кешеләре — ислам диненә кучүне игълан итәләр. Шул ук вакытта Кибәхуҗа авылы да мөселманлыкка күчә. Июль ахырында Елыш авылына атлы казаклар отряды белән вице-губернатор Е.А.Розов, атаклы миссионер Н.И.Ильминский һәм суд тикшерүчесе Леккер килеп төшә. Ирләр камчы белән суктырыла, ә хатыннар кыйнар өчен Мишә буеннан тал чыбыгы җыеп китерәләр. Оештыручылар дип табылган уналты кеше, кулга алынып, Мамадыш төрмәсенә озатыла. Күпчелек халык яңадан православие диненә кайтырга сүз бирергә мәҗбүр була. Биредә булган хәлләр турында халык Елыш бәетен иҗат итә:

Без Алладан теләдек мөселманга чыгарга,
Безгә Ходай язган икән иске диндә чыдарга.

Ягъфәр кәгазь яздырган падишага бирергә,
Падишадан хөкем килгән зиндан эченә керергә.

Башлап кәгазь бирүче Ягъфәр дигән ишандыр,
Шаять, хөкем бардыр, диеп, бөтен авыл ышанды.

Кәгазь бирдек падишага ислам динен сорарга,
Губернатор килеп төшкәч, мөмкин булмады чыдарга.

Быел җәйге эшебез — ислам дине сүзебез,
Губернатор килеп төшкәч, күрмәс булды күзебез,

Мөселман дип исемләндек быел сабан сөргәндә,
Курку алды, акыл бетте вафрумга (во фронт) тезгәндә.

---

[226] Памятная книжка Казанской губернии на 1901 г.— Казань, 1901.— С. 22—29.

Командылар килделәр, камчы белән казакълар,
«Иске дингә кайтыгыз!» — дип, бар да безне азаплый.

Уналты кеше җибәрделәр, аякларын богаулап,
Балалары җыелышып җылашалар бар да аунап.

Казан дигән җирләрдә, Җылыш дигән илләрдә
Яшьләр агып, күлләр булды уйсу килгән җирләрдә.

Быел җәйне үткәздек ислам дине хакында,
Ислам дине булмый калды алты өйле хакында.

Ягъфәр җыргычы ярганда, көч киләдер сары атка,
Дин артыннан йөри торгач, кереп куйды казаматка.

Ягъфәрнең җыргычы бик яргәны борайдыр,
Бер Алладан, зар-зар килеп, ислам динен сорыйдыр.

Мөнәҗәтемә ирешсеннәр, илдән илгә җөретсеннәр,
Безгә дога кылышсыннар ислам дине хакында.

Шәригатьчә булыштык, казасына ирештек,
Мәхбүсләргә без улаштык ислам дине хакында.

Без Алладан теләдек түбәтәйне кияргә,
Безгә Ходай җазган икән гомерлеккә кояргә.

Вафрумга тезделәр, арасыннан уздылар,
Җылыш авылы хакында бер хикәят төзделәр!

Мамадышка озатылган уналты кешедән уникесе, җинаятьләре расланмагач, 1867 елда иреккә чыгарылып, приходтагы священник карамагына озатыла. Православие динен ташлап, халыкны да шуңа котыртуда гаепләнгән Мостафа Миңлебаев, Ягъфәр һәм Бәшир Вәлитовлар төрмәдә дүрт ел газап чигәләр. Миңлебай Ибраһимов төрмәдә җан бирә[227]. Хакимият даирәләре һәм дә миссионерлар белән көрәшкән батырларны халык онытмый, алар хакында бәетләр чыгарып, Алла хакына кылган хезмәтләрен мәңгеләштерә. Ә Елыш авылы кешеләренә килгәндә, алар, мөселманлыкка 1882 елда кайтып, максатларына ирешәләр. Ә моңа кадәр тагын Елыш халкын Исмәгыйль ислам диненә кайтырга өндәп йөри башлый. Алтмыш өч яшьлек картны Себергә сөргенгә озаталар. Шул заманда иҗат ителгән Исмә-

[227] Нәҗмиев Т., Хуҗин М. Яшә, Саба-йорт.— Казан, 1999.—171—174 б.

гыйль бәете, буыннардан буынга күчеп, безнең заманга кадәр килеп җиткән:

Тарих мең дә сигез йөз дә җитмеш сигезенче елда
Газиз башым харап булды алтмыш өченче яшемдә.

Урыс кяфер килгәндер Елыш авылы иленә,
Кяфер мәлгунь каршы килде хак мөселман диненә.

Исмәгыйль бара кантурга сөаль-җавап бирмәгә,
Ислам дине хакы өчен Хак юлында үлмәгә.

Барча кардәш арасында мин иканмен бәхетсез.
Мин фәкыйрьне грифтар итте (тоткын итте)
Урыс кяфер фәһемсез (аңгыра).

Минем җиккән атымны олы юлга тезделәр,
Инде казамат китәсең, дип, ач үзәгем өзделәр.

Өч-дүрт көндә килеп җиттек Сембер дигән калага,
Хак Тәгалә яздырмасын һәрбер мескен балага.

Бу кяфернең җәфасы ки башымнан алгандыр.
Туган илемнән аерылганда, бар да җылап калгандыр.

Казаматның ишекләре тимер түгел, җиз генә,
Кяфер кулына грифтар булгач, кайтып булмый тиз генә.

Ислам дине хакы өчен түктем күздин яшемне,
Өч-дүрт кяфер сүзе белән җуйдым газиз башымны.

Җәмәгатем, угланнарым, минем башым бетәр күк,
Төшләремә караганда, морадыма җитәр күк.

Минем кигән киемемне ак келәткә элегез,
Бу бәетне язучы Исмәгыйль дип белегез.

Казаматны бер күргәч,күрмәенчә күңел тук,
Бу илләрдә, бу җирләрдә сүзем калды, үзем юк.

Урыс суйган итләр белән пешерәләр ашларын,
Безгә дошман кешеләрнең эт ашасын башларын.

Өй түрендә умартам, көн дә,көн дә аерсын.
Инде китәм мин казамат, Зөбәер дуңгыз баесын.

Безгә урман бик ерак, җулы аның маяксыз.
Дөньяда ук биргән Алла — Зөбәер калган аяксыз.

Минем болай булганым дус-ишләргә фаш булсын,
Уртанчы улым Мөхәммәт Якуп үз урыныма баш булсын.

Кяфер йөзен караның белалмадым уйларын,
Кече углым Ситдыйгымның күрә алмадым туйларын.

Җир җиләген җыя-җыя кулъяулыгым тулды инде,
Җыясы ризыгым монда инде, туфрагым анда булсын инде.

Тал әйләнсен, тал әйләнсен, талга колмак бәйләнсен,
Бу бәетнең иясенә Алла рәхмәт әйләсен.

Бәеттә телгә алынган Зөбәер, Исмәгыйль артыннан шымчылык итеп, донослар язып, вулыс идарәсенә килә. Мамадышта сөйләгәннәрен раслау йөзеннән Коръән Кәрим тотып ант итә. Тик авылга кайтып җиткәнче телсез кала, каргыш сүзләрен әйтеп каршы алган авылдашларына берни әйтә алмый, авызыннан ниндидер сәер авазлар гына чыга[228].

Гомумән алганда, урыс миссионерларының мөселман татарларны чукындыру буенча хезмәтләре көтелгән нәтиҗәне бирми, дөресрәге, ул планнар тулаем барып чыкмаган. Киресенчә, урысларның көчләп чукындыру, урыслаштыру сәясәте татар халкын берләштерә, ислам диненә көч-куәт бирә, сафландыра гына. Русиядәге ислам динен өйрәнүче галим А.Бенигсен фикеренчә, XVIII гасырда, дини кысрыклау золым иткән чорда, ислам дине төшенчәсе халык, милләт төшенчәсе белән бергә кушыла һәм динне саклау төшенчәсе милли берлекне саклау төшенчәсе белән бергә карала башлый.

• • •

[228] Нәҗмиев Т., Хуҗин М. Курс. хезм.— 175—176 б.

Файдаланылган әдәбият исемлеге

Рус телендә:

Акманов И.Г. Башкирские восстания в первой трети XVIII вв.— Уфа, 1987.

Акманов И.Г. За правдивое освещение истории народов.— Уфа, 1995.

Анисимов Е.В. Дыба и кнут: Политический сыск и русское общество в XVIII в.— М., 1999.

Анисимов Е.В. Императрица Елизавета Петровна.— М., 2000.

Асфандияров А.З. Религиозная политика царизма в Башкирии в период феодализма // Башкирский край.— Уфа, 1991.— Вып.1.

Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана / Справочник.— Уфа, 1993.— Кн. 3.

Ахметзянов М.И. Новые археографические материалы и их значение в исследованиях по истории татарской литературы: Автореф. дис. ...д-ра. филол. наук.— Казань, 1998.

Бельская Т.Б. О характере восстания 1755 г. в Башкирии / Башкир. гос. ун-т. Уч. записки. Сер. ист. наук.— Уфа, 1970.— Вып. 54.— № 12.

Бенигсен А. Мусульмане в СССР // Панорама-Форум.— 1995.— № 3.

Брайан-Беннигсен Ф. Миссионерская деятельность в Поволжье // Татарстан.— 1994.— № 1—2.

Васильев С.М. Роль Батырши в восстании 1755 г. в Башкирии // Страницы истории Башкирии.— Уфа, 1974.

Вейдемейер А. Царствование Елисаветы Петровны.— СПб., 1834.

Веретенников В.И. Из истории Тайной канцелярии. 1731—1762 гг.: Очерки.— Харьков, 1910.

Витевский В.Н. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г.— Казань, 1889 —1896.— Вып. 1—5.

Газиз Г. История татар.— М., 1994.

Гернет М.Н. История царской тюрьмы. В 5 т.— 3-е изд.— М., 1962 — 1963.

Гилязов И.А. Политика царизма по отношению к татарам Среднего Поволжья во 2-й пол. XVI — XVIII вв. // Материалы по истории татарского народа.— Казань, 1995.

Глухов М. Судьба гвардейцев Сеюмбеки: Неформальный подход к еще ненаписанным страницам истории.— Казань, 1993.

Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей как один из методов национально-колониальной политики царизма // Материалы по истории Татарии.— Казань, 1948.— Вып. 1.

Доннелли А.С. Завоевание Башкирии Россией. 1552 —1740 гг. Страницы истории империализма.— Уфа, 1995.

Дубровин Н. Пугачев и его сообщники. Эпизод из истории царство-

вания императрицы Екатерины II. 1773 —1774 гг. По неизданным источникам. В 3 т.— СПб., 1884.

Еникеев Саид мурза, князь. Очерк истории татарского дворянства.— Уфа, 1999.

Знаменский П.В. История русской церкви // Учебное руководство. 9-е изд., исправ.— М., 2000.

Ильминский Н.И. Материалы для истории христианского просвещения крещеных татар. Казанская центральная крещено-татарская школа.— Казань, 1887.

Ильминский Н.И. Опыты переложения христианских вероучительских книг на татарский и другие инородческие языки в начале текущего столетия. Материалы для истории православного русского миссионерства.— Казань, 1883.

Имамов В. Запрятанная история татар.— Набережные Челны, 1994.

Ислаев Ф.Г. Исмагил Апкин — соратник муллы Батырши // Гасырлар авазы — Эхо веков.— 1999.— № 1/2.

Ислаев Ф.Г. Мулла Батырша и Альметьевский край // Альметьевский регион: Проблемы историко-культурного наследия.— Альметьевск, 1999.

Ислаев Ф.Г. Бахадуршах // Аргамак.— 1997.— № 12.

Ислаев Ф.Г. Ш. Марджани и проблемы крещения мусульман в России // Марджани: Наследие и современность. Материалы международной научной конференции.— Казань, 1998.

Ислаев Ф.Г. Православные миссионеры в Поволжье.— Казань, 1999.

Ислаев Ф.Г. Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к терпимости.— Казань, 2001.

История религий в России: Учебник / Под общ. ред. Н.А.Трофимчука.— М., 2002.

Исхаки Г. Идель-Урал.— Казань, 1991.

Исхаков Д.М. Введение в историческую демографию волго-уральских татар.— Казань, 1993.

Исхаков Д.М. Историческая демография татарского народа (XVIII — нач. XX вв.) / АН РТ, Ин-т яз., лит. и истории им. Г.Ибрагимова.— Казань, 1993.

Исхаков Д.М. Этнографические группы татар Волго-Уральского региона / АН РТ, Ин-т языка, литературы и истории им. Г.Ибрагимова.— Казань,1993.

Исхаков Д.М. Этническое развитие волго-уральских татар в XV — начале XX вв.: Дис. ...д-ра. ист. наук в форме науч. докл.— М., 2000.

Ишмухаметов З.А. Социальная роль и эволюция ислама в Татарии.— Казань, 1979.

Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке. Численность и этнический состав.— М., 1990.

Каменский А.Б. От Петра до Павла I. Реформы в России XVIII века. Опыт целостного анализа.— М.: РГГУ, 1999.

Каппелер Р. Россия — многонациональная империя. Возникновение. История. Распад.— М., 2000.

Климович Л. Ислам в царской России: Очерки.— М., 1936.

Кобищанов Т.Ю. Мусульманско-христианские отношения в Египте и Сирии в преддверии эпохи перемен (XVIII — нач. XIX вв.) // Вестник Московского ун-та. Сер. 13; Востоковедение.— 1999.— № 4.

Кунгурская летопись Пиликиных.— Пермь, 1886.

Ланда Р.Г. Ислам в истории России.— М., 1995.

Л ю щ и н Л.И. Описание башкирского бунта 1755 года // ИОАИЭ.— Т. 19.

М а к а р о в Д.М. Самодержавие и христианизация народов Среднего Поволжья (XVI — XVIII вв.).— Чебоксары, 2000.

М а л а ш е н к о А.В. Исламское возрождение в современной России.— М., 1998.

М а л о в Е.А. О Новокрещенской конторе.— Казань, 1878.

М а л о в Е.А. Миссионерство среди мухамедан и крещеных татар.— Казань, 1892.

М а л о в Е.А. О татарских мечетях в России.— Казань, 1868.

Материалы по истории татарского народа.— Казань, 1995.

М о ж а р о в с к и й А. Изложение хода миссионерского дела по просвещению казанских иноверцев с 1552 по 1867 год.— М., 1880.

Материалы по истории Башкирской АССР.— М.; Л., 1936.— Ч.1; М.; Л., 1949.— Т. 3; М., 1956.— Ч. 1.— Т. 4; М., 1956.— Ч. 2.— Т. 4; М., 1960.— Т. 5; Уфа, 2002.— Т. 6.

Мусульманский мир: Средние века, новое время / Пособие для студентов.— Казань, 1996.

М у х а м е т ш и н Р.М. Ислам в общественно-политической жизни татар: Возрождение и функционирование религиозных традиций в XX веке: Дис. ... док. политол. наук.— Казань, 2000.

М у х а м е т ш и н Ю.Г. Татары-кряшены: Историко-этнографическое исследование материальной культуры. Середина XIX — начало XX в.— М., 1977.

Н е п л ю е в И.И. Записки / Новое полное издание, с примеч.— СПб.: Изд-во А.С.Суворина,1893.

Н о г м а н о в А. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI — XVIII вв.— Казань, 2002.

Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне. [Текст. Транскрипция. Перевод на русский язык. Факсимиле] / Составитель, автор введения, коммент. и глоссария акад. Г.Б.Хусаинов — Уфа, 1993.

Полное собрание постановлений и документов по ведомству православного исповедания Российской империи. Сер. 1. В 10 т.— М., 1869 — 1915.

Полное собрание постановлений и распоряжений по ведомству православного исповедания Российской империи. Сер. 2. В 4 т.— Т.1. Царствование государыни имп. Елизаветы Петровны 25 ноября 1741—1743 гг.— СПб., 1899; То же. 1744 —1745 гг.— Т. 2.— СПб., 1907; То же. 1746 — 1752.— Т. 3.— СПб., 1912; Т. 4. Царствование государыни имп. Елизаветы Петровны. Царствование государя имп. Петра Федоровича. 1753.— 28 июня 1762 г.— СПб., 1912.

Разные бумаги генерал-майора Тевкелева об Оренбургском крае и о киргиз-кайсацких ордах, 1762 год // Временник Имп. Моск. общ. истории и древностей российских.— М., 1852.— Кн.13.

Сенатский архив.— СПб., 1888 —1913.— Т. 1—15.

Р ы ч к о в П.И. Топография Оренбургской губернии.— Оренбург, 1887.

С а д у р В.Г. Мусульмане в СССР: История и современность // На пути к свободе совести.— М., 1989.

С и н и ц ы н а К.Р. История Татарстана и татарского народа.— Ч. 2. Вторая пол. XV—XVIII вв. — Казань, 1995.— Ч. 2.

С у л т а н о в Ф.М. Ислам и татарское национальное движение в российском и мировом мусульманском контексте: История и современность.— Казань, 1999.

Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана.— Казань, 2000.

Татары.— М., 2001.

Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII — XVIII вв.— Казань, 1972.

Фаизов Г.Б. Государственно-исламские отношения в Поволжье и Приуралье.— Уфа, 1995.

Фаизов С.Ф. Ислам в Поволжье XIII — XX вв. Очерки истории.— М., 1999.

Чернавский Н.М. Оренбургская епархия в прошлом ея и настоящем.— Оренбург, 1900.— Вып. 1—2.— Т. 1.

Чулошников А.П. Восстание 1755 г. в Башкирии — М.; Л., 1940.

Чупин К. Сожжение в Екатеринбурге в 1738 г. // Русская старина.— 1878.— Кн.9.

Ш.Марджани: Наследие и современность // Материалы международной научной конференции.— Казань, 1998.

Щапов А. Лука Канашевич, епископ Казанский // Православный собеседник.— 1858.— Ч. 3.

Татар һәм башкорт телләрендә:

Алишев С.Х. Батыршаның батырлыгы // Казан утлары.— 1986.— № 2.

Баттал Г. Казан төрекләре.— Казан, 1996.

Вәлиди Ә. Башкорттарның тарихы // Агыйдел.— 1993.— № 7.

Гайнетдин М. Батырша // Иман нуры.— 1997.— Июль.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр.— Казан, 1974.— 2 т.

Саматов Г. Татарларда ислам дине.— Казан, 1998.

Татарстан АССР тарихы: Иң борынгы чорлардан алып Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр.— Казан, 1959.

Татар әдәбияты тарихы.— Казан, 1984.— 1 т.

Фәхреддин Р. Болгар вә Казан төрекләре.— Казан, 1993.

Эчтәлек

Кереш 3

Идел-Урал төбәкләрендә мөселманнарны христианлаштыру сәясәте

Русия империясендә 1552 —1740 елларда дини сәясәт 15
Афәт: мөселманнарны 1741 —1755 елларда күпләп чукындыру 30
Данлыклы миссионерлар 48
Башкортстанда дини һәм социаль-икътисади изүнең көчәюе 57
1743 —1754 елларда христианлаштыруга каршы көрәш 64

Мулла Батырша восстаниесе: максатлары һәм нәтиҗәләре

Батыршаның тәрҗемәи хәле 68
Батырша — восстаниенең идеологы һәм оештыручысы 73
Бөрҗән вулысындагы восстание (май ае) 80
Ногай юлындагы восстание (август — октябрь айлары) 83
Гәйнә вулысындагы чуалышлар 88

Восстаниенең җиңелүе һәм анда катнашучыларның язмышы

Восстаниенең җиңелүе һәм әһәмияте 95
Казакълар арасындагы качаклар: язмыштан узмыш юктыр 99
Батыршаның аркадашлары 101
Императрицага хат 104
Санкт-Петербургтагы тикшерү 108
Йомгаклау сүзе урынына: дини түземсезлектән толерантлык өчен көрәш 115

Файдаланылган әдәбият исемлеге 123

Научно-популярное издание

Ислаев Файзулхак Габдулхакович

Восстание Батырши
1755 год

Исторический очерк

(на татарском языке)

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 21.03.2005.
Форматы 84×108¹/₃₂. Офсет кәгазе. «Futuris Cyr» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,72 + форз. 0,21 + рәс. 0,42.
Шартлы буяу-оттиск 8,40. Нәшер-хисап табагы 7,73 + форз. 0,36 + рәс. 0,37.
Тиражы 2000 экз. Заказ А-192.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahat™.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.



Фәйзелхак Габделхак улы Ислаев 1946 елның 2 гыйнварында Пермь өлкәсе Октябрь районы Уразмәт-Яңабирде авылында туа.

1970 елда Пермь университетының тарих факультетын тәмамлый, шунда ук аспирантурада укып, тарих фәне буенча диссертация яклый. Пермь авыл хуҗалыгы институтында тарих фәнен укыта. 1993 елдан Казанда Тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли; 1998 елдан — Укытучыларның белемен кутәрү институтының тарих кафедрасы мөдире. 100гә якын мәкаләләр, 7 китап авторы.